ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№8 (320) – АВГУСТ 2018

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Беренчеләр заманы

Төркиядә – татар аһәңе

Җәлилчеләр эзләре буйлап

АЛЕКСАНДР СЛАДКОВСКИЙ.
ЮГАРЫ ҮРЛӘРГӘ ТАБА

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Олеся Бондаревская,
Руфия Фазылова
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Катерина Котова, Ксения Сёмина,
Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин,
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыктагы фото: ТР Дәүләт симфоник оркестрының сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижеры Александр Сладковский. Фото ТР ДСО матбугат хезмәтеннән алынды

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: 3500 данә,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә **басылды**: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № Е-2124
Басарга кул куелды: 24.08.18

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com
Коммерция директоры: Гүзәл Подольская
Коммерция директоры урынбасары:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

«О, БЕЗНЕҢ ВИНТАЖ УКУЧЫБЫЗ!..»

Бүгенге мәгълүмат ташкыны эчендә ничек күмелеп калмаска? Барлык социаль челтәрләрдән дә «чыгып» китеп, бөтенләй баш тартып, бәлки? Тасмадагы яңалыклардан үзеңне азат итеп? Балига эмиграциягә олагып? Тормыш энергиясен суырып торучы телефонны сүндереп куеп?

Әлеге ысуллар чынлап та булыша. Әмма сез тирә-юнегездәге вакыйгаларның асылына төшенергә тырыша башлаганчы гына. Ә вакыйгалардан качып котылып булмый шул. Алар безне барыбер эзләп таба, куып тота, өстебезгә бар көче белән ябырыла. Тән күзәнәкләребезгә тәмам кереп сеңә.

Психолог-белгечләр, телефоннарына минут саен чума-чума (ә аннан аерылып тору турында сүз дә юк!), безне өйрәтәләр: Интернетка көненә 20 минуттан артык вакытны әрәм итмәскә! «Ә калган вакытны ничек уздырырга?» – дип гаҗәпкә калачак тәүлек дәвамында Интернетка тоташып яшәүче кешеләр. Интернетка кадәрге «борынгы» чорның барлык шатлыкларын – якыннар белән аралашу, бергәләп урам әйләнү, киногa бару һ.б.ны – бары тик башкалар да дөнья пәрәвезеннән аерылса гына татый алачак лабаса. Югыйсә сүндереп куелган Интернет кабаттан үзенә йолып алырга мөмкин. Кача да, котыла алмыйсың! Энергия югалту процессы да дәвам итә бирә...

Әмма, вакытлыча гына булса да, котылып тору юлы бар. «Татарстан» журналы редакциясе сезгә бик тә үтемле киңәш бирә: китап укыгыз! Интернетта уздырган сәгатьләрдән китап белән уздырган сәгатьләр күпкә файдалырак. Ачып җибәрәсең китапны, ә ул, замана суыткычлары кебек, рухи сый-нигъмәтләр белән тул-тулы! Бу нигъмәтләрне, суыткычтагыдан аермалы буларак, төннәрен дә «ашарга» ярый, хәтта шулай дөресрәк тә әле. Пижамадан һәм ялгыз калып!

Кәгазь китапны уку үзе бер рәхәт булса, аның белән бәйле шартлар – икенче бер ләззәт. Яраткан кәнәфиеңә яисә диваныңа җәйлап урнашасың, йә булмаса күңелеңә якын кафедагы, кофейнядагы кадерле бер почмакка... Чәй белән кофе – китап уку процессының аерылгысыз өлешләре. Ә иң ләззәтлесе – синең өчен вакыт бөтенләй башкача ага башлый, син башка пространствога күчкәндәй буласың...

Француз язучысы Фредерик Бегбедер үзенең «Конец света. Первые итоги» китабында ватандашларына менә болай мөрәҗәгать итә: «О, минем винтаж укучым! Кәгазь букинисты, тузанлы чарлаклар вәкиле, җир йөзендәге иң хәтәр наркотикка бәйлелеккә эләккән тәвәккәл токсикоман! Күгәреп беткән фолиантлар сакчысы, илаһи әдәби аутист, акылны онытылудан саклый торган пәйгамбәр, ялварып сорыйм, берүк бу чирдән савыга күрмә!»

СЕЗНЕҢ ТӘВӘККӘЛ РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **900 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7076** – татар телендә
Индекс **П7077** – рус телендә

Иллюстрация: Айрат Гайфуллин «Тәтеш янындагы Идел яры», 2013 ел.

АВГУСТ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Изге Болгар җыены.
Репортаж

8. Ворлдскиллс: беренчеләр заманы.
Ничек үз эшеңнең остасы булырга

12. План буенча лидерлык.
Кеше капиталын үстерү ысуллары

18. Милләттәшләребез.
Төркиядә - татар аһәңе

22. Казанга гашыйк.
Сергей Безруков Татарстан һәм татарстанлылар турында

28. Кызыксынучаннар өчен юл күрсәткече.
Татарстанның өр-яңа туристик сукмаклары

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

44. Бәхетле киләчәк рецепты.
Балаларны ничек иректе итеп тәрбияләргә

46. Югары сәнгать могҗизасы.
Маэстро Британияне ничек үзенә каратты

48. Татарстан киносы менталитеты турында,
яисә Канны фестивале ерак офыкта түгел

57. Алтын чор.
Өлкәннәрнең ни өчен пенсиягә китәселәре килми

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

66. Җәлилчеләр.
«Туган илдә безнең язмышны белсеннәр иде...»

72. Тарих битләре.
Үзбәк хан һәм Җанибәк хан чорлары

84. Казан бистәләре.
Кәҗә бистәсе: соңгы утлар

88. Аккош күз яшьләре.
Тәтештә чишмәләр ничек барлыкка килгән

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: www.protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

08.08

Хулио Маглионе, Халыкара йөзү федерациясе (FINA) президенты, – Татарстанда каплаулы яңа йөзү бассейннары ачылу уңаеннан видеомөрәҗәгатьтә:

– Республикада бик зур эш башкарылганын күрәбез, киләчәккә чемпионнар үстерү өчен монда җитди нигез салынган. Бүген Татарстанның төрле почмакларында берьюлы 7 яңа бассейн ачыла. Бу объектлар, халыкның сәламәтлеге өчен дә бик кирәкле эш!

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

04.08

Владимир Мединский, РФ мәдәният министры, – журналистлар белән очрашуда:

– 2019 елда кече тарихи шәһәрләрнең үзәкләрен торгызу программасы эшләтеп җибәрелер дип өметләнәбез. Боларга биш-алты шәһәр керә: Выборг, Суздаль, Татарстандагы Чистай каласы һәм башкалар. Әлеге программа соңгы алты ел дәвамында килештерелде, һәм ул биш-алты елга хисапланган. Шул ук вакытта министрлык акчаларның 90%ы бурычка алыныр, 10%ы федераль бюджеттан булыр, дип ниятли.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

20.07

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты, – Казанда IX Бөтенроссия татар дин әһелләре форумының пленар утырышында:

– Бүген дин туган телнең, милли гореф-гадәтләребезнең һәм мәдәниятебезнең сакланып калуына булыша. Татарстанда бу эш киңрәк колачта алып барылса, башка төбәкләрдә мондый бурыч нигездә мәчетләргә йөкләнгән. Шуңа күрә без бу мәсьәләләрдә сезгә таянабыз, һәм киләчәктә үзара тыгыз элемтәдә торачакбыз.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Болгар җыены **НИНДИ** тәэсирләр калдырды

Ярышта **НИЧЕК** җиңәргә

Буа **КАЙЧАН** галәм үзәгенә әйләнәчәк

Төркиядә татарлар **НИЧЕК** яши

Татарстанда **НИНДИ** туристик сукмаклар бар

ТАТАРСТАННЫҢ ТАГЫН **БЕР БРЕНДЫ**

Изге Болгар җыены Спас районында 1995 елдан бирле уздырыла. Бу көнне бирегә, матур гадәт буенча, республика җитәкчелеге, федераль дәрәҗәдәге вәкилләр, Россия төбәкләреннән һәм чит илләрдән килгән кунаклар җыела. Минтимер Шәймиев һәм Рөстәм Миңнеханов ассызыклаганча, рус телендә аналогы һәм атамасы булмаган әлеге чара – «җыен» – уникаль, кабатланмас йола. Димәк, аны, һич тә икеләнмичә, Татарстанның бренды дип исәпләргә мөмкин.

922 елның 21 маенда Идел Болгарстаны рәсми рәвештә Ислам динен кабул итә. Шул көннән башлап ул истәлекле дата булып исәплănә.

Фото: Александр Ефремов

Автор:
Луиза Янсуар

ЯҢА МӘРҖАНИ, КУРСАВИЛАРГА ЙӨЗ ТОТЫП...

Әле Җыен әзерләнгән көннәрдә Болгар ислам академиясе ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин «Татар-информ» агентлыгына биргән интервьюсында болай дигән иде: «Изге Болгар җыенын әзерләүдә төрле оешмалар катнаша. Элек аны Тәлгать хәзрәт Таҗетдин башлап җибәрде. Ул бер дини проект кына иде. Соңрак Бөтендөнья татар конгрессы кушылды. Бүген Татарстан Мәдәният министрлыгы да, Бөтендөнья татар конгрессы һәм Татарстан Диния нәзарәте дә, Россия Диния нәзарәте дә актив катнаша. Хәзер ул, дини проект кысаларыннан чыгып, милли-дини проектка әверелде. Болгар җыены тарихыбызга конкрет караш, милли аңны формалаштыру, яңарту, балаларга җиткерү функциясен үти. Шуңа күрә дә Хөкүмәт Болгар җыенын оештыруда актив катнаша».

Быелгы Җыен нәкъ менә Ислам академиясендәге эшлекле очрашудан – түгәрәк өстәлдән башланды да. Кунакларны Рәфыйк Мөхәммәтшин каршылады һәм академия бинасы белән таныштырды. Соңгы еллар эчендә башкарылган эшләр, аларның нәтиҗәләре турында ТР Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев сөйләде. «Болгар ислам академиясе – Татарстанда гына түгел, Россия күләмендә ислам дине белеме бирүче төп югары уку йорты», – дип искәртте ул.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин ислам диненең һәрвакыт белемгә, мәгърифәткә йөз тотуы хакында искә алды. «Без Мәрҗани, Курсави, Утыз-Имәни дәрәҗәсендәге татар галимнәрен – дин белгечләрен әзерләргә тиешбез», – диде ул.

Болгар ислам академиясе 2017 елда беренче шәкертләрен кабул итте. Барлыгы – 68 кеше.

- Шуларның 16 сы – докторантурада, 52 се магистратурада белем ала.
- 2018 елда беренче курска 60 кеше кабул итәргә ниятлиләр.
- Магистратурага – 45, докторантурага – 15 кеше.

БОЛГАРЧА АПГРЕЙД

21 июльдә узган Изге Болгар җыенын тантаналы рәвештә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ачып җибәрде. Дин кардәшләрен, килгән кунакларны, аксакалларны котлап, ата-баба рухына дога кыларга җыелганнары өчен рәхмәт белдергәннән соң, ул Болгарның яңарышы, заманча әйтсәк, апгрейды турында янә бер мәртәбә әйтеп узарга кирәк тапты.

– Территориянең ничек үзгәрүе – һәммәгезнең күз алдында. Бу зур үзгәрешләр өчен беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиевкә, «Яңарыш» фондына рәхмәтебез чиксез. Болгар җире – ислам дине үзәге генә түгел, ул дөньякүләм әһәмияткә ия урын да. Монда ешрак килегез. Ислам динен күтәреп, бергә-бергә яшәргә насыйп булсын!» – диде Президент.

Ул шулай ук Россиядә исламга булган мөнәсәбәтнең уңай булуына да басым ясады:

– Россия һәрвакыт ислам дөньясы мәнфәгатьләрен тугры яклаучы булды. Бу сүздә генә түгел, ә гамәлләрдә дә чагыла. Россиядә хәзер мәчетләр күбәйгәннән-күбәя...







Татарстанда төрле конфессия вәкилләренең тыныч, тату яшәве дә әнә шул югары структуралардагы аңлауга, заманча, цивилизацияле мөнәсәбәткә барып тоташа, дип ассызыклады Рөстәм Нургалиевич. Традицион ислам һәм ислам төшенчәсе белән капланып, бәла-каза китерүчеләр, динне үз мәнфәгатьләрендә файдаланучылар барлыгын да искә алды.

Эшлекле сөйләшү барышында сүз динне укыту һәм кечкенәдән балаларның аңына сеңдерү өчен кирәкле махсус классик программа турында да барды. Очрашуда Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Россия Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгать Таҗетдин, Кавказ мөселманнары идарәсе рәисе урынбасары Салман Мусаев, ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Камил Сәмигуллин, Казахстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Таҗикстан, Дагыстан, Кырым, Палестина һәм башка төбәкләрдән килгән дин әһелләре һәм фәнни даирә вәкилләре һ.б.лар катнашты.

НАМАЗ, САМАВЫР ҺӘМ ТАТАРЧА ЧӘЙ

Изге Болгар җыенына килүчеләрнең Болгарда Җәмигъ мәчете каршындагы күмәк гыйбадәттә катнашуы – мәйданда намаз укуы, аның алдыннан вәгазь тыңлавы – шулай ук күркәм традициянең бер өлеше. Быел биредә халык бик күп җыелган иде. Әйтергә кирәк, бу традиция Россиянең төрле төбәкләреннән килгән мөселманнар өчен аерым бер мәгънәгә ия. Ульяновск өлкәсеннән килгән 77 яшен тутырырга җыенучы Кәүсәрия абыстай белән сөйләшеп киттек:

– Балаларыма рәхмәт, алып килделәр, беренче генә килүебез дә түгел, – дип сөйләп китте ул. – Килгән-килгән, берочтан Татарстанда яшәүче туганнарыбызны да күреп китәбез, кунак булабыз. Быел да бу Җыенда күрештек, менә. Үзенә күрә Кече хаҗга тиңлим инде мин моны...

Халыкны «Болгар чәйләве» экспозициясе җәлеп итте. Ул төбәк халыкларының чәй эчү традициясен чагылдыра, чәй йоласының мәдәниятебездә нинди урын тотуы хакында сөйли. «Юкка гына татар дусларым озаклап утырып чәй эчми икән», – дип тел шартлатты, бу экспозиция белән танышкач, рус милләтеннән булган танышларыбыз. «Татар чәе»нең нигезен тәшкил итә торган үләннәрнең дә булуы бөтенләе белән күңелләренә хуш килде – мәтрүшкә, бөтнек, дисеңме... Татар чәе булгач, аның янына, әлбәттә, милли тәм-том да куела – бавырсак, чәкчәк, коймак, күмәч, бал, май...

Самавырлар коллекциясе дә зур кызыксыну уятты. XIX гасырдан башлап, XX гасырның азагына кадәр – бик күп төрле экземплярларны җыеп туплаганнар. «Чәй темасы бик әһәмиятле», – дип ассызыклады Минтимер Шәймиев тә. Бу музей әле киләчәктә тулыландырылачак икән.

Абдулла Алиш музеена, халык ташкынын ерып, барып эләгә алмадык. Анда язучының әсәрләре белән бәйле күргәзмәләр урын алган, сенсор экраннардан әсәрләре белән танышырга мөмкин, интерактив оештырылган, дип сөйләделәр.

Елена Галицына, рәссам (Мәскәү төбәге):
– Дусларым белән килеп чыктым, киләсе маршрутыбыз – Башкортостан. Болгарга беренче мәртәбә ул әле төзекләндерелгәнче килгән идем. Ул чакта Биләр җирлегендә дә булдым, Алабуганың «Шайтан каласы»нда да. Мин рәсем белән мавыгам, төшереп алып киткән эскизларым да булды. Аларның берничәсен, кайткач, киндергә төшердем. Мин сәяхәтләр ярата торган кеше, җаным кая чакырса, шунда чыгып китәм. Кырымны бик яратам, мондагы архитектура үрнәкләре белән кырымныкылар арасындагы охшашлыклар табам. Болгар хәзер заманча таләпләргә җавап бирердәй чын туристик үзәккә әверелгән. Элегрәк ул үзенең хәрабәләре белән җәлеп итеп, магиясе белән сихерләп торса, бүген инде чын туризм институты булуы белән шаккатыра. Аутентик рухны саклап калып, алга таба да үстерсәләр – мөселман дөньясының йөзек кашы булып танылачак, һичшиксез.

Илгизәр Хәлиуллин, пенсионер (Татарстан):
– Элек карчыгым белән килә идек, хәзер балалар белән бергәләшеп киләбез. Оныкларны да алабыз, күрсеннәр, тойсыннар кечкенәдән мондагы рухны. Иң авыр чакларда безне дин саклап калган, дип сөйлим аларга. Без үскән вакытта дингә караш икенче иде, сез – бәхетле буын, дим.
Исламның яңарыш кичерүен күреп, бик сөенәм. Җитәкчеләрнең бу эштә башлап йөрүе – зур нәрсә. Алар бит халыкны әйдәүчеләр, барысы да алардан башланырга тиеш.

БЕРЕНЧЕЛӘР ЗАМАНЫ

Көньяк Сахалин. Җирле «Кристалл» спорт сараенда әле генә «Яшь профессионаллар» (WorldSkillsRussia) VI милли чемпионатының ябылу тантанасы тәмамланган мәл.

Сарай каршындагы мәйданда – тулы составта Татарстан командасы. ТР мәгариф һәм фән министры Рафис Борһанов нәтиҗәләр ясый:

Автор:
Ксения Сёмина

– Сез хәлегездән килгәннең барын да эшләдегез...

Хисләрне инде монннан соң да тыеп торып булмый. Бер мизгелдән соң «Татарстан! Татарстан!» дип кычкыру бөтен мәйданны яңгырата.

Аларның кулында – беренче урыннар өчен бүләкләр һәм Татарстан байраклары. Алда – туган республикага берничә сәгатьлек юл. Артта – ярышлар, анда җиңү өчен бер генә нәрсә – дөньякүләм дәрәҗәдәге осталык таләп ителде. Көньяк Сахалиндагы милли чемпионат – соңгы трамплин, менә дигән этәргеч ул, анда җиңүчеләргә 2019 елның августында милли җыелма командага керү һәм Ворлдскиллс стандартлары буенча Казанда узачак дөнья чемпионатында Россия данын яклау мөмкинлеге бирелә.

КОТКАРУЧЫЛАР – БУЙ ҖИТМӘСЛЕК ЮГАРЫЛЫКТА

Коткаручылар формасы кигән бишәү, кочаклашып, бер-берсенә уңыш теле һәм старт сызыгына тезелә. Алар шуннан берәм-берәм ясалма кыя – скалодромның текә дивары буйлап өскә үрмәләргә тиеш. Билгеле бер вакытка сыешырга, туктап тормаска, кирәк-яракттан файдаланганда ялгышмаска кирәк. Кем белә, әлеге күнекмәләрне камилләштерү аларга бәлки кайчан да булса кемнең дә булса гомерен саклап калырга булышыр...

– Төшү җайланмасын кабызам! – ди команданың беремне соңгы булып үтәүче катнашучысы. Ул бик оста аска төшә, мәйданчыктан чыга – һәм командадашлары белән кабат

кочаклашалар – бу юлы инде чемпионаттагы соңгы сынауны үтүгә сөенәләр. Бу егет-кызлар – Тәтеш дәүләт гражданлык сагы көллияте яшьләре командасы – әлеге мизгелләрдә үзләренең чемпионатның алтын медаленә лаек булуын белми куаналар.

– Бүләкләү тантанасында безнең җиңүне игълан иткәч, Татарстан әләмен алдык та, йөгереп киттек. Пьедесталга менеп баскач кына исебезгә килдек! – дип сөйли 16 яшьлек Аделина Кошелева. Командадагы иптәшләре белән ул көллиятнең беренче курсында укый. Җәй буена күнекмәләр ясаганнар, әмма Аделина моңа үкенми: чемпионат – ул сайлап алган һөнәр юлында мөһим адым.

– Минем булачак белгечлегем – «Гадәттән тыш хәлләрдә яклау». Хәзер кызларны Сыктывкардагы уку йортына гына алсалар да, Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы югары уку йортына керермен, дип бик өметләнәм. Көньяк Сахалинга бару нәрсә бирдеме? Беренчедән, мин үзебезнең республика данын лаеклы яклавыбызга бик шат. Бу «алтын» безнеке генә түгел, тренер һәм педагогларыбызның бүләге дә әле ул, – ди Аделина. – Икенчедән, без бирегә вакытны бик шәп үткәрдек. Соңгы көннәрнең берсендә тренерыбыз безгә бик тәмле, бик зур диңгез кысласын сатып алды. Бу кысланы көлешә-көлешә ашаганда мин үзебезнең чыннан да командага әйләнүебезне һәм сынауларны бергәләп үткәндә үзара якынлыкны тоюның никадәр мөһим булуын сиздем.

ЯЛКЫНЛЫ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТКӘН ӨЧЕН – МЕДАЛЬ

Чемпионатның оештыру комитеты мәгълүматлары буенча, Көньяк Сахалиндагы «Аллея» сәүдә-күргәзмә үзәгендәге ярыш мәйданчыгында 38 меңгә якын кунак булган, «Пушистый» аэродромында – тагын 13 меңгә якын кеше. Барлыгы – 50 меңнән артык кеше, ягъни шәһәр халкының чирегеннән артык кунак, дигән сүз. Чараның шеф-повары әйтүенчә, барлыгы 800 литр аш, 4,5 тонна ботка пешерелгән, 3 мең тонна яшелчә туралган, 3 мең котлета әзерләнгән, 1,5 мең балык чистартылган... Һәм бу әле гарнирны, икмәкне, башка кайнар ризыкларны исәпкә алмыйча гына...

Казан сәүдә-икътисад техникумы студенты, Татарстаннан «Ресторанда хезмәт күрсәтү» компетенциясендә катнашучы Айсылу Нуретдинова бу байлыкны табынга матурлап тезүдә рәхәтләнеп профессиональ мастер-класс күрсәтә алыр иде. Әмма башта осталыгыңны дәлилләү зарур. Соңыннан Айсылу журналистларга сөйләгәнчә, чемпионат мәйданчыгында көрәш кызу булган...

– Без бик күп әзерлек этапларын үттек, сайлап алу ярышларында Айсылу Идел буе федераль округында иң яхшы дип табылды. Икебез дә яхшы аңлый идек – гамәли яктан да, теория ягыннан да ул бик яхшы әзерлекле. Әмма ярыш вакытында аны күзәткәндә, мин барыбер бик дулкынландым, – ди тренер-компатриот (катнашучы белән бер төбәктән килгән эксперт) Екатерина Бикмуллина. – Безнең компетенциядә катнашучыларның барысы да бик югары дәрәҗәдә чыгыш ясады. Әмма төп көндәшләребез Мәскәү командасы иде, аларда техника бик яхшы. Бер генә артык

Айсылу Нуретдинова, Казан сәүдә-икътисад техникумы студенты, «Ресторанда хезмәт күрсәтү» компетенциясе буенча Татарстан конкурсанты.

Илфат Гаптрахманов, Исмәгыйль Гыймадиев, Антон Задворнов, Ангелина Кошелева, Даниил Филиппов – Тәтеш дәүләт гражданлык сагы көллиятенең җиңүче юниор командасы.

хәрәкәтләре дә юк. Мин Айсылуга нинди билгеләр куюларын күрмәдем, шунлыктан нәтиҗәне без бүләкләү тантанасында гына белдек...

Екатерина Казан сәүдә-икътисад техникумында махсус дисциплиналар укыта, WorldSkillsRussia махсуслаштырылган компетенцияләр үзәгенең «Ресторанда хезмәт күрсәтү» компетенциясен җитәкли. Айсылуны елдан артык өйрәтә.

– Айсылу безгә укырга кергәч, мин әлеге компетенциянең нәкъ менә аның өчен булуын күрдем. Шөгыльләнергә тәкъдим иттем. Җиңел булмады. Айсылуга күп тырышырга туры килде. Мин моның өчен аны хөрмәт итәм һәм аңа сокланам, – ди Екатерина. – Аның мәйданчыкта ничек эшләвен күргәч, шаккаттым: шул вакыт эчендә һөнәри яктан ул бик остарган. Мин WorldSkills 2019 дөнья чемпионатында нәкъ менә аның – бик якты, амбицияле кызның – Россия данын яклавын телә идем.

Әлеге юнәлештә беренче адым ясалды инде. Компетенциянең бөтен биремнәрен үтәп (табындагы кунакларга хезмәт күрсәтү, ризыкларны SILVER һәм GUERIDONE ысуллары белән китереп бирү, 4 төрле каһвә ясау, кунаклар каршында фламбе (ачык ялкын ярдәмендә) кабымлык әзерләү һ.б.), Айсылу 547 балл җыйды һәм Мәскәү вәкиленнән бер баллга узды. Икесенә дә «алтын» бирелде.

БЕРКАЙЧАН ДА БИРЕШМӘ!

Көньяк Сахалиндагы ярышлар ачылышында WorldSkillsKazan 2019 дөнья чемпионаты илчесе сыйфатында концерт куйган рэпер L-One ның шул исемдәге фильмга язылган «Беренчеләр заманы» трегы бар.

«Аерым бер кешеләр була, алар хыялланырга курыкмый. Алар, сулыш алырлык мөмкинлек булмаганда да, билгесезлеккә юл тота. Һәм андыйларның һәрбер адымы – киләчәккә таба ясаган адым. Җир шарын аяк астында тоймый ясаган адым! – диелә әлеге текстта. Тулаем алганда, бу легендар космонавтлар Леонов белән Беляев хакында гына түгел, бәлки WorldSkills ярышларында катнашучы һәм җиңүче яшьләр турында да.

Авиатөзелештә композицион материаллар – яңалык түгел, әмма шулай да әле инновацион технология санала. Шуңа да карамастан, «Авиация техникасына хезмәт күрсәтү» компетенциясендә катнашучы композиттан ясалган детальдәге кимчелекне таба, аннары хезмәт һәм материалны кулланудa аеруча оптималь юл белән төзәтә, башкарылган ремонтның сыйфатын һәм детальнең бөтенлеген ультратавыш һәм акустика ысулы белән тикшерә белергә тиеш.

– Чынлыкта, минем өчен иң катлаулысы бу соңгы модуль түгел, бәлки иң беренчесе – калай табагын ремонтлау булды. Мин әлеге биремгә 100%ка әзер түгел идем, шунлыктан ял вакытын укыган, өйрәнгәннәремне хәтергә төшерүгә сарыф иттем, – дип сөйли Казан авиация-техника көллиятен тәмамлаган 21 яшьлек Рәмис Хәйруллин. Ул Татарстан данын «Авиация техникасына хезмәт күрсәтү» компетенциясендә яклады.

Әмма Рәмиснең дулкынлануын тамашачылар сизмәгәндер дә: турыдан-туры трансляция кадрларында егетнең слесарьлык станогында металл детальне бик бирелеп, ышанычлы, оста рәвештә эшкәртүе күренә. Ул янәшәсеннән үтүче кунакларга да, операторга да, «Пушистый» аэродромы ярыш мәйданчыгындагы шау-шуга да бөтенләй игътибар итми.

– WorldSkills чемпионатында чыгыш ясауның стратегиясе булырга тиеш. Сиңа бирелгән вакыт чикләнгән. Йә син, корал һәм материалларны җәеп салып, регламент буенча эшлисең, яисә моңа игътибар итмичә, балларны югалтасың да, үзеңә җайлы булганча эшлисең һәм вакытны отасың. Мин исә барысын да регламент буенча, мөмкин кадәр сыйфатлы

Рәмис Хәйруллин, Казан авиация-техника көллияте чыгарылыш студенты, «Авиация техникасына хезмәт күрсәтү» компетенциясендә Татарстан вәкиле.

ТР мәгариф һәм фән министры Рафис Борһанов нәтиҗәләр ясый.

һәм вакытында эшләргә тырыштым. Барлык модульләрдә дә шома гына килеп чыкмады, – ди Рәмис. – Финишка берничә адым кала кайбер егетләрнең бирешүен күреп, мин тагын да ныграк тырыша башладым. Мин шуны аңладым: соңгы нәтиҗә синең әхлакый яктан ничек әзерләнгән булуыңа бәйле! Мондый күп сәгатькә сузылган йөкләмәләр вакытында физик яктан көчле булу да бик мөһим.

Рәмис үзенең компетенциясендә беренчелекне яулады һәм, 551 балл җыеп, Свердловск өлкәсеннән килгән, 520 балл җыйган көндәшен артта калдырды. Сүз уңаенда, Рәмиснең Татарстаннан тагын бер «коллегасы», Чаллы техника көллияте студенты Данил Пронин да «Йөк техникасына хезмәт күрсәтү» компетенциясендә алтын медаль яулады.

«БАРЫСЫ ДА БАШЛАНА ГЫНА, ДУСЛАР!»

Җиңүчеләр өчлегендә Татарстан командасы (27 алтын, 8 көмеш, 9 бронза медаль һәм гомуми хисапта 228 балл) Мәскәү командасыннан (34,18, 12 һәм 345) калышты, әмма Мәскәү өлкәсеннән (11, 9, 8 һәм 107) узды.

– Без быел былтыргыдан яхшырак чыгыш ясадык. Республикабыз Президенты һәм Министрлар кабинеты исеменнән рәхмәт белдерәсем килә. Милли чемпионатта да (дөнья чемпионаты алдыннан 2019 елда Казанда үтәчәк. – **Ред.иск.**) без һичшиксез беренче булырга тырышачакбыз. Ә инде дөнья чемпионатында җыелма команда составында илебез данын яклаучылар Россия җыелмасы җиңсен өчен барысын да эшләргә тиеш, – диде Татарстан егет-кызларына «Кристалл» янындагы кечке очрашуда Рафис Борһанов. – Минем сезгә әлеге чемпионатларга әзерлек вакытында алган күнекмәләрегезнең компетенциягез һәм тәҗрибә туплавыгыз өчен файдалы булуын, ахыр чиктә исә Татарстан һәм Россиянең байлыгын арттыруга булышуын телисем килә. Булдырдыгыз, хәлегездән килгәннең барын да эшләдегез!

– Без уку йортлары, предприятие һәм ведомстволар арасында WorldSkills ярышларына әзерлек буенча хезмәттәшлек системасын шактый күптән булдырдык. Безнең барлык компетенцияләр буенча әзерлек үзәкләре бар. Осталарыбыз һәм җиңү турында хыяллаучы талантлы яшьләребез бар. Бүген без нәтиҗәне күрә алабыз инде. Татарстан милли чемпионатларның лидерларыннан берсе санала, – ди «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» генераль директоры урынбасары Эмиль Гобәйдуллин.

Теләсә кайсы WorldSkills чемпионаты – талантларның зур ярминкәсе ул. Көньяк Сахалиндагы бүләкләү мәрасимендә конкурста катнашучыларның күбесенә Сахалин өлкәсе губернаторы чакыруы буенча эшкә урнашу ваучерлары тапшырылды. Казандагы дөнья чемпионатының тармак предприятиеләрендә нинди кызыксыну уятачагын да күз алдына китереп була...

– Әмма катнашучылар арасында көндәшлек арта. Элегрәк берничә төбәк кенә әзерлекнең югары дәрәҗәсен күрсәтсә, хәзер бөтен конкурсантлар баллары буенча шактый тигез бара. Шунлыктан безгә, лидер булып калыр өчен, WorldSkills стандартлары буенча күнекмәләр технологиясен дә, әзерлек үзәкләренең матди-техник базаларын да камилләштерүне дәвам итәргә кирәк, – ди Эмиль Гобәйдуллин.

Дөнья чемпионатында чыгыш ясаячак Россия җыелмасының төп нигезе инде формалашкан. Нигездә, бу узган елгы милли чемпионатта җиңүчеләр. Әмма Көньяк Сахалинда «алтын» алучы һәркемнең өмете бар. Конкурсантка милли җыелманың киңәйтелгән составына эләгергә, WorldSkills оештыру комитетының эчке сайлавын үтәргә, өйрәтүнең берничә этабын узарга һәм йомгаклау сынавында нәкъ менә үзенең дөнья күләм дәрәҗәдә Россия данын якларга лаек булуын дәлилләргә генә кирәк... Шунлыктан, үзенең «ВКонтакте»дагы сәхифәсендә Айсылу Нуретдинова язганча, «Безнең команда – иң көчле һәм иң тату команда. Әле барысы да башлана гына, дуслар!» ■



Эмиль Гобәйдуллин, «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» генераль директоры урынбасары (сулда), чемпионат кунакларына Татарстанның ничек итеп яшь профессионалларны әзерләве турында сөйли.

КАПИТАЛНЫ ИШӘЙТЕП...

Татарстан Россия Федерациясендәге субъектлар арасында тормыш сыйфаты буенча беренче бишлеккә керә. Экспертлар бәяләгәнчә, төбәк керемнәр буенча да, эш белән тәэмин ителеш, демографик ситуация буенча да иң югары күрсәткечләргә ия... Бу республика җитәкчелеге тарафыннан төбәк үсешендә өстенлекле юнәлеш буларак кеше капиталын сайлауга зур игътибар бирелү белән турыдан-туры бәйле.

Автор:
Ксения Сёмина

Кеше капиталына ясалган иң әһәмиятле кертемнәрнең берсе – мәгариф өлкәсенә керткән кертемнәр. Бу һәрчак шулай булган һәм булачак. Төбәк үз белгечләренә инвестицияләр ясый, ә соңыннан бу кертемнәр үзен күп тапкырлар аклый – моның чагылышын республиканың һөнәри һәм гомуми үсешендә күрә алабыз. Нәтиҗәләр югарырак булган саен, кешенең иҗтимагый бәйләнешләре дә күбрәк. Димәк, ул икътисадый, иҗтимагый һәм рухи өлкәләрдә дә күбрәккә ирешә ала, дигән сүз.

– Чиновникларны кеше капиталын туплау процессына җәлеп итү бик мөһим. Гади гражданнар белән төбәк җитәкчелеген бәйләп торган буын активрак һәм профессиональрәк булган саен, әлеге бәйләнешләрнең төбәктәге халык мәнфәгатьләрен кайгырту дәрәҗәсе дә югарырак булачак. Казан федераль университетының Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе тормышка ашырган мәгариф программалары – озак вакытка исәпләнгән инвестицияләр ул. Республика дәүләт хезмәткәрләренең интеллектуаль капиталына гына түгел, ә дәүләт белән идарә итү системасына да, – дип исәпли Югары мәктәп директоры Игорь Привалов.

Мәгариф программаларын мәктәп инде биш елдан артык тормышка ашыра. 2012 – 2018 елларда программаларны 25 меңнән артык җитәкче белән белгеч тыңлады. Соңгы еллардагы программалар практикага өстенлек биреп эшли – аны үзләште-

Фотолар КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мкатәбе матбугат хезмәтеннән алынды.

“

– Программаларның исемлеге үзгәреп тора. Без министрлыклар, ведомстволар һәм җирле үзидарә органнары таләпләренә йөз тотып эшлибез, шулай ук тыңлаучыларыбыз белән кире элемтәне дә исәпкә алабыз.

ручеләр «хәзер» һәм «шушында» кулланылырлык белем ала.

ручеләр «хәзер» һәм «шушында» кулланылырлык белем ала.

КЕШЕЛӘР – БЕРЕНЧЕ УРЫНДА

– Программаларның исемлеге үзгәреп тора. Без министрлыклар, ведомстволар һәм җирле үзидарә органнары таләпләренә йөз тотып эшлибез, шулай ук тыңлаучыларыбыз белән кире элемтәне дә исәпкә алабыз. Әйтик, мәсәлән, безнең курсларны тыңлаган бер җитәкче сораштыру барышында шундый мәгълүмат җиткерде: кул астында эшләүчеләремнең кайберләре грамоталы яза белми һәм документларны дөрес тутыру кагыйдәләрен белеп җиткерми. Ә бит дөрес тутырылган документтан күп нәрсә тора – хакимиятнең абруе да, гражданнарның аңа мөнәсәбәте дә, кайчакта хәтта кешеләрнең иминлеге дә, – ди Игорь Привалов. – Яхшы язу критерие – бу тасвирлаган проблеманы инде яртылаш чишү, асылда. Әмма моның өчен аны дөрес әзерләү кирәк. Укыган як авторны дөрес аңларга һәм әйтергә теләгән сүзен ишетергә тиеш. Шул рәвешле безнең «Эшлекле хат» курсы барлыкка килде.

Популярлык буенча икенче урында торган тагын бер программа – «Җирле халык белән мөнәсәбәтләр урнаштыру. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү». Бүгенге дәүләт эшлекләренең тарихи җирлектә оешып өлгергән «чиновник» төшенчәсенә карата булган тискәре мөнәсәбәтне үзгәртергә барлык мөмкинлекләре дә бар. Мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне куллану, «катлаулы» кешеләрне кабул итү һәм алар белән эш итү, эшлекле язу телен үтемле итеп файдалана белү, кат-

лаулы бурычларны хәл иткәндә стрессларга чыдамлы булу – гражданнар белән уңышлы бәйләнеш булдыруның иң төп һәм әһәмиятле аспектлары әнә шулар. Югары мәктәп программасы әлеге процессны ничек нәтиҗәле итү турында мәгълүмат бирә.

«Авыл җирлекләре башлыкларын укыту» – урыннардагы җитәкчеләр эшчәнлеген нәтиҗәлерәк итүгә карата республика тарафыннан куелган таләпләрне һәм әлеге сфера үзенчәлекләрен исәпкә алып эшләнгән махсус программа ул. Курс авыл җирлеге башлыкларына, беренчедән, вазыйфаларының функциональ ачыкларга булышса, икенчедән, финанслар, хокук, нормативлар эшләү һ.б өлкәләрдә кирәкле таррак белемнәрне үзләштерергә мөмкинлек бирә. Бу ялгышлардан котылырга ярдәм итә, ә бит кайбер ялгышларның бәясе чиновникның үзе өчен дә, җирле халык өчен дә, тулаем алганда, республика өчен дә шактый кыйммәткә төшәргә мөмкин. Мәктәпнең программасы – үзенә бер ликбез ул. Максаты – югарыда искә алынган өлкәләрдәге белемнәрнең аксавын кисәтү генә түгел (бу да бар, әлбәттә, әмма ул табигый рәвештә практика белән нысытыла), ә җитәкчеләргә барлык килеп туган ситуацияләрдә дөрес карарлар кабул итә белү алгоритмын үзләштерергә булышу.

УКЫРГА, УКЫРГА ҺӘМ ТАГЫН БЕР МӘРТӘБӘ – УКЫРГА

– Алдынгы укыту методикаларын гамәлгә куючы төбәк буларак, Татарстанда укытуның өзлексез процесс рәвешендә бару беренче планга чыга. Беренче чиратта, бу безнең тыңлаучыларга карый. Кайбер программалар тыңлаучыларга булган белемнәрен яңартырга, актуальләштерергә яисә дәүләт хезмәте өлкәсендә регламент һәм норма таләпләрен үтәү буенча аларны тирәнәйтергә ярдәм итә. Мәсәлән, «Коррупциягә каршы» курсы укытучылары – Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе һәм Татарстан Юстиция министрлыгы вәкилләре – аудитория белән конкрет мисаллар ярдәмендә әлеге өлкәдә коррупциягә каршы законнар һәм аларны бозуларны кисәтү очракларын тикшерәләр, – дип сөйли безгә Югары мәктәп директоры урынбасары Наталья Аксенова.

– Конкуренция булдыру, сатып алуларны үтә күренмәле һәм нәтиҗәле итүдә әһәмиятле рольне мәгълүматлаштыру тәэмин итә, – дип белдерде Татарстанның Сатып алулар буенча дәүләт комитеты коллегиясендә ТР Премьер-министры Алексей Песошин. Ул шулай ук бу өлкәдә алдынгы технологияләр кертү идеясен дә алга сөрде. Бүгенге көндә кулланыла торганнары һәм дәүләт тарафыннан сатып алулар үткәргәндәге закон бозулар һәм гамәлдә эшли торган регламентлар белән «Дәүләт һәм муниципаль сатып алулар өлкәсендә идарә итү» һәм «Дәүләт һәм муниципаль сатып алулар» курслары тыңлаучылары таныша.

«Җирле үзидарә/хакимият органнары эшчәнлеген юридик яктан тәэмин итү» программасы белемнәрен яңартырга ниятләүче юридик хезмәтләр һәм дәүләт органнары белгечләренә, шулай ук дәүләт структурасы юристларына юнәлтелгән. Юридик хезмәтнең дөрес оештырылуы һәм эшләве, норматив хокукый актлар проектларына хокукый һәм коррупциягә каршы экспертиза уздыру, проектларны әзерләүдә юридик техника кагыйдәләрен куллану – болар барысы да кыска вакыт эчендә белгечнең үз алдына куйган максатына ирешүен тәэмин итә.

Ә менә җирле үзидарә органының үз юристы булмаса, нәрсә эшләргә? Әйтик, гади генә бер авыл җирлегендә чикләрне үзгәртү каралган, һәм бу хокукый документта теркәлергә тиеш, ди. Моны контрольдә тоту, билгеле инде, җирле үзидарә башлыгы җилкәсенә төшәчәк. Юридик хезмәт вазыйфаларын да үз өстенә алырга туры килгән шундый җитәкчеләр һәм белгечләр өчен без Югары мәктәптә «Норматив хокукый актлар проектларын

әзерләү», «Белешмә-аналитик материалларны әзерләү» кебек курслар эшләдек.

ГРАМОТА АРТКАН САЕН ЗАРЛАР АЗАЯ ТӨШӘ

– Безнең уку курсларының ике зур өстенлеге бар. Беренчедән, без лекция форматыннан мөмкин булганча ерагайдык. Күпчелек дәресләр тренинглар һәм кейсларны чишү рәвешендә уза. Шулай итеп, тыңлаучы, уку-укыту процессының актив катнашучысы гына булып калмыйча, үз тәҗрибәсе белән дә уртаклаша ала. Бу башкаларга бигрәк тә кызыклы, ә яңа килгән «укучыларыбыз» өчен гаять актуаль да, – дип сөйли Наталья Аксенова. – Икенчедән, программаны эшләгәндә без һәрвакыт дөньяда тупланган тәҗрибәгә нигезләнәбез. Шуның белән беррәттән, республика дәүләт хезмәте, шулай ук муниципаль дәүләт хезмәтенең уку-укыту өлкәсендәге таләпләрен дә күз уңыннан ычкындырмыйбыз.

Югары мәктәпнең актив эшчәнлеге үз җимешләрен бирә. Безнең белгечләр программаларның һәм сораштыруларның нәтиҗәлелеген даими рәвештә мониторинглап тора, бу, үз чиратында, кайсы темаларга зуррак ихтыяҗ булуын ачыкларга ярдәм итә.

– Елдан-ел Татарстан Юстиция министрлыгы тарафыннан дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына яңадан эшләп бетерер өчен кайтарыла торган норматив хокукый актларның саны кими бара. Бу дәүләт хезмәткәрләренең әлеге өлкәдә белемнәре артуы турында сөйли, – ди Игорь Привалов.

2017 елда Татарстанда (Татарстан Республикасы Президентының гражданнар мөрәҗәгате белән эшләү идарәсе әзерләгән хисап мәгълүматы буенча), соңгы 15 ел эчендә беренче тапкыр гражданнар тарафыннан республиканың югары вазыйфаи затларына адресына юлланган гаризалары һәм шикаятьләре кимүгә китте. Республика министрлыкларына һәм ведомстволарына юлланган мөрәҗәгатьләр дә кими төште, җирле үзидарәләрдә шундый ук хәл күзәтелә. Күзгә ташлана: җирле халык белән һәм республика, һәм җирле хакимият дәрәҗәсендә вазыйфаларны үтәү дә, үзара аралашу культурасы да үсеш кичерде.

Болар барысы да – олы, даими һәм, әйтергә кирәк, кабатланмас эш нәтиҗәсе. Республика җитәкчелеге дәүләт хезмәтен камилләштерү, барлык дәрәҗәләрдәге җитәкчеләр белән белгечләрне үстерү юнәлешендә туктаусыз эшли. Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе, әлеге трендка нигезләнеп, уку-укыту программаларының эффекты иң югары дәрәҗәдә булсын өчен тырыша. Бу нәкъ менә кеше капиталына йөз тотып эшләү – төбәкнең киләчәктә дә лидер булуы өчен көч кую.

2016–2017 ЕЛЛАРДА ГРАЖДАННАРНЫҢ РЕСПУБЛИКА ХАКИМИЯТ ОРГАННАРЫНА МӨРӘҖӘГАТЬЛӘРЕ САНЫНЫҢ ҮЗГӘРҮЕ

ЧЕМПИОННАР ЭНЕРГЕТИКАСЫ

2018 елгы мундиаль Татарстан башкаласында ай буена сузылган бәйрәмгә әйләнде. Әлеге искиткеч атмосфераны бернинди җитди вакыйганың да бозмавында «Челтәр компаниясе» ААҖ белгечләренең дә өлеше зур, алар үзләренең чын профессионал булуын тагын бер кат дәлилләде.

Автор:
Ксения Сёмина

Июльнең эссе көннәренең берсендә Идел буе электр челтәрләре югары вольтлы линияләре хезмәте белгече Балык Бистәсе районында янгын чыгуын күрә, ул электр тапшыру линиясенең саклагыч зонасы ягына таба тарала. Хезмәткәр диспетчерга хәбәр итә: 220 кВ Котлы Букәш–Үзәк линиясенә куркыныч яный. Диспетчер әлеге мәгълүматны «Челтәр компаниясе» ААҖнең челтәр һәм филиаллар белән идарә Үзәгенә һәм Татарстан Республикасы энергетика системасы Төбәк диспетчерлык идарәсенә (ТДИ) тапшыра. Ут капкан урынга Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы (ГХМ) бүлекчәсе килеп җитә, ярты сәгать эчендә ул янгынны сүндерә... Әмма шул ук вакытта Казан Җылылык электр станциясендә өзеклек килеп чыга, бу исә аңа тоташтырылган подстанцияләрдә ут бетү куркынычы тудыра. Әмма моңа кадәр барып җитми: подстанцияләрдә резервны автомат рәвештә кушуның энергетиклар көйләгән схемасы эшли башлый...

Бәхеткә, әлеге эпизодлар – «Челтәр компаниясе» ААҖнең ТДИ һәм республика ГХМ белән бергәләп мундиаль алдыннан үткәргән колачлы өйрәнүләре этаплары гына. Мондый укуларның төп максаты – энергетикларның килеп туган җитешсезлекләрне тиз арада анализлау һәм аларны бетерү буенча стратегия эшләү күнекмәләрен камилләштерү. Әмма хәтта «күпсюжетлы» репетицияләр дә Татарстан башкаласында чемпионат барган чорда компаниянең чынбарлыкта үткәргән эше фонында шактый гади булып күренә.

ДАИМИ ӘЗЕРЛЕК РЕЖИМЫНДА

«Челтәр компаниясе» ААҖ өчен Казанда мундиаль чараларын әзерләү һәм үткәрү чын махсус операциягә әйләнә. Оешманың җаваплылык зонасына электр белән ышанычлы тәэмин итү таләпләре куелган бик күп объект керә. «Казан Арена» стадионы, «Казан» янындагы фанфест зонасы, «Рубин», «Хезмәт резервлары» һәм «Свияга» стадионнарының җыелма командалар яшәгән күнегү базалары, «Электрон» һәм «Үзәк стадион» күнегүләр стадионнары, Тынычлык бистәсендәге һәм «Идел» лагерендагы спорт базалары – барлык бу объектларны бертуктаусыз электр белән тәэмин итеп тору сорала. Моннан тыш, периферия нокталары – шәһәр һәм шәһәр яны электр челтәрләре һәм станцияләренә дә контроль көчәйтелә. Электр җиһазларын торышы, кимчелеклләр һәм зыян килгән урыннар, һәлакәтләрне бетерүгә әзер көчләр һәм чаралар турында мәгълүмат тәүлек буена энергетика штабына тапшырыла, аның операцияләр һәм ситуация-аналитика үзәге «Казан Арена» стадионына урнашкан була. Шәһәр энергетика объектларында террактларны кисәтүгә дә зур игътибар бирелә: әлеге юнәлештә компания белгечләре хокук саклау органнары һәм көч структуралары белән тыгыз хезмәттәшлектә эшли.

4 июньнән 16 июльгә кадәр технологик тынлык чорында компаниянең барлык бүлекчәләре эше көчәйтелгән режимда алып барыла: югары вольтлы линияләр көн саен, подстанцияләрдәге җиһазлар исә көненә берничә тапкыр тикшерелә. Электр тапшыру линияләрен даими рәвештә һавадан да тикшереп торалар. Компаниянең авария-торгызу бригадалары тәүлекнең теләсә кайсы вакытында бәлаказа турында теләсә нинди сигнал буенча чыгып китәргә әзер була.

ЧИКСЕЗ МӨМКИНЛЕКЛӘРНЕ КОНТРОЛЬДӘ ТОТУ

Казан электр челтәрләре (КЭЧ) филиалы хезмәткәрләренә зур җаваплылык йөкләнә. Аны тигезләп тарату өчен, ТР башкаласын биш зонага бүләргә, һәр бригада өчен озынлыгы һәм катлаулылыгы якынча бертөрле булган маршрутлар формалаштырырга карар кылына.

– Казан энергорайоны подстанцияләрендә – ПС 500 кВ Киндерле, ПС 220 кВ Үзәк һәм ПС 220 кВ Магистраль («Казан Арена» стадионын энергия белән тәэмин итү үзәге) – без тәүлек буе кизү тордык, май тутырылган һәм элегаз җиһазларын ешрак тикшердек, матч алдыннан һәм матч үткәрелгән көннәрдә бигрәк тә, – дип сөйли КЭЧ подстанцияләре хезмәте башлыгы Валерий Иванов. – Гадәти режимда күчмә бригадалар хезмәт күрсәтә торган түбәнрәк дәрәҗәле подстанцияләрдә «Челтәр компаниясе» ААҖнең бөтен республикадан килгән җиде филиалы хезмәткәрләре кизү торды. Алар төрле технологик җитешсезлекләр турында Үзәк штабка вакытында хәбәр бирде.

Идел буе электр челтәрләре (ИЭЧ) филиалы белгечләре Казан янындагы бистәләрдә төп электр җайланмалары эшен, аерым алганда, «Казан» Халыкара аэропортын электр энергиясе белән тәэмин итүче 110 кВ Аэропорт подстанциясен һәм Татарстан башкаласын Алабуга районындагы куәтле подстанция белән тоташтыручы 220 кВ Щелоков – Үзәк икечылбырлы һава линиясен контрольдә тотты.

– Персонал инструкция үткән һәм ПС 110 кВ Аэропорт, шулай ук безнең филиалның башка объектларында килеп туган теләсә нинди көтелмәгән хәлләрдәге җитешсезлекләрне төзәтергә әзер иде. Асылда, без үзебезнең гадәти эшебез белән шөгыльләндек, әмма процессны җентекләбрәк контрольдә тоттык. Безнең кулда мөмкинлекләре чиксез булган куәтле җиһазлар бит, – ди ИЭЧ электр подстанцияләре төркеме башлыгы Сергей Шмаков.

ЯЛГЫШЫРГА ХАКЛАРЫ ЮК

Чемпионатның «йөрәге» – «Казан Арена» стадионында «Челтәр компаниясе» ААҖнең төрле филиал һәм идарәләреннән 11 тәҗрибәле белгеч кизү торган. Объектның энергоменеджеры, Алабуга электр челтәрлә-

Реклама

ре филиалы директоры Эдуард Шаронов җитәкчелегендәге команда сигез бүлгеч щит, 350 спорт яктырткычы һәм стадионның төп казанышы – гаять зур мультимедиа экранын энергия белән тәэмин итүне контрольдә тоткан. Биредә энергетиклар Универсиада-2013 вакытында да, су спорты төрләре буенча дөнья чемпионаты барганда да, Конфедерацияләр кубогы матчларында да шундый ук режимда эшләгән. Һәм барлык бу чаралар вакытында объектта бер генә «энергетик» ЧП (ГХ) да булмаган. Әмма чемпионаттагы уеннар стадион тарихында иң күп санлы һәм иң статуслы булырга тиеш иде, шунлыктан кечкенә генә хата да кичерелмәячәк.

– Зур чаралар вакытында стадионны энергия белән өзеклексез тәэмин итү – безнең төп бурычыбыз. Ялгышырга хакыбыз юк. Чемпионат алдыннан без зур эш эшләдек: барлык электр челтәре объектларын тикшердек, җитешсезлекләрне төзәттек, шул вакыттагы өстенлекләрне исәпкә алып, электр белән тәэмин итү схемаларын үзгәртеп төзедек. Мәсәлән, блэкаут очрагында берөзлексез эшли торган станцияләр энергияне беренче чиратта спорт яктырткычларына, иминлек хезмәте җиһазларына, штабларга һәм төбәк үзәкләренә, эвакуация объектларына, авария очрагында яктыртуга, янгын сүндерү системаларына, лифтларга тапшыра. Форс-мажор очрагында барлык башка яктырту стационар дизель-генераторлар эше нәтиҗәсендә берничә минут эчендә көйләнә, – ди Эдуард Шаронов. – Без Универсиада вакытыннан сыналган схема буенча эшләдек. Безнең барлык хезмәткәрләребез дә – зур тәҗрибәле профессионаллар. Шунлыктан катлаулы хәлләр килеп чыкмады.

– Стадионда гигант күләмдә җиһазлар, катлаулы электр җайланмалары. Инде биредә беренче ел гына булмаганга, хезмәткәрләребез аларны яхшы белә. Әмма һәрвакыт нәрсәгәдер өйрәнеп була. Мәсәлән, Алабуга электр челтәрләре филиалының релелы яклау хезмәте башлыгы Фәннур Зиннәтов безгә, бүлү челтәрләрендә эш тәҗрибәсе булган кешеләргә, резервны кертү автоматлары эшен көйләү, аппаратура эше селективлыгы буенча бәһаләп булмаслык ярдәм күрсәтте… – дип сөйләде Алабуга электр челтәрләре элемтә хезмәте башлыгы Константин Евсин.

Илшат Фәрдиев, «Челтәр компаниясе» ААҖ генераль директоры:

– Без гаять зур чарада катнаштык – Казанда чемпионатның 6 уены үткәрелде, бездә меңләгән чит ил җанатары булып китте, аларны татарстанлылар, шул исәптән энергетиклар да, бик яхшы кабул итте… «Челтәр компаниясенең» соңгы еллардагы бөтен эшчәнлеге әлеге вакыйгага әзерлек белән бәйле булды. Без планлы рәвештә Казан энергорайонының ышанычлылыгын көчәйттек, энергообъектлар төзү һәм реконструкцияләү белән шөгыльләндек, төрле структуралар белән үзара хезмәттәшлекне җайладык, теләсә нинди бурычларны хәл итәргә сәләтле профессионаллар командасын әзерләдек. Конфедерацияләр кубогы вакытында мундиальгә репетиция ясадык… Безнең тырышлык бушка китмәде ахрысы! Һәм бу энергиягә баета, киләчәктә тагын да зуррак казанышларга өметләндерә. Хәзер без төгәл беләбез: мондый команда белән без Олимпиада да үткәрә алабыз!

ИҢ ШӘПЛӘРГӘ – АЛКЫШЛАР

«Казан» Гаилә үзәге янындагы фанфест мәйданчыгындагы гигант медиаэкраннардан матчларны карарга меңләгән кеше килде. Мундиальнең 40 көне буена барлык 64 матчны да бик яхшы сыйфатта трансляцияләүне энергоменеджер, Чистай электр челтәрләре директорының хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыру буенча урынбасары Сергей Панфилов җитәкчелегендәге белгечләр командасы тәэмин итте, алар һәр көн саен диярлек тәүлегенә 12шәр сәгать кизү торды.

– Без инде февральдән әзерләнә башладык. Мәйданчыкның проектын өйрәндек, Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе баш энергетигы Фидаил Гобәйдуллин белән бергә файдалануда уңайлы һәм ышанычлы электр схемасын сыздык һәм керттек, подрядчы белән бергә кабель-каналларны монтажладык – 100 метрлап тирәсе коммуникацияләр төп экранны резерв туендыру чыганаклары белән тоташтырды, – дип сөйли Сергей Панфилов.

Казан электр челтәрләре белгечләре, энергетикларның эш урыннарын җайлап, коллегаларына ярдәм күрсәтә. Моннан тыш, Казан электр челтәрләренең Көнбатыш РЭЧ хезмәткәрләре резерв трансформатор подстанциясе эшен күзәтеп тора.

Чемпионат башланганчы мәйданчыкта резерв дизель-генераторлы җайланманы кабызып карау репетициясе уздырыла, ул төрле бәла-каза очрагында фанзона объектларын электр белән тәэмин итәргә тиеш була. Электрны бөҗралап бирү схемасы мәйданчык «туендырыла» торган 110 кВ Крыловка подстанциясендә инцидент булган очракта аны башка подстанцияләргә күчереп тоташтыруны күздә тота. Җиһазлар һәм персоналның эшкә әзерлегендә шәхсән инану өчен, репетицияне «Челтәр компаниясе» ААҖ генераль директоры Илшат Фәрдиев тә килеп карый. Компания башлыгы нәтиҗәдән канәгать кала. Чемпионат вакытында,үз хезмәткәрләрен контрольдә тотар өчен генә түгел, аларга куәт өстәр өчен дә, ул берничә тапкыр фанфест мәйданчыгында була.

– Соңгы ике атнада гына түгел, чемпионатка әзерлек барган соңгы берничә елда сез гаять зур эш эшләдегез һәм моның белән горурлана аласыз, – диде FIFA президенты Джанни Инфантино июльдә Казанга килүендә. Бу – мундиаль объектларында мәшгуль булган бөтен кешенең, шул исәптән «Челтәр компаниясе» ААҖ энергетикларының да, эшенә югары бәя. Әмма иң мөһим бәя – Казан халкының һәм кунакларның чемпионат вакытында алган онытылмас тәэсирләре, сөенече һәм кабатланмас хисләре. Һичшиксез, уеннардагы алкышлар чемпионатны үткәрүдә ярдәм итүчеләр хөрмәтенә дә яңгырагандыр.

ТӨРКИЯДӘ – ТАТАР АҺӘҢЕ...

Җәйге яллар чоры башланды исә, Россия халкы ашкына-ашкына Төркиягә ял итәргә китә. Быел да шулай булды. Матур табигате, йомшак сулы диңгезе һәм кулай бәяләре белән төрек пляжлары безнең күңелне инде күптәннән яулады. Шушы гүзәллек һәм уңайлылык үз вакытында Казан егете Сәгыйть Хәйрине дә җәлеп иткән. Тормышын Төркия белән бәйләгән ул.

Автор:
Руфия Фазылова

БУКЧА АСЫП – ЕРАК ИЛГӘ...

Сәгыйть Хәйри бүген Әнкарада «Төркия авазы» радиосының татар редакциясен җитәкли. Беренче ачылган көненнән – 1998 елдан бирле әлеге вазыйфаны башкара. Төркия башкаласын яуларга Казаннан 1991 елда чыгып китә. Ул чорларны болай искә алды:

– Казан дәүләт университетының журналистика факультетында укып йөргән вакыт. Икенче курсны тәмамлаган идем. Берничә студентка Төркиядә уку мөмкинлеге бар дигәч, ике дә уйламыйча, букчамны җыйдым. Һич онытасым юк: сентябрьнең 7се иде ул. Кесәдә кырык доллар акча, башта мең төрле уй, хыял...

– Ә Казан кай ягы белән ошамады? Ни дисәң дә, монда юллар ачылырга тора: ГТРК радиосында эшлисең, телевидениедә тапшырулар төшерәсең. КДУның журналистика факультетында тагын өч ел укыйсың да, син дипломлы белгеч, югыйсә...

– Мин хәзер ул турыда еш уйланам. Туган шәһәремдә нәрсә җитмәде икән, дим? Мөгаен, күңел халәте белән бәйле булгандыр китәргә талпынуым. Ул заманда Казан цивилизация дәрәҗәсе буенча бу кадәр алга китмәгән шәһәр иде әле. Татар дөньясы уянып кына килә. Һәм киләчәктә ниләр булып бетәсен берәү дә төгәл генә әйтә алмый иде. Ә Әнкара чиста, төзек шәһәр, культура дәрәҗәсе бөтенләй башка. Мин аны беренче көннән үк яраттым.

– Казанны ташлап киткәнгә үкенгән чаклар буламы? Егерме җиде елны кичеп, кирегә әйләнеп кайтып карасак, яңадан шушы юлдан китәр идеңме? – дим.

– Китәр идем кебек. Икенче яктан караганда, Татарстан ул чор белән чагыштырганда бик күпкә алга китте. Хәзерге мөмкинлекләр булса, бәлки калу мөмкинлеген дә уйлап карар идем. Әмма шунысы бар: Төркиянең климаты миңа рәхәтлек бирә, бәлки анда калуымның төп сәбәбе дә шулдыр.

– Бөтенләйгә кайтырга исәп юкмы? Лаеклы ялга чыккач, әйтик...

– Соңгы вакытта ул хакта уйлаганым бар. Әмма монда климат кырыс. Мин җылы һавага өйрәндем инде.

– «Төркия авазы» радиосының татар редакциясендә ничә кеше эшлисез?

– Дүрт кеше эшлибез. Хезмәттәшләремнең барысы да Татарстаннан күчеп киткән татар кызлары.

– Ә радио нинди акчага яши?

– Без Төркия дәүләт телерадиокомпаниясенә бәйле. Тулысынча Төркия хөкүмәте карамагында. Шуңа күрә, дәүләт радиосы буларак, башта Төркия яңалыкларын татарча сөйлибез. Әлбәттә, төп басымны татарлар тормышына ясыйбыз.

ТАТАРСТАН КИЛЕННӘРЕ ҖӘМГЫЯТЕ?!

Сәгыйть абый (аңа шулай эндәшергә гадәтләнгәнгә, төчеләнеп, рәсми итеп эндәшәсем килми. – Авт.) гаиләсе белән Әнкарада яши. Хатыны Нигар-төрек. Улы Мөхәммәд Сирайга – егерме бер, кызы Зәйнәп Гөлчатауга унсигез яшь. Сүзебез үзеннән-үзе Төркиядәге татар гаиләләренә күчте.

– Төрек-татар гаиләләре бик күп бездә, – диде Сәгыйть абый. – Элек мин Татарстан киленнәрен йөзгә танысам, хәзер күбесен белмим. Ник дигәндә, алар елдан-ел күбәя. Еш кына очрашуларда: «Әйдә, Татарстан киленнәре җәмгыяте» төзик дип, мөрәҗәгать итәләр. Әлбәттә, уйлап карарга була. Хәер, кызлар болай да бер-берсе белән аралашып яши. Төрле кичәләр үткәрү, җыелып утыру, дисеңме. Эшкә урнашканда да бер-берсенә терәк булалар.

Төрек егетләре татар кызларын ярата дип ишеткәнем бар иде, хак икән. Баксаң, аларга безнең кызларның бала тәрбияләү ысуллары ошый икән.

– Татарстаннан килгән кызлар балалары белән бик нык шөгыльләнә, – диде Сәгыйть абый. – Балалар бакчасы, мәктәптән кайткач, төрле түгәрәкләргә йөртәләр. Тәмле итеп кичке аш әзерлиләр. Төрек гаиләләрендә мондый гадәтләр бик юк. Балалар мәктәптән кайта да өйдә утыра. Ә Татарстаннан килгән кызлар балаларын бөтен яклап үстерә. Казанда да шулай бит. Тагын татар кызларының үткенлеге, тырышлыгы турында да әйтергә кирәк. Чит ил, дип аптырап тормыйлар, тиз арада телне, гореф-гадәтләрне дә өйрәнәләр, җәмгыятькә яраклашалар. Мәсәлән, Лилия Сабир исемле кыз Әнкарада Татар ашлары йорты ачты. Атна азагына шунда татарларны җыя, матур кичәләр оештыра. Соңыннан татар ризыклары белән чәй эчү була.

Төркиянең һәр шәһәрендә диярлек татарларны берләштерүче оешмалар бар икән. Аларның күбесе рәсми рәвештә теркәлгән ди. Татар язучыларын искә алу кичәләре, милли бәйрәмнәр – берсе дә читтә калмый.

– Төркиядә күпме татар яшәвен төгәл генә әйтә алмыйм, – диде Сәгыйть абый. – Андый статистика алып барылмый. Анталиядә Татарстаннан 2 мең татар яши икәнен беләм. Ә болай иң күп татарлар Иске шәһәрдә гомер итә. Мин яшәгән Әнкара шәһәрендә Кытай ягыннан күчеп килгән татарлар күп. Истанбулда исә госманлы чорында күчеп килгән татарлар яши. Татарлар тормышы Иске шәһәрдә бик актив, гөрләп бара. Аларга сокланырлык, үрнәк алырлык.

Фото: Лилиана Вәлитова

Сан ягыннан, Төркиядә Кырым татарлары күбрәк икән.

– Җирле татарлар арасында тел сакланганмы? – дим.

– Авыл җирендә ана телен яхшы беләләр. Ә шәһәр җирендә татарча бик сөйләшмиләр, аеруча яшьләр. Ләкин икенче як та бар: 1990 нчы елларда, юллар ачылгач, Татарстан, Башкортостаннан булган милләттәшләребез Төркиягә килеп урнашты. Менә шулар хисабына төрек җирендә татар теле янә чәчәк атты.

«КЕШЕ ҮЗЕ ӨЧЕН ДӘ ЯШӘРГӘ ТИЕШ»

Төркия халкы начар яшәми. Сәгыйть абый белән, уртача хезмәт хакларын чагыштырып, санап утырдык. Укытучының уртача хезмәт хакы, безнең сумнарга күчергәндә, илле мең чамасы чыга. Уртача пенсия –25 мең сум. Пенсия дигәннән, биредә хатын-кызлар лаеклы ялга егерме ел эш стажы булганнан соң чыга, ә ир-атларга дәүләттән акча алу өчен 25 ел эшләргә кирәк икән.

– Россиядән аермалы буларак, Төркиянең шул ягы яхшы: лаеклы ялга чыкканда дәүләт гражданнарга компенсация түли, – ди Сәгыйть абый.

– Күләме күпме? – дим.

– Хезмәт хакыңа карап. Мин, мәсәлән, шул компенсация акчасына диңгез буеннан зур булмаган йорт алырмын, дип хыялланам. Лаеклы ялга чыккач, Әнкарадан китеп, диңгезе булган шәһәрдә төпләнергә уйлыйм. Дулкыннарга карап иҗат белән шөгыльләнергә, җанга ләззәт алып яшәргә... Кеше үзе өчен дә яшәргә тиеш. Яшияши шундый фәлсәфәгә килдем. Югыйсә һаман йөгерәбез, тегесе, монысы булсын, дибез. Ә гомер узып китә. Һәм күп борчуларның, хезмәтнең юкка булганын аңлыйсың...

Икътисад турында сүз чыккач кредит, ипотека турында да сөйләштек. Сәгыйть абый:

– Бездә кредитның процентлары артты, – ди.

Мин инде «7-8» дигән сан көтәм. «Арту» дигәне 2 процент икән!

– Күп түгел бит инде! – дим, гаҗәпләнүемне яшерә алмыйча. – Безнеке белән чагыштырсаң...

– Йорт салганда кредит алган идем, 0,8 процент белән... – дип дәвам итә ул.

– Төркиядә кредит алучылар күпме? – дим.

«Төркия авазы» радиосы 31 телдә сөйли, ягъни дәүләт Төркиядә яшәүче һәр халыкны кайгырта. Татар телендә башка төрки телләргә караганда да иртәрәк, иң беренчеләрдән булып сөйли башлыйлар. Монысы, әлбәттә, горурлык.

– Эшли башлаганда эфир вакыты бер сәгать иде, – ди Сәгыйть абый. – Аннан ярты сәгатькә калдырдылар. Әлбәттә, элеккеге кебек көн саен бер сәгать эшлисе килә. Безне бит Төркиядә генә түгел, Америка, Германия, башка илләрдә яшәүче татарлар да тыңлый. Еш кына электрон хатлар җибәрәләр. Хәзер менә интернетта үзебезнең телевидение каналын булдырдык. Төркиядә яшәүче татарлар тормышыннан булган иң кызыклы чараларны, аерым шәхесләр белән әңгәмәләрне шунда урнаштырабыз. Миңа калса, бу юнәлештә эшләргә кирәк. Махсус акча таләп итми, ә милләттәшләребезне таныту, берләштерү өчен бер дигән юл. Берләшеп яшик, аралашып. Татар халкы көчле, бөек милләт ул. Без үз телебезне югалтырга, араларны суытырга тиеш түгелбез…

Сәгыйть Хәйри «Төркия авазы» радиосының татар редакциясендә эшләүче хезмәттәшләре белән.

– Әйе, күп. Фатир да, машина да алалар. Россиядәге кебек инде.

– Аерма кредитларның процентында гына икән, – дип куйдым, үземә нәтиҗәләр ясап.

– Төркия Россиягә карап яшәми, – дип сүзен дәвам итте Сәгыйть абый. – Халык анда үз тормышын гадәттә Европа илләре белән чагыштыра.

«ТАТАРСТАН – ИКЕ АРАДАГЫ КҮПЕР»

Татарстанның Төркия белән дуслыгы 1992 елда ук башлана. ТРның беренче Президенты Минтимер Шәймиев Төркиянең башкаласы Әнкарага килә һәм дәүләт җитәкчелеге белән очраша. Шуннан ике як арасында шактый килешүләр төзелә, аралар җайлана.

– Татарстан Төркия өчен Россия Федерациясе белән күпер ролен башкара, – ди Сәгыйть абый. – Татар теленең төрки телләр рәтенә керүе, дин бер булу, күрәсең, үзенекен итә. Татарның талантлы уллары – Садри Максуди, Йосыф Акчура, Гаяз Исхакый һәм тагын бик күпләр үз вакытында Төркиядә сыенып урын тапкан. Ике арадагы бәйләнеш ерак тарихка барып тоташа.

Әле күпләр онытмагандыр: 2015 елда Россия белән Төркия арасында килеп чыккан каршылык (24 ноябрьдә Төркия Сирия чигендә Россиянең хәрби очкычын бәреп төшерде) ике арадагы мөнәсәбәтләрне какшатты. 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап, Россия төрек товарларына, туризмына һәм төзелеш секторына карата чикләүләр кертте. Дөрес, бер елдан соң аралар җайланды. Ә шулай да әле һаман шул очрактан «айнып» җитеп булмый.

– 2015 елга кадәр Россиядә яшәүче татарлар белән Төркия татарлары арасындагы мөнәсәбәт якынрак иде кебек, – ди Сәгыйть абый. – Уртак проектлар эшләнә, чаралар, фестивальләр үтә иде. Икътисад өлкәсендә эшләр җайланды, дип беләм. Ә менә мәдәният, сәнгать өлкәсендә әле һаман элеккеге мөнәсәбәтләргә кайтып булмый.

Соңгы елларда Төркия белән Россия арасындагы тормыш шартлары бер-берсеннән әллә ни аерылмый башлады булса кирәк. Һәрхәлдә, Сәгыйть Хәйригә шулай тоела.

– Кибетләргә кереп йөрим, әйбер бәяләре бер чама, – ди редакциябезнең кунагы. – Казанның аерым җирләренә баргач, үземне Төркиядә кебек хис итеп җибәрәм. Сүз биналар турында гына бармый, кешеләрнең үз-үзләрен тотышында уртак яклар бар. Ә Төркия халкында егерме биш ел элек булмаган үзгәрешләрне күрәм. Икенче мәдәният керә башлады кебек, тәртипсезлек тә чагылып китә. Күрәсең, халык бер-берсе белән якыннан аралашкач, ниндидер сыйфатларны да йоктырып ала. Кызганыч, адәм баласы яхшыга караганда, начар сыйфатларны тизрәк үзләштерә.

САННАРДА...

Татарстанда 10 төрек предприятиесе эшли. Аларда иң алдынгы технологияләр кулланыла. Инвестицияләр суммасы 2 миллион доллардан артып китә. Бу предприятиеләр халыкны эшле итсә, салымнар түләү нәтиҗәсендә, җирле һәм федераль бюджетка зур гына файда китерә.

ТЕЛЕМ МИНЕМ – ДУСТЫМ МИНЕМ
ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН
«ТАТАРСТАННЫ» ТАТАР ҺӘМ
РУС ТЕЛЛӘРЕНДӘ УКЫГЫЗ!
Реклама. 16+

МИН КАЗАНГА ГАШЫЙК. БУАНЫҢ ИСӘ ГАЛӘМ ҮЗӘГЕНӘ ӘЙЛӘНҮЕН ТЕЛИМ

Театр һәм кино артисты, Мәскәү Губерна театрының сәнгать җитәкчесе Сергей Безруков Татарстан тамашачысы, татарларның кунакчыллыгы, Буада таләпчән туристлар өчен ЭКО-бистә төзелеше һәм үзенең Казанга булган чиксез мәхәббәте хакында.

– Татарстан тамашачысына һәрвакыт зур ихтирам белән карадым, чөнки биредә чын мәгънәсендә театраль тамашачы яши. Казанда күп тапкырлар уйнадым инде, биредә минем дусларым шактый. Хәтта тәүге продюсерлык проектым – «Реальная сказка» фильмын да без Казанда төшердек, һәм бу идеяне хуплаганнары, булышканнары өчен казанлыларга рәхмәтем зур. Бу барыбыз өчен дә файдалы тәҗрибә булды.

Мин Казанга гашыйк: сүз дә юк, шәһәр архитектурасы белән дә, чисталыгы белән дә таң калдыра. Үзенең яхшы, төзек, шома юллары белән дә сокландыра. Армый-талмый һаман кабатлаячакмын – биредә җаның теләгән бөтен нәрсәне табып була: Европа архитектурасы үрнәкләре Казанның үзенә генә хас милли үзенчәлекләре белән янәшә тора. Кол Шәриф мәчете, бик күркәм ап-ак Кремль... Болар барысы да тарихи хәтер атмосферасына чумдыра. Зөя – гомумән минем иң яраткан урыннарымнан берсе!

Хәзер исә менә үзем өчен Буаны ачам (Сергей Безруковның «Маленький принц» музыкаль моноспектакле Буада үткән «Буинск – пространство диалога» Икенче театр фестивале кысала-

рында күрсәтелде. – **Ред.иск.**), Тәтешне дә ачарга өметләнәм. Бирегә ешрак киләсе иде дә бит. Халыкара театр фестиваленә чакыруларына мин бик шат, чөнки мин һәр яңалыкны хуплап каршылыйм. Биредә исә моның ихластан, яратып эшләнүе күренеп тора. Мондый фестивальләр күбрәк булган саен, яхшырак. Аны оештыручыларның хыяллары тормышка ашып, ул абруйлы халыкара чарага әйләнсен иде.

Мин киләчәктә җитәкчелек һәм хакимиятнең ярдәме саллырак булуын телим. Хуплаганнарын да, булышуларын да беләм, әмма бер зур теләгем бар: Буада ЭКОбистә булдырылуына өметләнәм – борынгы кием-салымнарны киеп, борынгы чын татар авылына килеп эләгеп, тарих төпкелләренә чумасы иде... Бу чит илләрдән килүче туристлар өчен дә мавыктыргыч булачак. **Минемчә, шундый авылда яшәп карар өчен алар акчаларын бер дә кызганып тормас иделәр.**

> **– Мондый провинциаль театр фестивальләре тамашачыны тәрбияли. Биредәге, Буадагы кебек, тәрбия бара.**

Бирегә автомобильдә дә, тимер юл белән дә килеп була, театрларны чакыруны һәм урнаштыруны оештыруы кыен түгел. Россиянең төрле төбәкләреннән бирегә килү бик җайлы, дип уйлыйм. Барысы да фестивальнең колачына бәйле булачак. **Кунакчыллык исә биредә чын. Татарстанда кунакларны ничек каршылауларын мин яхшы беләм, татарларның кунакчыллыгын әллә ничә тапкыр үземдә сынаганым бар. Табыннан торып китүе кыен – шартлаганчы ашаталар, һәм монда иң мөһиме – чаманы югалтмау.** Барлык ризыклар да калорияле, бик туклыклы, кунакны сыйлау һәм аңа ярау теләге шулхәтле көчле, һәм бу миңа, әлбәттә, бик ошый.

Сүз дә юк, мондый провинциаль театр фестивальләре тамашачыны тәрбияли. Биредәге, Буадагы кебек, тәрбия бара. Тамашачы әкренләп кәмит кенә түгел, ә җитди психологик спектакльләр, җитди драмалар карарга да күнегә. **Бер биш елдан соң монда бик зәвыклы, таләпчән тамашачы өлгереп җитүенә минем иманым камил, аңа ярау өчен күп тырышырга кирәк булачак.**

Буа фестиваленә 23 театр килгән иде! Хәтта Швейцариядән дә бер коллектив килгән, дип ишеттем. Буадагы фестивальгә киләчәктә уңышлар, аның тагын да куәтләнүен телим! Театр тамашалары ай буена сузылсын. Бу очракта бөтен шәһәр театр белән җенләнәчәк, театр белән яшәячәк! Берничә ачык мәйданчык оештырып, спектакльләр, Авиньондагы кебек, урамда уйналсын! Кунак коллективлар өчен бөтен шәһәр гаять зур театрга әверелсен! Буада бер түгел, ә бәлки биш кунакханә булып, алар кунак белән шыплап тулса, бигрәк тә шәп! Хәзер Остап Бендерга тыңләшеп, Васюкиның галәм үзәгенә әйләнәчәге турында сөйлисем килмәсә дә, Буаның галәм үзәгенә әйләнүен бик телим! ■

Фото: Рамиль Гали, «Татар-информ» МА

Андрей Кузьмин белән «Галстуксыз әңгәмә». «Татарстан-24».

МИН ТАТАРСТАНГА РӘХӘТЛӘНЕП КИЛӘМ, ЧӨНКИ БИРЕДӘ – ХОККЕЙ. **ХОККЕЙ ИСӘ – МИНЕМ ГОМЕРЛЕК МӘХӘББӘТЕМ**

Россия Хоккей федерациясе президенты Владислав Третьяк «Ак Барсның» ни өчен күп гол кертмәве, әмма үзенә тагын да азрак керттерүе һәм балаларны компьютер каршыннан ничек кузгату турында.

– Мин, быел «Ак Барс» бик тотрыклы уйнады, дип уйлыйм: зур йолдызлар юк, әмма бөтен сезон буена яхшы уен күрсәткән тотрыклы команда бар. Мин Зиннәтулла Билалетдиновны илебездәге иң яхшы тренерларның берсе, дип саныйм, аны КХЛда сезонның иң шәп остазы дип таныдылар. Ул үз күрсәтмәләрен төгәл үти торган команда булдырды. «Ак Барс» күп гол кертми, әмма үзенә тагын да азрак керттерә... Алларына куелган бурычны төгәл үтәделәр һәм һаман оттылар, шунлыктан Казанны котларга гына кала.

– Мин Казанга рәхәтләнеп киләм, бу шәһәрне бик яратам. Шәймиев белән дә, Миңнеханов белән дә, Спорт министрлыгы белән дә мөнәсәбәтләрем бик яхшы, чөнки биредә – хоккей. Ә хоккей ул – минем гомерлек мәхәббәтем, аңлыйсызмы? Кайда хоккейны үстерәләр, мин шунда. Татарстанда 42 шугалак булуына, биредә хоккейны яратуларына сөенәм. Шунлыктан мин сезгә бик рәхәтләнеп киләм. Минем өчен бу, чыннан да, бәйрәм.

– Миңа Билалетдинов белән уйнау бәхете тәтеде. Ул «Динамо» өчен, ЦСКАга каршы уйный иде. Әмма безнең җыелмада «Спартак», «Динамо» яки ЦСКА командаларына бүленеш юк иде. Бу – бердәм команда, шунлыктан ул «Кызыл машина» дип йөртелде һәм дөньяда иң күп җиңүләргә ирешә. Миңа һәрвакыт үземә ярдәм иткән һәм минем хаталарымны төзәтергә булышкан сакчылар ошый иде. Зиннәтулла – шәп сакчы, минем янәшәмдә торган һәм һәрвакыт уяу булган ышанычлы солдат. Аннары ул зур тренерлык мәктәбе үтте. Ул безнең әйдәп баручы белгечләребездән берсе – быелгы кебек, йолдызлары аз булган команда белән дә чемпион була ала. Бу – зур талант.

– Татарстан – хоккейны үстерүдә әйдәп баручы төбәкләрнең берсе. 42 шугалак! Бу бик шәп. Әмма, кызганыч, йолдызлар азрак. Сез үзегезнең шәкертләрдән җыелма командага кергән, Олимпия чемпионы булган беркемнең дә исемен атый алмыйсыз. Бу белгечләрнең җитешмәве турында сөйли. Стадионны төзеп кую – бер эш. Ә инде команда туплау, тренерга яшь уенчыларны тәрбияләү буенча белем һәм методика бирү – бөтенләй икенче. Шунлыктан без хоккейчылар әзерләү өчен «Кызыл машина» программасын эшләдек. Бүген биш яшьтән сигез яшькә кадәргеләр өчен махсус программалар бар. Канадада, мәсәлән, балалар командалары белән, кагыйдә буларак, актив кеше – берәр баланың хоккей яраткан әтисе шөгыльләнә. Ул әлеге дәреслекне ала, атаның кайсы көнендә нишләргә икәнен карый, ә анда бөтенесе дә бик аңлаешлы итеп язылган. Әйтик, иртәгә

Фото: Рамиль Гали, ИА «Татар-информ»

сишәмбе – гомуми физик әзерлек, кросслар. Бездә исә кайвакыт аттестация үтмәгән тренерлар килә: алар биргән йөкләмәләрдән балалар арый, имгәнә. Шул рәвешле алар балаларның хоккейдан гайрәтен чигерә. Безгә бу мәсьәләне бөтен ил буенча системалы рәвештә хәл итәргә кирәк. Шунлыктан биредә «Ак Барс хоккей академиясе» булдырылды. Без аны карадык, эше белән таныштык, киңәшләр бирдек. Һәм хәзер бергәләп шушы эшләнмәләребезне бөтен ил буенча таратырга ниятлибез. РХФ халыкара гамәли конференциясендә без Россия Хоккей федерациясенең «Кызыл машина» программасының «Ак Барс хоккей академиясе» программасы белән хезмәттәшлеге турында меморандумны имзаладык, аларны берләштерәбез, тулыландырабыз һәм бергәләп бөтен ил буенча эшлибез, дип килештек.

– Казанда «Ак Барс хоккей академиясе» төзелү бик мөһим. **Бераз вакыттан биредә Татарстанны гына түгел, бәлки бөтен Россияне дә данга күмәчәк йолдызчыклар пәйда буласына минем иманым камил. Чөнки шартлар искиткеч яхшы.** Уйнарга теләгән малайлар өчен бөтен нәрсә бар. Әмма аларны өлкәнрәк командаларга алып барып җиткерерлек профессиональ тренерлар кирәк.

– Минем Рөстәм Миңнехановның да хоккей уйнаганын күргәнем бар. Инде күп еллардан бирле боз өстендә ул, шактый оста уйный. Безнең җитәкчелекнең үрнәк күрсәтүе бик мөһим. Алар – иң мәшгуль кешеләр бит. Владимир Владимирович Путин исә, мөгаен, иң мәшгуледер. Шулай булса да, ул бозга чыгарга вакыт таба. Хоккей федерациясе президенты буларак, бу минем өчен бик мөһим, чөнки ул хоккейның нәрсә икәнен аңлый. Спорт белән шөгыльләнәсең икән, син инде аңа башка төрле мөнәсәбәттә – бусы беренчедән. Икенчедән, ул башка җитәкчеләргә дә сәламәт яшәү рәвеше үрнәген күрсәтә. Игътибар иткән булсагыз, Путин үрнәгеннән соң күп җитәкчеләр бозга басты һәм моның чыннан да ләззәт бирә алуын аңлады. Әтәргечне исә Владимир Владимирович бирде – 60 яшьтә дә, бик яхшы шумасаң да, өйрәнергә, шөгыльләнергә һәм моннан рәхәтлек алырга мөмкин булуын раслады.

– Минем оныгым ЦСКАда иде, илнең үсмерләр һәм яшьләр җыелмаларында уйнады. Хәзер ул икенче капкачы ролендә – кайсы клубта икәнен әйтмим. Һәм эш аның минем оныгым булуында гына түгел. Мин аның бик тәртипле егет икәнен беләм. Аның уйныйсы килә. Акча аны әллә ни кызыксындырмый, аңа уен мөһим. Мин «Ак Барска шалтыратып: «Йәгез әле, минем капкачыны куегыз! Минем оныгым уйнарга тиеш!» – дип әйтә алмыйм бит. Юк. **Миңа бик күп кеше мөрәҗәгать итә: «Зинһар, минем уенчыны куегыз инде!» – диләр. Мин: «Ничек куйыйм инде мин? Ул моңа үзе ирешергә тиеш», – дип җавап бирәм.**

– Безнең илдә малайлар хоккей уйнарга тели, әмма без шартлар тудырмыйбыз. Советлар Берлегендә бөтен илдә 80 шугалак кына эшләде, әмма нәтиҗәсе бар иде. Чөнки җирдә, табигый боз өстендә уйнадылар. Без барыбыз да шуннан чыктык. Хәзер исә андый кышлар юк, хәтта Себердә дә, шунлыктан махсус шартлар тудырырга кирәк. Без хәзер хоккейны үстерү буенча федераль программага эләгүебезгә бик сөенәбез. Акча бүленер, дип өметләнәбез. Безгә әле тагын 400 шугалак кирәк. Канадада 3 мең шугалак төзелгән, бездә исә 560 кына. Финляндиядә нибары 34 миллион кеше яши, ә 230 шугалаклары бар. Швециядә – 340, Германиядә – 150, Швейцариядә исә 140 шугалак исәпләнә. Сүзнең ни турында баруын аңлыйсызмы? Аларда шугалаклар бик күп. Ә без, шугалаклар санын ишәйтеп, милли җыелма проблемасын гына түгел, социаль проблеманы да хәл итәчәкбез – балаларны компьютерга бәйлелектән коткарып, сәламәт яшәү рәвешенә күнектерәчәкбез. Шунлыктан минем беренче теләгем – шугалаклар. Икенчесе – тренерлар. Безнең институтларыбыз бар. Алар барысы да яхшы эшли дип әйтеп булмый, чөнки аларның методикалары юк, элеккечә эшлиләр. Хәзер без аларга методика биргәч, алар балаларны өйрәтә башлаячак. Мәскәүдә, башка шәһәрләрдә хоккей кафедралары бар. Алар безнең методика буенча укытачак. Төп проблемаларыбыз шушылар.

Андрей Кузьмин белән «Галстуксыз әңгәмә». «Татарстан-24».

Дендрарий
Җир асты рудниклары
Өяз шәһәре
Татар авылы

Фото: Александр Гайнетдинов

БЕЗНЕҢ БЕЛӘН БЕРГӘ СӘЯХӘТ ИТЕГЕЗ

Җәй белән саубуллашыр алдыннан кечкенә генә сәяхәт кылып алу яхшы булыр иде, дип уйлыйбыз. Сәяхәттән дә яхшырак нәрсә бар? Дөрес, тагын шундый берничә сәяхәт. Дөнья күрүдән канәгатьлек кичерү юл чакрымнарына гына да, хәтта сәфәр кылгандагы уңайлылыкларга гына да түгел, бәлки күргәннәрнең синең өчен өр-яңа галәм ачып бирүеннән торуы да хак. Үзең өчен яңа дөнья ачу, дулкынландыргыч хисләр кичерү, бу турыда таныш-белешләреңә җиткерү, аларның син төзегән юл күрсәтмәсе буенча сәфәргә чыгып китүе – менә болар зур канәгатьлек кичерүгә сәбәпчеләрдер.

Бу юлы «Татарстан» журналистлары, әле тапталып өлгермәгән туристлар сукмаклары буйлап йөрергә яратучылар, укучыларына эксклюзив юл күрсәткече тәкъдим итә. Безнең юл күрсәткечендәге сукмаклар әле тапталмаган, алар пляжларындагы һәрбер ком бөртеге өйрәнелгән курортларга яисә күп тапкыр кулланыштагы стандарт маршрутларга бөтенләй охшамаган. Аның каравы биредә – уникаль урыннар, тыюлыклы территорияләр һәм күпләр әлегәчә белмәгән экстремаль квестлар. Һәм болар барысы да Каф тавы артында түгел, янәшәдә – үзебезнең Татарстаныбызда. Укыгыз, өйрәнегез, күңелегезгә ошаганны сайлагыз!

ДӨНЬЯ АЛЛЕЯЛӘРЕ БУЙЛАП...

Мәскәүдән Архангельскига кадәр мең километрдан артык юл. Машинада барганда, тәрәзә аша ландшафтның ничек үзгәрүен, бер урманның икенчесе белән алышынуын күреп торасың... Әмма моңа охшаш юлны узар өчен алай еракка китү мәҗбүри түгел – Казан янындагы Раифа урманында булу да җитә. Биредә шундый ук маршрут нибары биш чакрымга – трассадан Садовый бистәсенә кадәрге арага сыйган. Юлдан шунда ук урманга борылып керә алмыйсың – тыюлык режимы рөхсәт итмәячәк, аның каравы, сәяхәт ахырында – җәннәт бакчасы диярсең! – сезне бөтен төсләре һәм исләре белән дендрарий каршы алачак.

Автор:
Катерина Котова

Бу урманны беркайчан да кисмәгәннәр, дип сөйлиләр. Башта аны мәҗүси марилар изгегә санаган: алар үзләренең йолаларын «гигант» агачлар – бүгенге көнгә 270 яшькә җиткән борынгы наратлар янында башкарган. Аннары аны биредә Раифа Богородица монастырена нигез салган монахлар саклаган. Ә 1960 елдан – шушында ук Идел-Кама биосфера тыюлыгы оештырган галим биологлар. Үзенең рәвеше белән уникаль һәм Татарстанда бердәнбер ул урман.

Бу территория зоологларны да һәрвакыт җәлеп итеп торган, чөнки ландшафтның һәм туфрак төрләренең алышынуы сәбәпле, бу урыннарда гаҗәеп биологик күптөрлелек хакимлек итә, диләр. 11 мең гектар мәйданда, урманнарда, күлләрдә һәм хәтта сазлыкларда да искиткеч күп сандагы тереклек ияләрен – пошиларны, бүреләрне, кабаннарны, кондызларны, селәүсеннәрне очратырга мөмкин. Кошларның гына да 260 тан артык төре бар. Барлык территориянең биш проценты экологик туризм өчен билгеләнгән. Саралин участогында» табигать сөючеләр өчен махсус экскурсия сукмаклары бар. Әйтик, мәсәлән, су маршрутында тыюлык символы булган ак койрыклы диңгез бөркетен очратмый калмыйсың. Бу кошларның таралу тыгызлыгы биредә бөтен Идел буендагыдан югарырак! Раифа участогында мондый сукмаклар юк, әмма искиткеч дендрология бакчасы бар.

...Һәм менә без – могҗизаи аллеядә. Баш очыбызда – әллә кая югарыда – юан кәүсәле баһадирларның ябалдашлары кушылып йомыла. Менә Маака шомырты – аңа ерак 1855 елда ук Россия натуралисты Ричард Карлович Маака хөрмәтенә шундый исем биргәннәр. Әмма аның башка, гадирәк исемнәре дә бар. Ландшафт дизайнерларының мәхәббәте – гаҗәеп бронзасыман кәүсәсе өчен Маака шомыртын «тыйнаксыз» дип тә атыйлар: киңәя барган саен, чишенгән шикелле итеп, ялтырап торган кайрысы шартлый башлый. Хәер, бу гүзәлнең тагын бер исеме бар – «аю чире». Әллә инде ялкау кәкре тәпиләр аның кара җиләкләрен яратканга, әллә аның бер генә җиләген кабып карау да кешедә гаҗәеп эффект тудыргангa. Бу бакчада

йөргәндә берүк аның җиләкләренә кызыкмагыз!

Сүз уңаеннан, әлеге бакчага йөз ел элек диярлек – 1921 елда нигез салынган. Аны булдыруның нигезенә кыю идея – төрле үсемлекләрнең климатка ничек яраклашуын күзәтү теләге сәбәп булган. Шулай итеп, бакчада Америка, Европа һәм Азиянең уртача климатлы киңлекләреннән кайткан яшел «күчмәннәр» барлыкка килгән. Барлыгы биш йөздән артык төр! Сукмаклардан үткәндә, сез планетабызның төрле почмакларында була аласыз – шартлы рәвештә генә булса да.

Менә без дә, тәмле исләргә тартылып, Американың Бөек күлләре районына килеп чыгабыз. Монда көнбатыш туясы үсә. Индеецлар туяны тормыш агачы дип саный һәм үзләренең вигвамнарын шуларның куелыгында төзи. Бу табигать балалары туя исенең хәтта туберкулезны да дәвалавына ышана. Хәер, моны фәнни яктан да аңлатып була: туя һавага бик күп күләмдә фитонцидлар бүлеп чыгара. Сез дә сулагыз аны. Сүз уңаеннан, мондагы туяның бөтенләй америкача булмаган үз тарихы бар. Салкын, ач кышларның берсендә аның ярдәмендә пошилар котылып калган. Берьюлы берничә поши, дендрарий территориясенә кереп, аллеяне «кыркып» чыккан. Хәзер бу турыда агачларның гадәти булмаган ябалдашлары искәртеп тора: алар нәкъ менә линейка ярдәмендә астан тигезләп киселгән кебек.

Безнең тагын бер ачышыбыз – көмешсыман лох. Аның яфраклары белән җиләкләре – чын перламутр! Тик исе белән генә сынаткан: кирәгеннән артык татлы-баллы, борынга килеп бәрелүгә, яныннан качасы килә! Тик еракка түгел, ә Виргиния гамамелисы янына гына. Бу Төньяк Америка гүзәлен косметологлар ярата, чөнки ул яшәртү сәләтенә ия. Халыкта аны сихерче чикләвеге дип тә йөртәләр – яфраклары урман чикләвеге яфрагына охшаганга. Тузгак сары чәчәкләре көз көне барлыкка килеп, көмеш җиләкләреннән дә ким гаҗәпләндерми. Бөҗәкләргә ошый, имеш, ә менә сезгә ошармы икән – үлгән песи исе килә, диләр аннан...

Бакча буйлап йөргәндә... сакураны искә төшерәбез. Җирле газеталарның берсе аның турында «чәчәк атты» дип язган иде! Димәк, хәзер аллея буйлап бу япон могҗизасын эзләүчеләр бер без генә түгел. Бик белдеклеләнеп, сакура Татарстан дендрариендә чәчәк атмый, дип игълан итәбез. Алай гына да түгел, авыр ияләшә, дибез. Ышанмасагыз – үзегез инаныгыз. Без күреп ышандык, әмма борчылып тормадык. Әйләнә-тирәндә, хәтта табигатьтә дә сирәк очрый торган шушы кадәр формалар, төсләр һәм исләр кушылмасы булганда, моңаеп торырга мөмкинме соң! Менә инде кызыл чаган да күзгә әзерләнеп утыра. Бу искиткеч дөньяның тормыш тантанасы буларак, әлеге урындагы төсләр балкышын үз күзләрең белән күрер өчен – шәһәр ыгы-зыгысында октябрьнең бер-ике коры ял көнен ычкындырып җибәрмәскә иде бит.

НИЧЕК БАРЫРГА:

Казан – Яшел Үзән трассасы буйлап Раифа борылышына кадәр барыгыз, ә аннары тыюлыкның урман массивы юлы аша – Садовый бистәсенә кадәр.


ЭКСКУРСИОННЫЙ
МАРШРУТ



БАКЫР ТАУ ХӘЗИНӘЛӘРЕ

«Бу урын спелеологик яктан да, тарихи караштан да игътибарга лаек. Мин төрле илләрдә булдым, күп рудниклар күрдем, әмма мондыйны беренче очратуым. Рудник музей-тыюлык була алыр иде».

Алексей Жалов, *Европа спелеологлар союзы вице-президенты*

Автор:
Алсу Троицкая

Әгәр сез Татарстанга килгән-сез икән, биредәге вакытыгызның бер көнен һичшиксез Сарманга барыр өчен билгеләргә тиешсез. Дөресрәге, район үзәгенең төньяк-көнчыгыш кырыендагы бакыр рудникларына барыр өчен. Алар сезнең өчен ачыш, соклану объекты булырга чыннан да лаек. Бердәнбер шарт – анда бару турында алдан кайгыртырга һәм озатучы белән сөйләшеп куярга кирәк, ул сезгә «Бакыр базы» рудникгының җир асты галереялары буйлап экскурсия оештырса, шәп булачак.

Тәэсирләр онытылмаслык булачак, менә күрерсез. «Бакыр базы»ның чуалып беткән күп баскычлы галереяларында адашырга да мөмкин. Яки тар тишекләрдә кысылып калырга. Ни дисәң дә, рудникларның холкы каршылыклы һәм хәтәр. Шуңа күрә озатучыдан башка монда баш тыкмавың хәерле. Бу урын спелеологлар, географлар, археологлар һәм тарихчылар арасында бик популяр. Әмма гадәти туристлар монда шулай да күп түгел. Һәм бу мондый үзенчәлекле, тынычлык хөкем сөргән атмосфераның кадерен белүчеләр өчен зур өстенлек. Биредә вакытлыча булса да бөтен мәшәкатьләр һәм проблемалар онытылып тора. Әхмәт-Таудан бакыр табу эше XVIII гасырның беренче яртысында башланып китә. Ике чакрымнан артык озынлыктагы бакыр чыгару юллары яхшы сакланган. Бу әле аларның билгеле өлеше генә.

Менә без «Бакыр базы» рудникгы авызына килеп җитәбез. Эчкә керер өчен әйбәтләп иелергә кирәк – уемның биеклеге нибары 90 см гына.

Кайбер тарихчылар раславынча, рудникны Төньяк сугышы вакытында әсир төшкән шведлар үзләштерә башлаган. Әмма башка фараз да бар. Анысына ышансаң, «Бакыр базы»н иске йола тотучылар казыган. Янәсе, алар рудникны үз гыйбадәтләрен кылу өчен файдаланганнар. Өченче фараз буенча рудник «чудь» дип аталган ярым мифик халык тарафыннан булдырылган. Шунысы кызык: бакыр рудникгының үзәгендәге «зал»ларның берсендә күл бар. Аның суы иң югары сыйфатка җавап бирә дип табылган. Белгечләр сүзенә караганда, бу – «бозылмый торган» су. Бәлки, чыннан да иске йола әһелләре кылган догалардандыр? Әллә чудьләр өргән тылсымнанмы?

Монда салкын һәм караңгы. Җылы кием һәм фонарь алырга онытмагыз! Мәгарәнең кызыгы нидә соң? Беренчедән, монда экзотик җир асты җан ияләре, динозаврларның замандашлары: колаклы соры ярканатлар һәм төньяк кожаннары, шулай ук бик сирәк очрый торган очлы борынлы бакалар яши. Икенчедән, сез бу мәгарәдә җиребезнең ничек «ясалганын» үз күзләрегез белән күрерсез. Тирәндә нинди катламнар булуын, төрле утырмаларны... Пермь чоры күз алдыгызга бөтен асылы белән килеп басар – география дәресләренә чып-чын күргәзмә әсбап. Сез 250 миллионнан да артыграк яшьтәге дымлы һәм салкын кантарларга кагылачаксыз! Бу үзе бер могҗиза! Һәм, ниһаять, өченчедән, мәгарәдән чыгып, көн яктысын күргәч, сез җир өстендә кояш нурлары астында яшәүнең чыннан да нинди зур бәхет икәнен аңларсыз!

НИЧЕК БАРЫРГА:

Казаннан М-7 трассасы буйлап Яр Чаллыга кадәр барыгыз. Аннары күрсәткечләр буенча – Сарман авылына. Район үзәгенә кергәч, төньяк-көнчыгыш юнәлешендә «Бакыр Тау» күрсәткеченә кадәр. Тагын берничә йөз метр – һәм сез тиешле урында!





Фото: Александр Ефремов

ДИҢГЕЗГӘ КАРАГАН ӨЯЗ ШӘҺӘРЕ

Мегаполислар ыгы-зыгысыннан арган кешеләргә «Татарстан» өяз шәһәренә сәяхәткә чыгарга тәкъдим итә. Тынлыкка, ләкин аулак почмакка түгел. Бүгенге көндә яшәп калган үткәннәргә. Республика картасында әнә шундый урын бар. Исеме дә җылы, йомшак – Тәтеш дип атала ул. Сәяхәтчеләр, балык яратучылар һәм гашыйк романтиклар өчен чын җәннәт.

Тәтеш урамнары тоташ истәлекле урыннардан тора: XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында сәүдәгәр Крупиннар, Серебряковлар, Колсановлар, Полосухиннар төзегән йортлар… Хәтта, махсус экскурсион әзерлегегез булмыйча, кайсының кем йорты икәнен аера алмасагыз да, аларны күрүдән алган эстетик ләззәт кимемәячәк. Шулай ук текә ярдан 400 басмалы озын агач баскыч белән дулкыннарга кадәр үк төшкәндәге гаҗәеп Идел елгасы манзарасы да – онытылмаслык. Идел-су монда диңгез кебек, ярлары күренми, әмма бер диңгез дә матурлыгы, киңлеге, тигез су өслеге ягыннан аның белән ярыша алмый.

Тәтеш – балыклы шәһәрчек. Балыкчылар, һичшиксез, мондагы биниһая зур уңыш белән мактана ала: 1921 елда тотылган искиткеч зур ак балыкка натураль зурлыгында куелган һәйкәл – үзе бер горурлык. Эрнест Хемингуэй әсәрендә тасвирланырга лаеклы вакыйга бу! Беләсегез килсә, ул чакта Иделдән 960 кг авырлыктагы балык тотылган! Аның эченнән 197 кг уылдык, бер капчык кысла, шамбы, чөгә балыклары чыккан…

Хәзер Иделдә андый ак балыклар инде күренми. Аның каравы, килгән кешеләр өчен балык кибетендә ысланган табан балыгын, чехонь, бёрш дигән киптерелгән вак балыкны

Фото: Алёна Кутыркина, Александр Гайнутдинов

һәм башка Идел деликатесларын сатып алу мөмкинлеге бар. Кибет киштәсеннән баш әйләндергеч ысланган-тозланган-киптерелгән балык исләре аңкып тора. «Тәтешкә килеп тә, аннан төрле зурлыктагы балыклар тартмасын алып китмәү – гомумән, яхшы түгел», – дип исәпли җирле халык. Ә кунаклар үзләрен бик яхшы тота – автомобиль багажникларын Идел күчтәнәчләре белән тутырмыйча китми.

Әгәр дә сез романтиклар сафыннан икән, өяз шәһәреннән киткәнче, Долгая Полянага – барыня Елизавета Молоствова утарына кереп чыгарга онытмагыз. Аның матур, әмма моңсу риваятькә охшаган катлаулы тормыш тарихы турында тыңлагыз. Йөзьяшәр карагайлар аллеясеннән үтегез, ул – Тәтеш өязе дворяннары җитәкчесе Владимир Германович Молоствовның кәләше Елизаветага туй бүләге булган. Бер-берсен һәм үз йортларын яраткан бу ир белән хатын тарафыннан төзелгән кечкенә җәннәт бакчасына үз бәягезне бирегез. Иренмичә, кыргыйлашкан алма бакчасы аша озын юлдан Идел буена төшегез – кайчандыр аның чәчәк аткан, җимеш биргән чакларын күз алдына китерегез... Алмалардан кайнатма һәм шәраб ясаганнар. Каскадлы буаларда форель балыгы һәм пар аккошлар йөзгән... Ә яшь барыня шигырьләр язган, хәзер алар утарда романслар булып яңгырый...

В этом мире мне жаль
Нежной ласки твоей,
Удивленного милого взора,
Золотого заката средь тихих полей,
Над заснувшей землей звёзд узора...

НИЧЕК БАРЫРГА:

Казаннан М7 трассасы буйлап барырга, аннан М241 трассасына борылырга. Тәтешкә кадәр башкаладан – 149 чакрым.













КЕМ КАЯ, ә МИН – АВЫЛГА!

Йортның хуҗасы, карт бабам, әле генә монда иде. Шыгырдап торган шушы арбада бер капчык бодай алып кайтты да, аны тарттырып, он итте. Аннары мунча керде. Ис тиеп, чак кына үлми калды. Әбинең сукрануына карамастан, оетып куйган куе салкын катыкны агач чиләгеннән үк чөмерде...

Автор:
Әскәр Сабиров

Карт бабам күптән юк инде. Яңгырлардан каралган бүрәнә өйләр, авыл юлларында таралып яткан ватык арбалар, татар авыллары буйлап җыелган борынгы иске кирәк-яраклар миндә генә түгел, башкаларда да гаҗәеп хисләр уятадыр: хуҗалары әле яңа гына китеп барган кебек. Әле генә кыстыбый пешергәннәр, ат дирбияләрен төзәткәннәр, бишек тирбәткәннәр, тимерче алачыгында эшләгәннәр...

Тукта, тукта, ни өчен гаҗәеп, ди? Биредә, Исәк авылындагы ачык һавадагы «Татар авылы» этнография музеенда, бөтен әйберләр дә чын, һәркайсының үз тарихы бар. Өйләр, мунча, сарайлар – берсе дә ялтыратып куелган ясалма муляж түгел. Кара мунчада – стеналарына сеңгән корым һәм төтен исе. Иске тегермән ташларында – он тузаны. Өй эчендә суынып та өлгермәгән мич, учак өстендә – карасу төтен эзләре...

Өстәвенә, бу байлыкны күрергә генә түгел, тотып карарга да була. Йон эрли торган кабаны да, киез итек басу калыбын да. Хәтта гигант тегермәннең түшәмендә үк урнашкан тешле агач тәгәрмәчләрне дә. Кулың белән кагылуга – бабайларның гасырлар буе тупланган энергетикасы сиңа көч өстәгәндәй тоела.

«Татар авылы» – шәхси музей. Монда тупланган бөтен хәзинәне бер кеше – Олы Шырдан авылында яшәүче укытучы Миңнедамир Камалетдинов җыйган. Күрше төбәкләрдән дә, чит илдән дә туристлар кызыксынып килә торган бу уникаль комплексны саклау һәм үстерү мәшәкате дә – аның җилкәсендә. Урта хәлле гаиләнеке кебек җиһазланган өй ишеге өстенә чит ил кешеләре өчен инглиз телендә язу эленгән: «Аяк киемнәрегезне сызык артында калдырырга», – диелгән. Мөгаен, бу монда килгән кешеләр өчен бердәнбер җитди чикләүдер. Әмма монда инде, гафу итегез, традиция: татар авылларында аяк киемен һәрвакыт бусага артында калдырганнар...

Камалетдинов мондый мөмкин булмаган эшне ничек башкарып чыга алган соң? Үзе әйтүенчә, монда идея «гаепле». Сиксәненче еллар ахырында ул Козмодемьянскидагы искиткеч этнография музеена барып эләккән. Кунакларны анда мари халык җыр-биюләре белән каршы алганнар, милли эчемлекләр белән сыйлаганнар. Әмма хуҗаларның бик яратып төзегән мари авылы күренеше аны сокландырып кына калмаган, дәртләндереп тә җибәргән. Миңнедамир беренче тапкыр үз алдына: «Ә нигә бездә, Татарстанда, хәзергә кадәр мондый әйбер юк? Ә бит ике-өч дистә елдан безнең бабаларыбызның татар авылында ничек яшәгәннәре турында истәлекләр генә калачак», – дигән сорау куйган. Әлеге идеясе белән Мәдәният министрлыгына барган – хупламаганнар. Дәүләт булышмый икән, нишләргә? Дөрес, үз көчеңә таянырга кала.

«Татар авылы»н ул 2010 елда гына ача алган – идея белән «авыру» егерме елдан артык вакытка сузылган, бу вакыт эчендә ул акча туплаган, экспонатлар җыйган һәм, өметен җуймыйча, түрәләрдән ярдәм эзләгән. Юкка булып чыккан. Элекке мәдәният министрларының берсе әйткән сүзләр әлегәчә хәтерендә героебызның. Миңнедамирның этнография музее ачарга теләвен һәм ярдәм көткәнен ишеткәч, ул ризасызлык белән:

– Беләсеңме, бу хәзер актуаль түгел. Иң яхшысы, атлар сатып ал да шуларга балаларны утыртып йөрт. Менә бу, һичшиксез, барачак!

Бигрәк беркатлы җавап. Ул вакытта Миңнедамир Биектау районында сакланып калган бәһасез раритет – сугыш вакытында, җиде дистә ел элек (!) салынган агач тегермән турында ишеткән була. Тегермәнне бүрәнәсен бүрәнәгә сүтеп, Исакка алып кайталар да, тәртип белән, яңа урында торгызып куялар. Хәтта механизмын да төзәтәләр, ул эшли булып чыга!

Ә чүлмәкче өе Балтач районы Чепья авылыннан күчеп утырган. Монда барысы да йөз ел элек булганча сакланган. Зур мич, сәке, балчык савыт-саба, бүрәнә стенада чабаталар эленеп тора, сандык һәм традицион татар бизәкле читекләр – аларын кай-



чандыр Миңнедамирның үз әбисе үк киеп йөргән.

– Ә сез татар миченең русныкыннан нәрсә белән аерылганын беләсезме? – дип, хәйләкәр генә сорау бирә Камалетдинов. – Белмисезме? Русларда мич авызы ике тапкыр киңрәк булган, чөнки анда ризык пешереп кенә калмаганнар, эченә кереп юынганнар да. Миңа бер турист ханым сөйләде, Ярославль өлкәсеннән. Ерак балачагында әбисенең аны ничек мичтә юындырганын искә алып...

Татар һәм рус көнкүреше монда адым саен бер-берсенә үрелеп бара, хәзерге тормыштагы кебек үк. Тимерче өе рус стилендә төзелгән, дип аңлата Миңнедамир. Бу хата түгел. Татар авылларында тимерче булып гел руслар эшләгән. Иван Грозный заманыннан ук шулай килгән – хакимнәр буйсындырылган Казан ханлыгы халкы корал кояр дип курыккан һәм аларга металл белән эшләүне тыйган...

Сүз уңаеннан, татар авылы музее үзе дә рус авылында урнашкан. Һәм бу берәүне дә гаҗәпләндерми. Өстәвенә, кайчандыр шушы тирәдә татар авылы да булган, диләр. Казан алынганнан соң, анда яшәүчеләрнең бер өлеше Норлатка күчеп киткән.

Хәзер Камалетдинов комплекс территориясендә мәчет төзи. Унҗиденче гасырдагы бер кадак та кулланмыйча салынган агач гыйбадәтханә проектын аңа үз вакытында архитектор Нияз Халитов бүләк иткән булган.

Әлбәттә инде ачык һавадагы бу гаҗәеп музей экспонатларының чын бәясен галимнәр генә билгели ала. Әмма бер нәрсә ачык: Камалетдинов һәм аның музее – безнең күптән түгелге һәм ерактагы үткәннәребезне күрү һәм тотып карау мөмкинлеге ул. Һәм аны яңа буыннар өчен саклап калу да.

...Кадерле кунакларны ул еш кына үзе каршылый. Тальян гармун һәм «Туган тел» җыры белән, милли киемнән. Мастер-класслар үткәрә, аларда данлыклы Шырдан катыгы оетырга, кыстыбый пешерергә, балчык савыт-саба ясарга өйрәнәләр. Ә өйләр арасында, чирәмдә, тавыклар кыткылдап йөри. Ишегалдына илтүче капкаларны тәкәббер казлар саклый. Утарда – сарыклар, кәҗәләр... Барысы да моннан нибары йөз еллап элек кенә булган гадәти татар авылындагыча.

НИЧЕК БАРЫРГА:

Казаннан М7 трассасы буйлап Мәскәү юнәлешендә – Исак (Исакова) авылына кадәр.







PRESSA

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Балаларны **НИЧЕК** ирекле итеп тәрбияләргә

Сладковский оркестры Британияне **НИЧЕК** үзенә каратты

Авылларга кино карау культурасын **НИЧЕК** кайтарырга

Өлкәннәрнең **НИ ӨЧЕН** пенсиягә китәселәре килми

ИРЕКЛЕЛӘР БУЫНЫ

Павел Шмаков, СОлНЦе мәктәбен оештыручы һәм аның директоры, балаларны ничек чыннан да иректе итеп тәрбияләү турында. Һәм моны эшләүнең кирәкме-юкмы икәнлеге турында.

Мин 70 нче еллар баласы. Тоташ ялган чорында үскән «югалган» буын. Ул чакта, мәсәлән, кибетләрдә берни дә юк иде, әмма шул ук вакытта Кремльдәге югары чиннар өчен махсус кибетләр системасы эшләде. Әтисе шуннан тәэмин ителә торган дустым бар иде минем. Кайбер ризыкларны мин беренче тапкыр аларның өендә күрдем. Шундый гаделсезлек турында Казан университеты каршындагы «Квант» җәйге физика-математика мәктәбе директоры белән сөйләшергә булдым. Валентина Алексеевна партиянең ихлас әгъзасы иде. «Махсус кибетләр – бу әйбәт түгел! Әйдәгез, бу хакта язабыз!» – дидем мин аңа. Ә ул миңа: «Әйе, Паша, бу начар, ләкин мин моның белән көрәшсәм, миңа безнең мәктәпне үстерергә ирек бирмәячәкләр», – дип җавап кайтарды... Аннары 90 нчы еллар килеп җитте, ул чакта өстебезгә ишелеп төшкән ирек белән нәрсә эшләргә мөмкин икәнен беркем белмәде. Кемдер сәүдә итәргә, акча эшләргә кереште, кемдер – машиналар яндырырга. Балалар ул чакта ничектер йомык иделәр. Җинаятьчел төркемнәрдәге хулиганнар белән дә хәтта өлкәннәр идарә итте... Һәм кинәт шушы соңгы биш ел эчендә килеп туган көчле дулкынлануга шаһит булдык!

Аларга әле унбиш кенә, ә алар инде Яшь гвардия сафларына баса, яки Навальныйны яклап митингларга чыга, ә кемдер илдән үк китеп бара – аларның үз фикере барлыкка килгән! 2013 елда безнең мәктәп ябылу алдында калгач, шушы балалар аны яклады. Һәм, 83 мең имза җыеп, аны саклап та калдылар. Алар бернидән дә курыкмады. Әле күптән түгелгеләре курка иде, ә болары инде – юк. Нигә болай булып чыкты, дисезме? Минемчә, моның алдыннан җинаятьчелекне почмакка китереп кыскан, ә дөреслек өчен массачыл репрессияләр көтмәгән шактый озын тәртип чоры булып алды...

Педагог һәм директор буларак, бу минем өчен менә ничек чагыла: элек безнең мәктәп укучылары белән, яхшымы-начармы, идарә итеп була иде, ә бүген – юк диярлек. Минем өчен һәр көн сынауга әверелә. Һәм бу бик авыр. Күптән түгел бер укучы белән минем кабинетымда сөйләшәбез. Ишек ачык, коридорда классташ кызы көтеп тора. Бераз гына ул кызга да туры килгән темага кагылабыз. Һәм бу кыз нишли? Тәкәллефсез генә кабинетка килеп керә дә малайга: «Булды! Киттек моннан!» – ди. Ул курыкмый. Әмма эш бит монда тагын менә нәрсәдә: **ниндидер моментта балалар ирек һәм теләсә нәрсә эшләү мөмкинлеге арасындагы чикне уздылар. Һәм без, өлкәннәр, алар белән бергә ул чикне күрергә тиеш.**

Минем өчен ирек ул – башкаларга комачауламаслык булганда гына ирек, менә шул чакта мин үзем теләгәнне эшлим. Ягъни «берәүнең ирегә башка кешенең ирегә башланган урында чикләнә». Ә балалар моны ничек аңлый? Аларга карыйм да шуңа инанам – берничек тә. Аларны моңа өйрәтергә кирәк. Һәм без уйный башлыйбыз. **Барьерлар куябыз: монысы һәм монысы – ярамый. Ошамыймы? Башкасына ирешегез!** Шул чакта балалар чын, яхшы мәктәп Советы төзеделәр. Беренче утырышы быел яз көне булды. Аның тәүге карары мондый иде: «Моннан соң Совет утырышларына җиденче класстан түбәнрәк укучылар кертелми». Алар башкаларның хокукларын чикләгәннәрен, туктарга һәм алга таба уйларга кирәклеген әлегә аңламыйлар. Чөнки алтынчы класслар да баш күтәрергә мөмкин бит! Ярар, күтәрелсеннәр, ә бит ирекнең бәясе – базардагы кебек – үзеннән үзе көйләнә.

Дөньяда тик торганнан бар нәрсәне дә рөхсәт итәргә ярамый, әмма безнең мәктәптә иң мөһиме – үз хокукларың өчен көрәшү һәм дөресен сөйләү рөхсәт ителә. Тик менә нинди парадокс! Безнең балалар гамәлләрендә иректе, ә менә дөресен сөйләү – алар өчен проблема. Атна саен узган линейкаларда без төрле проблемаларны тикшерә алабыз. Әмма ул турыда бик сирәкләр генә әйтә. Мин яңа чара уйлап таптым: кем проблеманы ачыктан-ачык әйтә алмый, ул язып бирә ала. Аноним рәвештә түгел, ләкин бала «К» хәрефе куйса, бу «конфеденциаль» дигән сүз, мин аның фамилиясен әйтмәячәкмен. Менә шул, хәзер бу хәрефне аларның өчтән икесе куя. Алар үзләренең ни уйлаганын хәтта үзләренең яшьтәшләренә дә, хәтта күп нәрсә рөхсәт ителгән безнең мәктәптә дә (!) ачыктан-ачык әйтә алмый. Димәк аларда сүз ирегән тою юк. Безнең бик күп директорларда да булмаган кебек – татар теле белән килеп чыккан вазгыять әнә шуны күрсәтте. Миңа татар телен яклаган өчен рәхмәт белдереп хат яза алалар, ә бер-берсе белән ачыктан-ачык сөйләшергә куркалар... Сүз ирегән тою хисе кирәкме соң? Мөгаен, кырыс дөреслекне әйтми торган укучылар – уңайлы укучылардыр. Ә минем өчен монда ниндидер гаделсезлек бар, мин моны кабул итә алмыйм. Әйтик, ниндидер начар хәл килеп чыкты ди, алар эндәшмәячәкме?

Бездә бер кызыклы вакыйга булды. Балалар әшәке сүзләр белән сөйләшә: юк, сүгенә, димим, нәкъ

менә сөйләшә. Без бу теманы тикшерә башладык, ә бер укучы кыз норматив булмаган лексика буенча тикшеренү эше язды. Ул үзенең элеккеге мәктәбенә барып, тәнәфестә балаларның «х» хәрефенә башланган сүзне, аннары башкаларын ничә тапкыр әйтүләрен язып алып кайтты. Шушы ук эшне безнең мәктәптә дә эшләде. Безнең мәктәп укучыларының сүгенү сүзләрен җиде тапкыр кимрәк куллануы ачыкланды. Бу хәлне тикшерү алар өчен бик кызыклы булып чыкты, һәм моннан соң мәктәптә сүгенү сүзләрен куллану тагын да кимеде. Нәрсәне булса да тыю (табу) алынгач, проблема юкка чыга. Тик менә шунысы кызык: сугышу, бер-береңне котырту, караклык кебек проблемаларны балалар бик нечкә тоялар, ә гаделлек һәм дөреслек проблемасы алар өчен бөтенләй юк.

Өч ел элек без үз мәктәбебезгә бишенче классларны кабул итә башладык. Унбер яшь – әле ул бик үк аңлы яшь түгел. Алар башлары белән көрткә дә чума, бер-берсенең аяк киемнәрен дә яшереп куя, су чәчрәтеп тә уйный, әфлисун кабыклары да атыша... Бөтенесе кемгәдер берәүгә каршы түгел, ә бәлки һәркем һәркемгә каршы, яки бөтенесе бөтенесенә каршы. Шул дәрәҗәгә барып җитте ки, гади генә хулиганлык аркасында бер малай мәктәптән китеп барды. Ул бәлки китмәгән дә булыр иде, әмма аның әнисе, укытучылар яки ата-аналар янына киләсе урынга, балалар белән сугышырга уйлады. Ә өлкән кешенең балалар белән сугышуы һәрвакыт җиңелү белән тәмамлана, балалар көчлерәк! Монда без, укытучылар да, ата-аналар да, балалар да, һәм бу әни дә – барыбыз да хаклы түгел идек. **Мондый эчке ирек һәм кыюлыкны ничек тиешле кысага кертергә? Аның рецептын без бер елдан соң гына таптык.** Ул сәяхәт булып чыкты! Кыска гына сәяхәт – ата-аналар белән бергә, ләкин төн кунып, утыннар, казаннар һәм җырлар белән. Анда кечүләрдә бер-береңә булышырга кирәк. Походта әле тагын кызлар рюкзакларындагы авыр әйберләрне малайларныкына күчерергә була. Малайларның баштарак ачулары килсә дә, соңыннан алар үз-үзләре белән горурлана башлый. Менә шундый табигый мохиттә кешелек сыйфатлары формалаша, китаплар арасында алар кайвакыт онытылып та куя бит. Һәм менә бу ирекле бишенчеләр үсә, шәхесләргә әверелә, һәм яңадан мондый башбирмәс балалар җәмгыяте белән уртак тел табу өчен безгә, караңгыда капшанып дигәндәй, яңа ысуллар эзләргә туры килә. Балаларның «сукыр тәкә» уеныннардагы кебек, күзләр бәйле, ә табарга кирәк.

Әле 2015 елда ук СОлНЦе мәктәбе БДИ нәтиҗәләре буенча шәһәр рейтингында беренче урыннар алды, безнең укучыбыз биология буенча бөтендөнья олимпиадасында җиңеп чыкты. Без шулай ук бүген дә рейтингның әйдәп баручылары арасында, ләкин беренче дә түгел, икенче дә түгел, өченче дә түгел, һәм бу тенденция миңа ошамый. Безнең мәктәптә без гадел билгеләр куябыз, әмма икеләләр өчен балаларны ачуланмыйбыз һәм укырга мәҗбүр итмибез. Кызганыч, **унынчы класска алар ялкауланалар. Ә БДИдан соң минем янга киләләр дә: «Павел Анатольевич, ник сез безне укырга мәҗбүр итмәдегез?!» – диләр. Димәк, бу ирек белән барысы да бик гади генә түгел.**

Киләсе уку елында безнең бик ирекле мәктәптә атнага бер көн мәктәп формасыннан йөрү кертелә. Дәресләргә соңга калган өчен шулай ук җәза биреләчәк. Берничә кисәтү җитә – мәктәпкә килеп гадәттәгечә укудан гаиләдә укуга «очуың» ихтимал. Ягъни, без куып чыгармыйбыз – теләсәгез, укыгыз бездә, тик башка хокуклар белән. Боларның һәммәсендә бер нюанс бар: **кемнең укуга хирыслыгы әллә каян күренеп тора, аңа кайбер кагыйдәләрне бозу рөхсәт ителә. Алар моңа ирешә алган.** Сез, мөгаен, бу 70 нче еллардагы өстенлекләләр өчен кибетләр тоту юлы түгелме, дип сорарсыз. Юк, андый юл түгел. Менә сезгә чагыштыру өчен бер мисал. Миңа бер күренекле прокурор шалтырата: «Күршемнең улын кабул итегез әле – ул бик башлы малай», – ди. «Миңа моңа ианырга кирәк», – дим. «Мин бит кем икәнлегемне әйттем», – дигән җавап ишетәм. Уйлап карагыз, ул һичшиксез кемдер тарафыннан кичекмәстән үтәлергә тиешле тәкъдим ясау өчен үзенең вазыйфасы җитә дип ышана. Менә ул «махсус кибетләр» системасы – блат системасы! Мин шуның белән көрәшәм.

Ихтимал, минем бара торган һәм киләчәктә дә барырга җыенган юлым идеаль түгелдер. «Өстенлекләләр» барлыкка килү – бу мәктәпнең концептуаль системасы түгел, һәм ул андый булмаячак. Әлеге вазгыятьтән чыгарбыз, һәм бер елдан соң безнең мөнәсәбәтебез башка булыр. Әйе, без моңа кадәр һәрвакыт булган глобаль иректән чигенәбез. Әмма мин ниндидер матур принципны – әгәр ул эшләми икән – дәвам итү ягында түгел. **Идеалда нәрсәгә ирешергә телим соң? Безнең балаларда ирекне тоюның җаваплылык хисе белән җиңел ярашуына.** Кайбер нәрсәләрнең – әйтик, гадел хезмәтнең – зарурилыгын эчтән (тирәннән) аңлауларына. Яраткан өлкәләрендә югары нәтиҗәләргә ирешүләренә. Конкрет бер хакимгә түгел, ә гасырлар буена җыелып килгән әхлакый кыйммәтләргә юнәлеш тотуларына. Үзләрендәге ниндидер бер өлешне – үз теләкләре белән һәм сөенеп – җәмгыятькә хезмәт итүгә багышлауларына. Менә шул чакта алар чыннан да ирекле булачак. Ничек моңа ирешергә? Бу сорауга минем әле төгәл җавабым юк – мин туктаусыз эзләнүдә яшим...

АЛЕКСАНДР СЛАДКОВСКИЙ: «БЕЗ БЕРӘҮНЕ ДӘ ШАККАТЫРЫРГА ОМТЫЛМЫЙБЫЗ, Ә БАРЫ НАМУС БЕЛӘН КӨНДӘЛЕК ЭШЕБЕЗНЕ ГЕНӘ БАШКАРАБЫЗ»

«...Моны Россия оркестры уйнаганына ышанып та булмый» – «1, 5, 9 нчы симфонияләр. Густав Малер. Александр Сладковский. Кирилл Кондрашин» дискына бәяләмәсен Бөекбританиядәге Musical Opinion журналының музыка тәнкыйтьчесе Грегор Тасси әнә шул сүзләр белән тәмамлый. Әлеге рецензияне күптән түгел Бөекбританиянең абруйлы Musicweb музыка басмасы дөньяга чыгарды, бу исә – Татарстан мәдәнияте өчен горурланырлык вакыйга. Ә республиканың Дәүләт симфоник оркестры өчен – яуланган яңа үр. Ә аннан соң нәрсә? Бу хакта «Татарстан» журналы Россиянең халык артисты, оркестрның сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижеры Александр Сладковский белән гәп корырга булды.

– Атаклы совет дирижеры Натан Рахлин Густав Малер симфонияләре турында «Бу музыкага һәр коллективның да теше үтәрлек түгел» дигән. Ә сез исә Татарстан оркестрының бик күп нәрсәгә көч-куәте җитүен расладыгыз. Чираттагы бу җиңү сезнең өчен нинди мәгънәгә ия?

– Минем өчен ул бер генә нәрсә аңлата. Барлык инвестицияләр һәм ниятләр бушка китмәгән, һәм сигез ел элек бу эшемә керешкәндә вәгъдә иткән бөтен нәрсәне, азмы-күпме булса да, иң югары халыкара дәрәҗәдә тормышка ашыра алганмын, дигән сүз бу. Грегор Тасси мәкаләсе дә шуңа дәлил.

– Шуны да телгә алу урынлы булыр: оркестрның дискларына һәм концертларына бәяләмәләр саны соңгы өч айда гына да дистәгә якын булды. Әйтик, әле күптән түгел генә бер инглиз тәнкыйтьчесе Шостакович симфониясенең оркестр башкаруындагы язмасын «иң яхшы язма» дигән сыйфатламага лаек тапты. Бөек композиторларның тагын кайсы сезнең өчен чираттагы илһам чыганагы булыр икән?

– Мондый дисклар – эшебезнең аерылгысыз бер өлеше. Теләсә кайсы оркестр вакыт елъязмасында үз эзен калдыра, ә бүген исә мондый эз санлы технологияләр белән белдерелә. Безне тарихка кертеп калдыра торган нәрсә ул. Ни кызганыч, Натан Рахлин җитәкчелегендәге Татарстан оркестры башкаруында язмалар бик аз калган, гомумән, андыйлар калган булса әле. Бу бик аяныч хәл. Фуат Мансуров чорыннан да бернәрсә дә сакланмаган диярлек, һәрхәлдә, оркестрның дистә еллар элек нинди

булганын безгә бүген күрсәтеп бирердәе, искә төшерердәе юк. Ә инде чираттагы илһам бирүче көйъязарга килгәндә, анысын киләчәк күрсәтер. Даһи музыка шулкадәр күп ки, аны яздырып кына түгел, уйнап та бетермәслек! Иң мөһиме, башкарыр кешеләр булсын.

– Сез оркестрны җитәкләгән сигез елда шаккаткыч санда премьералар уйналды. Репертуар дистәләрчә генә түгел, йөзләрчә әсәр белән баетылды. Шуларның туксанга якыны – Татарстан авторларының иҗат җимешләре. Бу тема сезнең өчен никадәр мөһим икәнлеге хакында шактый еш телгә алдыгыз. Әлеге юнәлешне ничек үстерергә ниятлисез?

– Композиторлык мәктәбе үсешенә мин турыдан-туры йогынты ясамыйм. Һәм бу яктан карагандa, берниндн планнарым да юк. Мин нишли алам? Татарстан классиклары һәм яшь композиторларның әсәрләре буенча концертлар куеп, классик музыка иҗат итәргә теләгән сәнгатькәрләрнең хыялларына канат куйсам гына инде. Яшь композиторлар белән һәрвакыт эш алып барам, аларга язарга, иҗат итәргә тәкъдим итәм. Әле яңа гына иҗат ителгән көйләрне башкарган чакларыбыз шактый.

– Санта-Чечилия Милли академиясе оркестры белән җитәкчелек итү мөмкинлегенә күренекле дирижерлар зур хөрмәт билгесе итеп карый. Сезгә исә андый бәхет инде беренче генә тәтеми. Шундый атаклы коллектив белән эшләү Татарстан дәүләт оркестрының дирижерлык пультында башкарган хезмәтегездән никадәр аерыла? Анда нииндидер үзенчәлек бармы?

– Әлбәттә, бар. Татарстан оркестры белән эшләгәндә, ни дисәң дә, мин үз өемдә, башка коллектив белән булганда – мин инде кунакта. Ләкин кунакка чакыралар икән, димәк, хәлләр бик начар түгел диган сүз, димәк, барысы да шәп! Үзебезнең оркестр белән генә түгел, Россиянең башка алдынгы коллективлары, Көнбатышның бик яхшы оркестрлары белән бергә эшләү мөмкинлеге дә булуына бик шатмын. Алда Тайвань һәм Япония оркестрлары белән бәйле зур планнар бар. Бу – хезмәтемнең бик мөһим бер юнәлеше, чөнки теләсә кайсы оркестрның пультында мин дирижер Александр Сладковский гына түгел, ә Татарстан Дәүләт оркестрының сәнгать җитәкчесе дә!

> **– Һәрвакыттагыча, профессионализм, осталык һәм оркестрыбызның энергетикасы белән яулаячакбыз. Коллективыбызның даны Татарстаннан бик еракларга күптән таралды инде, һәм аның белән кызыксыну көннән-көн көчәя генә бара.**

– Күптән түгел күренекле пианист Михаил Плетнев җитәкчелегендәге Россия милли оркестры белән Кытайда гастрольләрдә булып кайттыгыз. Әлеге сәфәрдә үзегез өчен ни ачтыгыз?

– Мин үзем өчен тагын бер тапкыр Михаил Плетневны ачтым. Тиңдәшсез музыкант һәм шәхес ул. Миңа ике атна аның оркестры белән дирижер һәм пианист буларак эшләү бәхете тәтеде. Тагын бер ачышым – Кытайдагы провинция башкалалары булган эре шәһәрләрнең һәрберсендә искиткеч актив төзелә торган зур заллар. Классик музыкага карата шундый кызыксынуны һәм шуңа бәйле шаккаткыч үсешне күзәтү мөмкинлегe туды. Бу яктан Кытай Япониядән үрнәк ала, хәзер японнар иленд̆ә чыгыш ясау теләсә кайсы музыкант өчен бик зур җиңү. Японияиең икътисад һәм мәгърифәт үсеше үзе үк күп нәрсә турында сөйли. Японнар классик музыканы бик югары бәяли, аны бик шәп аңлый. Аларда бу музыка – тормышның бер тарафы, өстәвенә, балачактан ук башланган тарафы. Һәм японнар мондый алгарышка, күбесенчә, концерт заллары төзү бәрабәренә ирешә.

– Ел ахырында Кытайга тагын бер сәфәр кыларга ниятлисез, бу юлы инде – Татарстан Республикасының Дәүләт оркестры белән. Чин дәүләтен ничек яуламакчы буласыз?

– Һәрвакыттагыча, Кытай тамашачысын профессионализм, осталык һәм оркестрыбызның энергетикасы белән яулаячакбыз. Коллективыбызның даны Татарстаннан бик еракларга күптән таралды инде, һәм аның белән кызыксыну көннән-көн көчәя генә бара. Болар барсы да – минем, оркестр музыкантларының, офис хезмәткәрләренең бер-беребез белән килешеп зур эш башкаруыбыз, уртак тырышлыгыбыз нәтиҗәсе.

– Яуланган үрне саклап тоту югары менүгә караганда да авырракгыр, чөнки уңышның икенче ягы да бар бит – сездән тагын да зуррак җиңүләр көтәләр. Сәнгать сөючеләрне яңа, 53 нче сезонда ни белән шаккатырырга телисез?

– Без оркестрның яңгыраш офыкларын, амплитудаларын киңәйтәбез, тавышның сыйфатын яхшыртабыз. Мондый хезмәтнең нәтиҗәсе берничә яссылыкта чагыла: оркестрны нинди фестивальләргә һәм кайсы концерт залларына чакыралар, ул тавыш яздыру компанияләренең кайсылары белән эш йөртә, елына ничә концерт бирә. Һәм, әлбәттә, иң мөһиме – нинди солистлар белән чыгыш ясый. Монда динамиканы күзәтү бик җиңел. Арттырып әйтү түгел – әлеге динамика гаять көчле. Бу хакта хәзер кем генә сүз әйтми калмаган икән! Шуңа да канәгатьлек хисе белән белдерәм: без берәүне дә шаккатырырга омтылмыйбыз, ә бары намус белән көндәлек эшебезне генә башкарабыз. Һәм һәр көнебез яңабаштан, ак кәгазьдән башлана.

Яңа сезон, инде гадәттәгечә, безнең өчен картадагы яңа ноктлар һәм яуланган абруйлы заллар белән билгеләнәчәк. Шуңа күрә, әлбәттә, без Казанда гына чыгыш ясап калмаячакбыз. Күренекле вакыйгаларның берсе – Татарстан Республикасы Дәүләт симфоник оркестрының Мәскәү филармониясендә үз абонементы. Концертлар 2019 елның гыйнвар, февраль һәм март айларына планлаштырылган. Бу әле оркестрның башкаладагы бөтен чыгышлары да түгел. Без шулай ук яңа гына ачылган «Зарядье» паркының концерт мәйданчыгында да, Чайковский исемендәге Мәскәү дәүләт консерваториясенең Зур залында да уйнаячакбыз. Тагын Денис Мацуевның Иркутскида узачак «Йолдызлар Байкалда» халыкара музыка фестивалендә, Санкт-Петербургтагы Мария театрының «Мариинка-3» залында, Тамбовта Рахманинов исемендәге халыкара музыка фестивалендә чыгыш ясаячакбыз... Моннан тыш, безне Франциядә дүрт концертта, дөньякүләм танылган Ла-Рок-д'Антерон фортепиано музыкасы фестивалендә, тагын әле Франциядә һәм Япониядә ел саен уздырыла торган бик колачлы La Folle Journée («Шашкан көн») классик музыка фестивалендә катнашырга чакырдылар.

Әңгәмәдәш – Анна Белозерова

МИЛӘҮШӘ АЙТУГАНОВАДАН БОРАЙ БӘЛЕШЕ

«Татарстан» журналының «Аш-су бүлмәсе»ндә бүген... кинодагы кебек. Татар киносындагы кебек. Чөнки «Татарстан»ның кабатланмас алъяпкычын «Татаркино» ДБМУ директоры Миләүшә Ләбиб кызы Айтуганова киде. Һәм ул без хәтта кинода да күрмәгән ризык – борай бәлеше пешерә.

Авторлар:
Татьяна Вафина

Татьяна Лескова

ИҢ ОСТА ӘЗЕРЛИ ТОРГАН СЫЕМ

– Бу чып-чын татар милли ризыгы, – дип таныштыра булачак бәлеше белән Миләүшә Айтуганова. – Гадәттә бәлешне бәрәңге белән пешерәләр, тик борайлысы файдалырак. Һәм, минемчә, тәмлерәк тә. Чөнки бодайның бу сорты радиациягә, әйләнә-тирә мохитнең тискәре тәэсирләренә каршы тору сәләте белән билгеле. Борай бөртекләре экологик яктан чиста, ник дигәндә, аларның дүрт катлы тышчасы бернинди зарарлы матдәне дә үткәрми. Бу ризыкны беренче тапкыр бик күптән бер шифаханәдә ашаган идем, һәм ул миңа шундый ошады ки, иң оста әзерли торган, «фирменный» сыема әйләнде. Безгә кунаклар килсә, гел шул бәлешне пешерүемне сорыйлар. Мин аларны шуның белән сыйлыйм да.

РОМАНТИК ТАБЫН

Камыр әзерли башлагач, Миләүшә Айтугановaның бу эштә дә үз сере бар икәнен ачыкладык.

– Бу камыр каймак белән ясала. Йомырка белән он салабыз. Бөтен булганы шул! Агач кашык белән болгатабыз. Мин агач әйберләр яратам – калаклар, такталар, тәлинкәләр...

Гадәттә, бәлеш зур була, ләкин бүген без ике кечкенәрәк бәлеш ясыйбыз, шул рәвешле әлеге ризыгыбызга ниндидер романтик төсмер биреп җибәрербез. Аларны кемдер икәү ашаячак дип күз алдына китерик...

– ... «Татарстан» һәм «Татаркино».

– Ә аннары сезнең укучыларыгыз һәм безнең тамашачыларыбыз да дип өметләнәм...

КАННЫ ФЕСТИВАЛЕ ЕРАК ОФЫКТА ТҮГЕЛ

– Татарстан киносының тамашачысы күпме?

– Хәзер безнең Татарстан киносында гаять кызыклы чор. Бик куәтле алга китеш күзәтелә, һәм кичекмәстән хәл ителергә тиешле мәсьәләләр дә бар.

«Татаркино» директоры буларак иң беренче эшем шул булды: Чаллы һәм Бөгелмә зонасының бөтен муниципаль кинотеатрларын йөреп чыктым. Кешеләр белән сөйләштем, бездән нинди кино көтәсез, дип сораштырдым. Барлык районнарда да, аеруча татар районнарында «безгә үз милли кинобызны эшләп бирегез» диделәр. Ә калганнары «бездә карау теләге туарлык яхшы кино эшләгез» дип сорады. Бу ике мәсьәләне без хәзер берләштерергә тиеш.

Милли кинобыз барлыгын зур ышаныч белән әйтә алам. Әлбәттә, без инглиз телендә, русча яки җаныгыз теләгән башка бер телдә сыйфатлы продукт эшләп чыгара алабыз, ләкин анда миллилек чагылыш табарга тиеш. Кадрда түбәтәй белән чәкчәк күренү һич тә мәҗбүри түгел, иң мөһиме, ул фильм безнең менталите-

Кирәк булачак:

Камыр өчен:
- Каймак – 200 г;
- Он – 200 г
- Йомырка – 2 данә.

Эчлек өчен:
- Сыер ите – 200 г;
- Тавык ите – 200 г;
- Песто соусы – 1 аш кашыгы;
- Борай – 200 г;
- Суган – 3 данә;
- Тоз, борыч – тәменчә.

Фото: Ната Смирнова, Алинә Әхмәдишина

ТАТАРСТАН

тыбызны чагылдырсын. Һәм менә шул чакта ул якут киносы кебек танылачак. Ул гына да түгел, без шундый югарылыкка күтәрелергә тиеш ки, милли үзенчәлегебезне саклаган хәлдә, киноларыбыз халыкара кинематограф белән иңгә-иң ярышырлык булсын. Үз фильмыбызны Канны кинофестивалендә тәкъдим итү әллә ни ерак киләчәк түгел. Һәм безнең төбәк кинематографы нәкъ менә шундый тел шартлатырлык колачлы максатлар куярга тиеш.

ХОЛКЫБЫЗГА КӨНЧЕЛЕК ХАС

– Ә моңа өмет булырлык нигез бармы соң?

– Бар. Бүген безнең кино тармагында чып-чын бум вакыты. Быел гына да тулы метражлы ун фильм төшерелгән. Әлеге вазгыять – тиешле урында, тиешле вакытта берничә шартның бергә туры килү нәтиҗәсе. Беренчесе – кино, нигездә, модага керде, бу хәзер гомуми тенденция. Икенчесе һәм бик мөһиме – фильмнарны төшерерлек кешеләр бар. Киноларны күтәрергә, алга этәрергә теләге булган продюсерлар да юк түгел. Үз идеяләре белән янып-мавыгып йөргән режиссёрлар бар. Бездә кайчан актив рәвештә кино җитештерә башлыйлар инде дип көтеп йөргән актерлар да җитәрлек. Мәдәният институтында кино һәм телевидение кафедрасы оештыруыбыз бәрабәренә профессионалларның ниндидер бер урта катламы үсеп чыкты. Алар теләсә кайсы командада икенче режиссёр, ассистент, оператор һ.б. булып эшли ала. Бу – табигый процесс: югары уку йортын тәмамлаучылар төрле презентация, реклама фильмнарында үсә-чарлана бара, тәҗрибә туплый. Ләкин теләсә кайсы иҗат кешесе реклама рухындагы материалларда озак чикләнеп тора алмый, аның үсәсе килә. Кечкенә метраждан башлап, аннан тулы метражга күчү – теләсә кайсы режиссёр өчен шактый уңышлы үсеш тарихы. Кешедә үз көч-сәләтен файдалану ихтыяҗы барлыкка килә, һәм алар шул рәвешле нормаль кино мохитенә керә. Шунда үзләрен күрсәтү, исемен таныту теләге туа. Бу – нормаль күренеш. Әмма шул ук вакытта иҗади мохиттә көндәшлексез мөмкин түгел, тик әлеге көндәшлекнең сәламәт, уңай рухлы булуы зарур. Без бер-беребезгә көнләшүсез генә булышлык күрсәтергә тиеш, хәер, мондый хиснең менталитетыбызга аеруча хас икәнен искә алып китим. Хезмәттәшенең ничек эшләгәнен күргәч, кара әле, нинди шәп, мин дә үземне сынап карарга телим, дип уйларга тиеш адәм баласы. Мондый нәрсә тиз йога. Син яхшы продукт күрсәттең икән, башка берәүнең тагын да яхшыракны күрсәтәсе килсен яки, ким дигәндә, синнән калышмаслык итеп эшлисе. Төбәгебездәге кино үсеше әнә шул рәвешле генә алга бара ала. Ә аннары максатыбыз – яхшы продукт белән тиз арада төрле фестивальләрдә призлар яулап алу. Мин турысын әйтәм: егетләр, дим, сезне күрүләрен телисез икән, «Кинотавр», «Берлинале» һәм башка дөньякүләм фестивальләрдә күрсәтерлек кино ясарга кирәк. Мондый кино төшерү өчен хәзер бөтен объектив һәм субъектив шартлар бар дип уйлыйм.

КИНОИНДУСТРИЯ ҮЗӘГЕ КИРӘК

Ә моннан чираттагы зур бурыч үзеннән-үзе килеп чыга. Аны исә ничек тә хәл итәргә, алай гына да түгел, дәүләт югарылыгында хәл итәргә кирәк. Кино төшерү өчен павильоннардан башлап, барлык инфраструктураны колачлаган эре киноиндустрия үзәге турында сүз бара. Бүген чит илләрдәге хезмәттәшләребез белән әңгәмә вакытында еш ишетергә туры килә: Татарстан – бик шәп локация, ди алар, монда таулар да, кырлар, елгалар, урманнар да, Идел дә – яхшы кино төшерер өчен кирәкле һәрнәрсә бар. Шунда сорау да бирәләр: безгә инфраструктура – камералар, грим, кием бүлмәләре, артистларга табигатькә чыгу өчен автобуслар, хезмәт күрсәтүче барлык персоналны һәм башкаларны тәкъдим итә аласызмы? Без, ни кызганыч, әлегә моның белән мактана алмыйбыз. Шуңа күрә «Татаркино»га килүемә, без бизнес-план әзерли башладык. Аның максаты – проектыбызны Татарстанның президент җитәкчелегендәге инвестицияләр буенча комитетына тәкъдим итү. Без шуны расларга телибез – кино эше республика өчен кирәмле! Кино төшерүчеләр өчен генә түгел, анысы аңлашыла булыр, ә республикага да файдалы: безнең үз кешеләребез өчен, эшмәкәрләр һәм хәтта предприятиеләр өчен эш булачак. Нәрсә ул кино? Аны төшерү белән мәшгуль төркемнән кала төрле хезмәт күрсәтүче персонал да әле ул. Бу хезмәткәрләргә төшерү төркемен торак белән тәэмин итү, аларны ашату, костюмнар тегү, декорацияләр ясау кебек эшләр йөкләнә. Андыйларның барысын да җирле белгечләр башкара ала, димәк, яңа эш урыннары барлыкка киләчәк. Болар бит шиксез өстенлекләр. Һәм моның шулай икәнен аңлаучылар кино осталары белән генә чикләнми.

ҮЗ ГОЛЛИВУДЫБЫЗ БУЛЫРМЫ?

Кино плюсларыннан бәлешебезнең плюсларына күчик. Борай белән бәйле файдасыннан, каймаклы камырының тәменнән кала, тагын бер бик үзенчәлекле сере бар: Миләүшә ханым ике төрле ит – сыер һәм тавык итләрен куша. Ул гына да түгел, тавык ите песто соусында маринадланган икән әле җитмәсә.

– Ит күбрәк булган саен яхшырак! – дип ышандыра аш-су остабыз. – Чөнки төрле ит төрле тәм бирә, пешерер алдыннан төнгелеккә бүртерергә куелырга тиеш борай шул тәмнәрне үзенә сеңдерә... Өстәвенә тышкы күренеше дә матур килеп чыга: ак ит, кызыл ит... Күзгә үзе бер рәхәт. Һәм, әлбәттә инде, суган кирәк. Бәлештә суган күп булырга тиеш.

– Бу тәмле генә түгел, бик тәмле булырга охшаган – кулинар Голливуд диярсең! Хәтерлисезме, Казаныбызның мэры Илсур Метшин, Казанның 2030 елга кадәрге үсеш программасын яклаганда, монда үз Голливудыбыз булачак, дип белдергән иде. Булырмы?

– Бәлки, Голливуд ук булмас, ләкин «Мосфильм», «Ленфильм», Калининград киностудияләренә йөз тота алабыз, – дип сөйли Миләүшә ханым. – Бу юнәлештә беренче адымнар ясала да инде. Әлбәттә, бу проект өчен актив рәвештә инвесторлар эзләргә кирәк.

Инвестицияле үсеш агентлыгы белән без билгеле бер нәтиҗәгә ирешербез дип уйлыйм, анда икътисадый яктан белемле, бу эшнең никадәр төшемле икәнен бик шәп аңлаган яшь, кызыксынучан егетләр бар. Без бит ниндидер сәяси керем, имидж ягыннан дивидендлар гына алмыйча, республикага реаль инвестицияләр җәлеп итәбез. Проектларыбызны яхшы итеп тормышка ашырсак һәм халыкара югарылыкка чыксак, бу инвестицияләр шактый сизелерлек күләмдә булачак.

Һәм менә шунда, грандиоз планнар фонында, парадокс хәл килеп туа, тик бу хакта уйлаучылар гына бик сирәк. Шундый вазгыять барлыкка килә ки, без Татарстаныбызның фильмнарын үзебездә, республика тамашачысына күрсәтә алмыйбыз диярлек, чөнки хәзер бездә киночелтәре тулысынча диярлек җимерелгән. Ә аның таркалуы объектив сәбәпләргә бәйле. Муниципаль кинотеатрлар барысы да башка шәһәрләр – Екатеринбург, Самара, Мәскәү, Санкт-Петербургның коммерцияле дистрибьютерлары белән рәсми килешү нигезендә эшли. Нәкъ менә шул дистрибьютерлар бу кинотеатрларның репертуар планын формалаштыра да инде. Ә бу репертуарда – Голливуд фильмнары, Россия кинолары, ә җирле кино өчен урын юк. Прокатчыларның җирле кинога мөнәсәбәте, гомумән, җитди түгел, нәрсә төшерә ала инде алар дип карыйлар, җитмәсә, булганын да алмыйлар. Коммерцияле кинотеатрларның елына 26 миллион сумга кадәр акча эшләвен, әле шуның 60 проценты башка төбәкләргә китүен хәтта әйтеп тә тормыйм. Гафу итегез, мондый сумманы бер дә югалтасы килми. Ник әле шундый акчаларны республикада калдырмаска, ди. Бер дә кесәне төртеп тишмәячәк.

Хәзер без дәүләт кинотеатрлар челтәрен торгызырга тырышабыз. Сүз уңаеннан, җиһазлар сатып алыр өчен аларга биш миллион сум тараттык, бу акча конкурс нигезендә Россиянең Кино фондыннан бүлеп бирелде. Соң шулай булгач, бу җиһазларны баланска кабул итеп, ничек инде чит калаларның коммерцияле оешмалары белән дә эшләргә мөмкин, ди? Прокат өчен җавап бирә торган оешма буларак, «Татаркино» дистрибьютерлык функцияләрен үзе дә уңышлы башкара ала. Россиянең, Голливудның яңа табадан төшкән картиналарын сатып алырга, шул ук планга Татарстанда җитештерелгән фильмнарны да кертеп җибәрергә хәлебездән килә. Әле моннан тыш, безнең Казан мөселман киносы фестивалебез бар. Фестиваль фильмнарына, Төркия, Мисыр, Иран һәм башка илләрнең өр-яңа, шәп киноларына прокат хокукын да сатып алсак, бөтен республика кинотеатрларының репертуарын тулыландырырга, баетырга сәләтлебез. Кинотеатрлар челтәре һәм бердәм репертуар планы безгә бик кирәк. Сүз уңаеннан, Россиядә андый тәҗрибә дә бар. Краснодарда безнекенә тиңдәш дәүләт учреждениесе эшли, ул репертуар белән 57 кинотеатрны тәэмин итә. Бу – яхшы сан. Бүген Татарстанда 19 DSP-кинотеатр (Казанны исәпләмәгәндә) эшләп килә, тагын бишесе быел грант отты, димәк, киләсе ел ахырына аларның саны 24 кә җитәчәк.

АВЫЛДАГЫ КИНОПАРАДОКСЛАР

Ул кинотеатрларның мәдәни-агарту эше, социаль вазыйфа башкаруы, икътисадый яктан файдалы булуы кирәк. Алар башка төбәкләрнең коммерцияле дистрибьютерлары белән хезмәттәшлек итә икән, шуларның таләпләрен катгый рәвештә үтәргә мәҗбүр. Мәсәлән, аларның репертуар планы буенча көнгә 8 тапкыр киносеанслар планлаштырылган. Күз алдына китереп карагыз, әйтик, Буада, Алексеевскида яки башка бер кечкенә бистә, йә авылда көненә 8 тапкыр кино күрсәтәләр, ди. Сеанс саен бер-ике тамашачы өчен. Һәркем бик яхшы аңлый булыр: 5-7 мең халык яши торган район үзәгендә көнгә 8 тапкыр кинога йөрүче табылмаячак. Гап-гади кара акыл белән уйлаганда да, бу эшнең җиһазларны мәгънәсез куллану икәнлеге ап-ачык. Ни өчен? Сеансларны күп дигәндә көненә ике тапкыр – иртән һәм кич куярга була. Мин хакимият башлыкларына әйтә киләм, аңлагыз, дим, кыйммәтле җиһазларга хезмәт күрсәтү белән бәйле бөтен чыгымнар муниципалитет җилкәсенә йөкләнә. Ә сезгә акчаның җилгә очуы кирәкме?

Хәзер икенче парадокс. Республикада авыл мәдәният йортларын төзү буенча дәүләт программасы бар, аның гамәлгә ашырылуын дәлилләгән саннар да саллы. Ләкин, ышанасызмы-юкмы, бу мәдәни-ял учреждениеләрендә кино күрсәтү мөмкинлеге каралмаган: тәрәзәләр капланмый, экран, проектор юк, шундый иң гади нәрсәләр дә теләсә кайсы авылда булырга тиеш югыйсә. Акылга сыймаслык нәрсә!

КИНО КАРАУ КУЛЬТУРАСЫН НИЧЕК КАЙТАРЫРГА?

Әнә шуннан чыгып, мин хәзер «кино якында гына» дигән яңа карашыбызның концепциясен үстерәм. Яңа чыккан премьера фильмнарны – Россиянекеме ул, Голливудныкымы, Татарстанныкымы – һәр авыл халкының карау мөмкинлеге булсын. Кино аларга килеп җиткәнче, 2–3 ай көтеп тормасыннар. Проблемамы бу? Әйе, проблема. Шулай булгач, әйдәгез, авыл мәдәният йортларын атнаның ике кичендә булса да кино күрсәтеп тутырып алыйк. Эштән кайттың, кичке ашны ашадың да гаиләң яки йөргән кызың белән кинога киттең. Район үзәкләренә һәм авылларга кино карау культурасын кире кайтару вариантлары бик күп. Әлеге матур гадәт хәзер юк, ул онытылган, аны җимерделәр. Тик бар иде бит. Әле хәтерлим, мине балачакта авылга кайтарганда, без клубка чыга идек тә, шимбә-якшәмбе көннәрендә ярыктан кино карый идек. Ә клуб булмаган якларда, күчмә җиһазлар кулланыла иде.

Боларның барысын да бер концептуаль идеягә берләштерү өчен, Татарстан Республикасында 2020 елга кадәр мәдәниятне үстерү программасы кысаларында без үз тәкъдимебезне – кинематографияне үстерү турында бүлекне керттек. Безнең идеябезгә президентның да,

МИЛӘҮШӘ АЙТУГАНОВАДАН БЕР КИҢӘШ:

– Ит күбрәк булган саен яхшырак! Чөнки төрле ит төрле тәм бирә, пешерер алдыннан төнгелеккә бүрттерергә куелырга тиеш борай шул тәмнәрне үзенә сеңдерә... Өстәвенә тышкы күренеше дә матур килеп чыга: ак ит, кызыл ит... Күзгә үзе бер рәхәт.

Һәм, әлбәттә инде, суган кирәк. Бәлештә суган күп булырга тиеш.

Санитар нормаларга туры килү өчен, башка яулык ябарга да оныттмыйк.

хөкүмәтнең дә, Дәүләт Советының да игътибар бирүен телибез. Өстәвенә, бу гамәлне башлап җибәрү өчен нәкъ вакыты: җәмгыятьтә хәзер өйдә телевизор каршында утыру түгел, ә яхшы сурәтле, шәп тавышлы әйбәт залда кино карап кайтуга омтылыш барлыгы ачык күренә. Кешеләр виртуаль дөньяда аралашудан туйган, күзгә-күз сөйләшүгә тартылалар. Залда киноны башка тамашачылар белән бергә карыйсың икән, ниндидер уртак бер кабул итү аурасы, башка энергетика барлыкка килә. Әлеге уртаклык хисен, ниндидер төркемгә, зур эшкә, миссиягә якынлыгыбызны без кайсыдыр мизгелдә югалттык. Моны кино аркылы кайтарырга мөмкин. Хәзер бу күренеш модага керә, һәм аны тотып калсак, һәрнәрсәне вакытында һәм дөрес эшләсәк, хәтта иҗтимагый кәеф-фикерләрдә дә бөтенләй башка хәл була алыр иде.

Кызыксынган затларда программабызга карата шәхсән мин яки командабыз ышаныч тудыра алсак, бу – Татарстан киносына яңа импульс бирәчәк. Ләкин инде бүген үк сизелерлек үзгәрешләр бар. Мәсәлән, Илдар Ягъфәровның «Байгал» фильмы төрледән-төрле фестивальләргә тәкъдим ителәчәк. Әмир Галиәскәров белән Рамил Фазлыевның «Мулла»сы да прокатта яхшы барыр, фестивальләрдә дә уңышка ирешер, дип өметләнәбез. Режиссёр Алексей Барыкин үзе беренче татар блокбастеры дип атаган «Су анасы» картинасы да бар. Ул аны Мәскәү кинобазарында тәкъдим итә. Рөстәм Рәшитов белән Илсөяр Дамаскинның инде төшерү этабында ук шау-шу куптарган «Кире» фильмы да озакламый әзер булачак. Исемлекне әле тагын да дәвам итәргә мөмкин, ләкин сан ягы мөһим түгел. Хәтта бу фильмнарның киләчәк язмышы ничек булып чыгачагы да икенчел. Шунысы әһәмиятле: кешеләрдә кино төшерү өчен чып-чын теләк бар. Алар монда, республикада, кино төшереп булганлыгына ышандылар. Әйе, әлегә без тамашачылар аңына кереп урнашкан стереотип фикерне – янәсе, Татарстанда яхшы кино була алмый – җиңүгә ирешмәдек. Ә чынлыкта бездә бик куәтле алгарыш, без үсештә. Кызыксынуны басар өчен булса да, килеп карый аласыз. Татарстан киносы турында әңгәмә вакытында очкынланып киткән күзләрне күргәндә, искиткеч рәхәтлек хисе кичерәм. Кино тармагының аякка басуына үземнән файдалы өлеш кертә алуым куанычлы.

Ә ИР-АТЛАР НИ ӘЙТЕР?

Бәлешләребез мичтә пешкән арада, шулпа әзерлибез, аны соңыннан бөкесенә үк җитәрлек итеп бәлешләргә саласы була.

– Ник дигәндә, борай суны бик сеңдерә дә бүртә.

– Татарстанда хатын-кыз җитәкченең язмышы авырмы?

– Бер баш югары булырга, ир-атлардан яхшырак эшләргә туры килә, ә хаталану бөтенләй тыела. Һәм әле шул вакытта да «хатын-кыз бит ул, барыбер булдырып бетерә алмый» дип әйтәчәкләр... Нәрсә әйтсәң инде аңа, хатын-кыз бит, янәсе... Ә ир-ат хата җибәрә икән, аны гафу итү генә түгел, хәтта ул хатаны күрмиләр дә. Әйтерсең, без яртылаш кына кешеләр? Ә шул

1. Ватабыз!

2. Бушатабыз!

3. Катнаштырабыз!

4. Турыйбыз!

5. Ваклап турыйбыз!

8. Болгатабыз!

9. Җәябез!

10. Куябыз!

11. Эчлек салабыз!

12. Ябабыз!

– Татарстан киносы турында әңгәмә вакытында очкынланып киткән күзләрне күргәндә, искиткеч рәхәтлек хисе кичерәм. Кино тармагының аякка басуына үземнән файдалы өлеш кертә алуым куанычлы.

ук вакытта башка илләрдә хакимияттә хатын-кыз булу – дөнья-күләм тренд. Мин мөселман киносы фестиваленә жюри рәисе итеп тәүге тапкыр хатын-кызны – Майя Аймедованы куярга тәкъдим иттем. Төрекмәнстанның атаклы артисткасы ул, СССРның халык артисты… Бик лаеклы кандидат. Каршы чыгучылар да табылды, янәсе, ничек инде мөселман киносы фестивалендә жюри рәисе хатын-кыз булсын, ди?! Ир-атлар ни әйтер? Фәкать хәзер кино да, журналистика кебек, хатын-кыз йөзле, шуңа күрә дә, минемчә, бу хакта ир-атлар ни әйтер икән дип уйлап-карап торырга кирәкми. Йомгаклап әйткәндә, мөселман киносы тарихында беренче тапкыр жюри рәисе – хатын-кыз! Бу яңалык белән мин барыбызны да котлыйм!

КИНО ГАДИ БЕР ТАМАША ГЫНА БУЛЫРГА ТИЕШ ТҮГЕЛ

Менә шул шатлыклы мизгелдә бәлешләрне мичтән алабыз. Кетердәп торган капкачын сындырып, баш әйләндергеч тәмле борайлы-итле исне иреккә чыгарганда, кызыксынып куябыз:

– Миләүшә ханым, кино караганда халыкның попкорн ашавына сезнең караш ниндирәк? Аның бар җиргә үтеп керә торган исен безнең бу бәлешнеке белән чагыштырып та булмый бит…

– Кызганыч, Америкадан килгән әлеге стереотип тормышыбызга бик нык кереп утырды. «Мир» кинотеатрында без «попкорнсыз кино» тәртибен кертеп маташкан идек, тик сорыйлар шул… Күпчелек шуннан бихуш.

– Яраткан киногыз нинди? Россиянекеләрдән? Чит илнекеннән? Татарстанныкы?

– Чит ил картиналары арасында – «Унесенные ветром». Аның төп героинясы Скарлетт О'Хара тарафыннан әйтелгән сүзләр гомерлеккә хәтергә уелып калды: «Мин бу хакта бүген уйламаячакмын. Бу хакта иртәгә уйлап карармын». Татар киноларыннан «Байгал» белән «Мулла» ошый. Совет киноларын бик яратам, аеруча Гайдай комедияләрен, аларны сансыз-хисапсыз тапкыр карый алам. «Жестокий романс» фильмын яратам, чөнки андагы музыка бик ошый. «Служебный роман» киносында Алиса Фрейндлих уенын да карарга яратам. Совет киносы шулкадәр дөрес, бөтен канун-кагыйдәләр дә җиренә җиткереп ясалган, шуңа да алар безгә кадерле, шуңа аларны каравы рәхәт. Кино җитештергәндә махсус эффектлар куллану, әлбәттә, бик заманча. Ләкин мондый форма артында чын, галәмәт зур максатны яшергән очракта гына ул урынлы. Бу максат – синең тамашачыга җиткерергә теләгән уй-фикерең ул. Тик син кино караганда төрле шарт-шортлар, даң-доңнар яки ниндидер коточкыч җан иясе генә истә калган икән, бу – кино түгел, ә гап-гади тамаша. Ни дисәң дә, кино күңелне биләп алырга тиеш дип саныйм. Кино кешенең психикасына, аның халәтенә иң көчле тәэсир итү чарасы бит. «Легенда 17» яки «Движение вверх» фильмнары кебек, кино ватанпәрвәрлек хисе тәрбияли. Ниндидер спорт командасын аягүрә басып алкышлаганда, безне бит әнә шул хис берләштерә – һәм бары кино ярдәмендә генә шундый нәтиҗәгә ирешергә мөмкин.

6. **Өстибез!**

7. **Тоз салабыз!**

13. **Ябыштырабыз!**

14. **Шулпа салабыз!**

15. **Теләкләр телибез!**



Редакция ZaVarka кулинария студиясенә материалны эшләгәндәге ярдәме өчен рәхмәтен белдерә.

MBEH: КУРКЫНЫЧСЫЗ ОЧЫШЛАР ТУРЫНДА

«Мурена» самолеты

Узган елның 10 сентябрендә «Кронавиа-9» җиңел самолеты Санкт-Петербург янындагы кечерәк кенә аэродромнан һавага күтәрелә. Һәм кинәт кенә двигатель эштән чыга. Аста – урман, су һәм торак массив, ә аэродромга әле ерак... Фаҗига? Булырга мөмкин иде, әгәр уникаль коткару системасы булмаса. Очучы аны кушып өлгерә, ә алга таба барысы да әкияттәгедәй матур тәмамлана. Авырлыгы 1000 килограмм булган самолет җиргә...парашютта төшеп утыра. Ике пассажир һәм очучы онытылмаслык куркыныч мизгелләр кичерсәләр дә, иң мөһиме – исән калалар.

Илья Ермоленко, «МВЕН» Фирмасының генераль директоры.

Александр Ефремов, «МВЕН» компаниясе архивыннан

«МВЕН» Фирмасы 1996 елда Германиядә ультраҗиңел һәм җиңел очу аппаратларында БПС куллануга сертификат ала. Компания җитәкчелеге сүзләренә караганда, бу күп нәрсә турында сөйли, чөнки шуңа охшаш системаларны немецлар да, америкалылар да эшләргә тырышып караганнар, ләкин Европада коткару парашют системаларын сертификацияләүдә уңышка беренче тапкыр россиялеләр ирешкән.

Әлеге хәбәр бөтен авиация дөньясына санаулы минутлар эчендә тарала. Һәм чираттагы мәртәбә Казандагы «МВЕН» Фирмасы тарафыннан эшләнгән тиз ачыла торган коткару парашют системасының (БПС) зарурлыгын раслый. «Кронавиа-9» самолетына нәкъ менә әлеге система урнаштырылган була.

Коткару системасының уникальлеге, полимер-композит материаллардан очкыч аппаратларны уйлап табу һәм җитештерү турында «МВЕН» Фирмасы генераль директоры Илья Ермоленко сөйли.

– Фирма ачу идеясе каян килде һәм ни өчен нәкъ менә коткару парашют системасы?

– МВЕН аббревиатурасы аны уйлап табучылар – Михаил Невельский һәм Виктор Ермоленко исем-фамилияләреннән алынган. КАИ ны тәмамлаган бу егетләргә, парашют спорты белән шөгыльләнгәнгә, мотодельтапланнарда очу куркынычсызлыгы проблемасы таныш була, һәм алар проблеманы хәл итү юлын табалар. Төп идея шунда: теләсә кайсы биеклектә һәм тизлектә очучыны һәм пассажирларны һава судносыннан чыкмый гына коткару. Невельский һәм Ермоленко үзләренең тиз ачыла торган коткару парашют системасын уйлап табучылар да, аны беренче мәртәбә сынап караучылар да булалар. Бүген предприятиенең исәбендә һавада коткарылган 50 гомер – бу 30 дан артык һава судносы экипажы дигән сүз! БПС безнең предприятие чыгарган барлык самолётларның база комплектациясенә керә. Без һава суднолары җитештерүчеләргә һәм очкыч хуҗаларына максималь тизлекләрен 450 км/сәг. кә арттыра алган һәм массалары 3000 тоннага кадәр булган очу аппаратлары өчен БПСның серияләп чыгарыла торган 10 төрен тәкъдим итә алабыз. Предприятиедә массалары 5700 кг га кадәр булган самолетлар, һәм шулай ук вертолетлар өчен коткару системалары, авыр авиация техникасы өчен коткару кабина-капсулалары эшләү алып барыла.

– Сезнең потенциаль заказчыгызга нәрсәләрне белергә кирәк?

– Әгәр һава судносы хуҗасының коткару системаларын урнаштыру буенча барлык исәп-хисаплары бар икән, без БПС тибын, размерларын, комплектациясен, заказчыга тапшыру ысулын килештерәбез, шартнамә имзалыйбыз һәм 45 көн эчендә заказны үтибез. Безгә һава судносы конструкторлары ешрак очу аппаратын уйлап табу стадиясендә үк мөрәҗәгать итәләр. Бу очракта без БПС урнаштыру буенча киңәшләр бирәбез, исәп-хисапларны уртак килештерәбез. Шунысын аңларга кирәк: бүгенге заманда куркынычсызлык позицияләре торган саен күбрәк популярлык казана бара. Һәм һава судноларын җитештерүчеләр өчен безнең коткару парашют системалары белән җиһазлау көндәшлекле өстенлек санала.

– Нәкъ менә сезнең системаның уникальлеге нәрсәдә?

– Аның эшләү принцибы бик гади: очыш вакытында авария куркынычы–

2011 елда Франциядә Казан «МВЕН» Фирмасының БПСларны сату һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча дилерлык үзәге ачылган иде. Биредә ел саен 15–20 система урнаштырыла. Французлар, өстенлекне америкалыларга һәм чехларга түгел, казанлыларга бирәбез, дип раслый. Эш бәядә түгел – Казанда эшләнгән система ышанычлырак, ул аварияле очракларның күпчелегендә ярдәмгә килә.

Реклама

Россия Президенты ышаныч күрсәткән коткару системасы Татарстанда эшләнгән! Ак торналарның популяциясен саклауга һәм арттыруга юнәлдерелгән «Өмет очышы» халыкара экология проекты вакытында Владимир Путин «МВЕН» Фирмасында җитештерелгән БПС урнаштырылган дельтапланда очыш ясый.

16 август көнне Татарстан Президенты «МВЕН» Фирмасы авиапредприятиесендә булды. Рөстәм Миңнехановка күпмаксатлы 4 урынлы «Мурена» самолетын күрсәттеләр. Әлеге самолетның рәсми презентациясе агымдагы елның августында «АКТО» күргәзмәсендә узды.

туганда очучы БПСны кушып җибәрә: очу аппаратыннан парашют системасы булган контейнер аерылып чыга. Парашют гөмбәзе ачыла һәм очу аппараты, экипажы белән бергә, парашют астында исән-имин җиргә утыра. Нәкъ менә контейнерның аерылып чыгуы аркасында БПС ны нәтиҗәле куллануга ирешелә дә: парашютның гөмбәзе һәм баулары һава судносы конструкциясендә эләгеп кала һәм бутала алмый, чөнки контейнерның каты корпусы аларга моны эшләргә ирек бирми.

– 9 август көнне «Казан ярминкәсе»ндә узган 9 нчы Халыкара «АКТО» күргәзмәсе кысаларында сезнең яңа күпмаксатлы 4 урынлы «Мурена» самолетының презентациясе узды. Бу хәзерге көндә республикада кече авиация өчен самолетлар конструкцияләү һәм җитештерү актив үсә дигән сүзме?

– Соңгы өч елда дөньяда моңа охшаш модельләр әллә ни күп җитештерелмәде. Шундыйларның берсе тулысынча Татарстан Республикасында эшләнде. Минем яныма килеп: «Бу Кытай самолетымы, әллә Америкада эшләнгәнме?» – дип, бер генә мәртәбә сорамадылар. Һәм аларга самолет җитештерүнең бөтен процессы – проектлаудан алып сынау очышларына кадәр – тулысынча республикада башкарылганлыгын аңлатырга туры килде. Әлеге самолетны «МВЕН» Фирмасы заманча композит материалларны, үз классында иң яхшы двигательләрне һәм инновацияле технологияләрне кулланып эшләде. Безнең аппарат үз күрсәткечләре буенча чит илләрдә эшләнгән аналогларыннан һич тә калышмый, ул көндәшлеккә сәләтле. Бу юлы да Татарстанда чыннан да үзләренең инновацион һәм икътисадый ышанычлылыкларын раслаучы, яңа таләпләргә (шул исәптән дөнья күләмендәге авиация базарында да) җавап бирерлек мөмкинлекләргә ия предприятиеләр барлыгын күрсәтте.

– «МВЕН» Фирмасы эшчәнлегенең бер юнәлеше – авыл хуҗалыгы авиациясе өчен самолетлар җитештерү. Аларга бүген ихтыяҗ никадәр зур?

– Сүз дә юк, авыл хуҗалыгы өчен махсус самолетларга ихтыяҗ бар. Бүген тулысынча композит материаллардан эшләнгән бер урынлы МВ-50 самолетына ихтыяҗ бар. Ул компаниянең элегрәк эшләнгән проекты – МВЕН-2 «Фермер» самолетының эволюцион дәвамы булып тора. Очкыч югары җитештерүчәнлеккә ия эшләрнең түбән үзкыйммәте мөһим булган хуҗалыклар өчен очышлар уздыруда иң югары куркынычсызлык таләпләрен исәпкә алып ясалды. Асылда бу – ышанычлы эш аты.

Узган елда «Ростех» Дәүләт корпорациясе һәм Татарстан Республикасы арасында имзаланган Бөтенроссия авиахимия эшләре системасын булдыру һәм үстерү һәм ТР территориясендә азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча килешү республикада авыл хуҗалыгы авиациясе самолетлары базарына яңа этәргеч бирер, дип уйлыйбыз.

«МУРЕНА»

Югары дәрәҗәдәге очыш-техник характеристикаларга һәм уңайлылыкларга ия 4 урынлы күпмаксатлы заманча самолет. Самолет өйрәнү, эшләү максатлары, мониторинг, һава туризмы өчен идеаль туры килә. «Мурена»ны эксплуатацияләүнең максималь нәтиҗәлелегенә югары тизлек һәм очыш сәгатенең түбән үзкыйммәте аркасында ирешелә: самолет, бер сәгатькә 25 литр АИ-95 автомобиль бензинын ягып, 300 км дан артык араны очып уза.

Самолетның шәп күзәтү кырына, вентиляция һәм җылыту системаларына ия иркен кабинасы экипажга һәм пассажирларга үзләрен яхшы хис итү өчен максималь уңайлылык тудыра.

Самолетта очыш куркынычсызлыгына АП-23 очыш яраклылыгы нормалары таләпләренә туры килү, һәм шулай ук ике двигатель һәм БПС урнаштырылу аркасында ирешелә.

«Ел авиатөзүчесе – 2017» конкурсы нәтиҗәләре буенча, «МВЕН» Фирмасы авиация техникасын, компонентларын уйлап табудагы уңышлары һәм яңа «Мурена» машинасын җитештерүе өчен призлы урыннар яулый.

МВЕН-2 «Фермер» самолеты.

МВЕН-2 «Фермер» һәм МВ-50 агросамолетлары, күпмаксатлы 4 урынлы «Мурена» самолеты «МВЕН» Фирмасында җитештерелә. Бизнес-класс өчен реактив 6–9 урынлы самолет ясау өстендә эш бара.

Бүгенге көндә Россиядә, якын һәм ерак чит илләрдә «МВЕН» Фирмасында җитештерелгән 1,5 мең БПС эшли.

Кече авиация самолетларын җитештерүчеләрнең күбесе белән казанлыларның яхшы хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре урнашкан. Әйтик, Пермь, Оренбург, Самара бортлары фюзеляжларына, Казанның «МВЕН» Фирмасының коткару системасы белән комплектлаштырылган, дигән язу урнаштырылган. Бу биредә очучыларда экономия ясамыйлар дигәнне аңлата.

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

WWW.PROTATARSTAN.RU

Реклама 16+



БӘХЕТЛЕ ЯШЬ

Бәхетле пенсионерларның барысы да бертөсле бәхетле. Безнең каһарманнар гамәлдә шуны исбатлый да: аларның өлкән яшьтә булуы – яңа мөмкинлекләр, казанышлар һәм үз иркендә өчен көндәшлек ресурсы, дигән сүз. Һөнәри яктан да шулай.

Фото: Александр Ефремов, Алинә Әхмәдишина

АЛТЫН ЧОРГА КЕРГӘНДӘ...

Күренекле кешеләр портретларыннан тулы бер галерея – Россиядә танылган сынчы, Татарстан Республикасының халык рәссамы Мәхмүт Гасыймовның остаханәсе сәнгать музееен хәтерләтә. Киштәләрдә, идәндә – һәркайда сыннар, скульптура эскизлары, коеп ясалган әйберләр, булачак эшләрнең караламалары.

– Менә бу эшем тыл хезмәтчәннәренә багышланган Бөтенроссия һәйкәлләр бәйгесендә җиңеп чыкты, – дип сөйли яңа танышым, мавыгып. – Казанның Җиңү паркына 2010 елда ук куярга дип планлаштырылган иде. Бер караганда, идеясе дә гап-гади, үзе дә тыйнак кына! Ләкин әлегә кадәр шушы проектны тормышка ашырырлык акча табылганы юк. Җиңүнең 70 еллыгын да билгеләдек инде... – дип көрсенә сынчы. – Аңлыйсыздыр, шәт: мин хак эш эшләсәң, һичшиксез ул өстен чыга, дип ышана торган буыннан.

Проектны гамәлгә ашырыр өчен Гасыймовка ныклыгы һәм үз дигәнендә торучанлык кебек сыйфаты ярдәм итәр, ахыр чиктә, аның моны башкарып чыгарга көче җитәр, дип ышанам.

Бүген сынчының татарстанлыларга таныш эшләре арасында Казанда Бакый Урманче, Салих Сәйдәшев, Гавриил Державин, Владимир Бехтеревка куелган һәйкәлләр, Әлмәттә Габдулла Тукайга багышланган «Илһам» декоратив композициясе, Алабугада Ибраһим I нең атлы сыны бар...

Мәхмүт Маталит улы – совет сынчылар мәктәбе вәкиле, портрет остасы, Аллаһ талантны аңа мулдан биргән. Күп еллар элек, бала вакытында, балчыктан Ленин яки Сталин фигураларын ясап, әти-әнисен телсез калдыра торган була – бик тә охшаган була ул сыннар.

– Портретчы Гасыймов әнә шулай барлыкка килгәндер инде, – дип көлә Мәхмүт ага.

Бүген дә аның беренче һәм төп «имтихан алучылары» булып якыннары – балалары һәм хатыны кала:

– Миңа аларның фикере, читләрнекенә караганда мөһимрәк. Алар гап-гади итеп «ошый», «ошамый» дип кенә бәяли. Ышандырамы, юкмы. Кызыклы композицияме, юкмы. Моның өчен академик белем алырга кирәкми.

Өлкән яшькә җитеп, ул иҗат ирегенә ирешкәнме? Әнә шул сорау кызыксындыра.

– «Ирек» сүзенә дәгъвам юк, – ди тыныч кына сынчы. – Совет хакимияте чорында да үземне ирекле хис итә идем, хәзер дә. Бернинди партиягә дә кермәдем, гәрчә үгетләделәр. Мин кулым белгән эшне җиренә җиткереп эшли алам. Шуның белән бетте! Кешеләргә синең эшләрең ошый икән, шул ирек хисе бирә дә инде. Мин шуңа канәгать.

Автор:
Алсу Троицкая



«ЯШӘР ӨЧЕН ЭШЛИМ»

Дуслары аңа еш кына: «Нишләп һаман эшләп йөрисең? Синең депутат пенсиясе белән күптән инде ялга китәргә була. 70 яшь ерак түгел...» – ди икән. Әнвәр Мөхәммәтзакиров исә каршы төшә:

– Өйдә нишләрмен соң? Бакчаны ял көннәрендә дә карап була аны...

Соңгы берничә елда ул – «Союзхипромпроект» проект институты директорының куркынычсызлык буенча урынбасары. Озак еллар идарә эшендә хезмәт куйган кеше өчен бөтенләй башка өлкә кебек. Әмма «Кадыйрович» (институтта аны шулай дип йөртәләр) моның белән катгый рәвештә килешми:

– Әйе, мин проектлаучы түгел, бөтенләй башка өлкәдән – җитештерүдән килдем. Бәлки, шуңадыр да эшләп бетерәсе нәрсәләр күземә яхшырак күренәдер. Ә яшь һәм тәҗрибә теләсә кайсы өлкәдә ярдәм генә итә. Мин шуны беләм: хәл итеп булмастай проблемалар юк, түземлек кенә кирәк. Тәҗрибә – абына-абына алган җәрәхәтләрнең суммасы ул, дип бик дөрес әйтәләр. Җитәкчелек эшенә иртәрәк керешкән саен, тәҗрибә дә тизрәк килә.

Әнвәр Мөхәммәтзакиров – «Радиоприбор»да радиоаппаратура көйләүчедән эре заводның директорына кадәр хезмәт юлы үткән шәхес. 9 ел директор булып эшләү дәверендә аның 245 көн алынмаган ял көннәре җыелган.

– Ул вакытларның теләсә кайсы җитәкчесе ничек эшләгәнебезне сөйләп бирә ала. Беренче оперативка иртәнге 7дә, кичкесе – 23 сәгатьтә. Хәзер алай эшләмиләр инде, – дип дәвам итә әңгәмәдәшем. – Киресенчә, бүген яшәр өчен эшлиләр. Мин дә – шул исәптән.

Мин ни өчен әлегә кадәр эшлимме? Чөнки миңа ошый, миңа авыр түгел. Һәм иң мөһиме: кирәклегеңне тоясың. Ул хис югалса, менә, ялга китәрмен. Ә әлегә институтыбызга файда китерә алуымны күрәм һәм эшли бирәм.

ГОМЕРЛЕК БАЛАЛАР

Үз гомерендә предмет кына өйрәтеп калмыйча, игелекле, гадел булырга да өйрәтә торган укытучыны очрату олы бәхет ул. Андый укытучыларны гадәттә онытмыйлар.

Светлана Александровна Клочкова да шундый укытучы булган. Ни өчен булган, дибезме? Чөнки лаеклы ялга чыкканнан соң 12 ел эшләгән, хәзер бераз гына ял алырга уйлаган. Күп вакытта дачасында яши, оныкларын карый, иренә бакча эшләрендә ярдәм итә. Мәктәп турында, балалар турында сөйли башласа, күзләре яна: ул күзләргә карап, узып баручы елның аның укытучылык гомерендә соңгысы түгеллеген аңлыйсың. Өстәвенә, тәкъдимнәр дә элеккечә күп.

Кунак бүлмәсендәге чәчәк гөлләмәсе хуҗабикәнең үзенә охшаган – шундый ук ачык һәм кыю. Ни дисәң дә, 15 ел элек укытып чыгарган укучылары үзләренең сыйныф җитәкчесенең холкын яхшы беләләр.

– Әйе, шушы көннәрдә генә әле безнең дачада чын мәгънәсендә «Мамай һөҗүме» иде, – дип көлә Светлана Александровна. – Укучыларым үзләренең хатыннары, ирләре, балалары белән килде. Ифрат күңелле булды!

Ул Казан дәүләт университеты каршындагы Академик колледжда биология укыткан, соңыннан ул, беләбез, КФУ каршындагы Лобачевский исемендәге лицей итеп үзгәртелде. Аннан соң инде СОлНЦега әверелде – махсус олимпиада-фәнни үзәге.

– СОлНЦе ул – укытуның бөтенләй башка принциплары, дигән сүз. Минем өчен укучы – барыннан да элек, кеше, һәм мин аны ихтирам итәргә тиеш! – ди Светлана ханым. – Билгеле, миңа күбрәк ошый торган укучылар да була. Беренчедән, мин моны беркайчан да сиздермим. Икенчедән, «яратканнар» исәбенә кергәнсең икән – бу дәрәҗәле исемне күтәрә дә бел, башкаларга караганда күбрәк укы, эшлә.

Ул укытып чыгарган укучылар арасында бүген профессиональ биологларның һәм олимпиадаларда җиңүчеләрнең күп булуына карап хөкем йөртсәң, «яратканнар» шактый булган. Шуларның берсе – Никита Алкин – 2015 елда Биология буенча халыкара олимпиада җиңүчесе.

Балалар белән Светлана Александровна һәрвакытта да яхшы мөнәсәбәт урнаштыра белгән, дөрес, ул мәктәптә иң кырыс укытучылардан санала.

– Мин балаларга башта ук әйтеп куям: белемне сез үзегез сайлап аласыз. Минем бурыч – аны фактка карап кую. Һәркем нинди билгегә лаек, шуны ала. Ихтирам – мөгаллимлек итүнең нигезе шушы. Мин «педагог» дигән сүзне яратмыйм. Борынгы грек теленнән тәрҗемә иткәндә, ул кол кебек, белемле тәрбияче дигәнне аңлата. Укытучы исә – әйбәт сүз, үзебезнеке. Мин – укытучы.

Димәк, Светлана Александровна, дәвамы булачак әле?

Р.О.С.Т.

ТИЗ УКУ МӘКТӘБЕ

Әгәр сез тиз уку методикаларын сатып алып үз шәһәрегездә әлеге юнәлешне үстерергә телисез икән, шушы телефон буенча мөрәҗәгать итә аласыз.

8 800 301 42 55 8 (843) 216 34 55

www.школа-скорочтения.рф
www.скорочтение-рост.рф

КОМПАНИЯ УКУ-УКЫТУ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ХЕЗМӘТЛӘР БАЗАРЫНДА ИНДЕ 6 ЕЛ ЭШЛИ. БЕРНИЧӘ МЕҢ ЧЫГАРЫЛЫШ БАЛАСЫ БЕЛӘН ГОРУРЛАНА АЛАБЫЗ.

Без әти-әниләрдән еш кына балаларның укырга теләге юк, дигән сүзне ишетәбез. Төп сәбәп – игътибарларын бер ноктага туплый алмау, дибез, ягъни уку процессында бала башка нәрсәләр турында уйлый, үзен җыя алмый, нәтиҗәдә укыганын хәтеренә сеңдереп тә калмый. Сүз әдәби текстлар турында гына бармый, ә математика буенча мәсьәләләр, башка предметларга караган мәгълүмат турында да. Әгәр бала материалны үзләштерә алмый икән, аның укуга карата булган тулаем мөнәсәбәте дә тискәрегә әйләнә.

Балаларны уку процессына акрынлап, этаплап кертеп, без аның баш мие структурасын алга таба да укуга көйләнә торган итү максатын куябыз. Болай иткәндә, ышанып әйтергә була: аның акылы һәм физиологиясе талчыкмаячак, ул уку материалын кире какмаячак. Тиз уку һәм хәтерне үстерү методикалары балаларга индивидуаль якын килүне исәптә тота. 4 кешедән гыйбарәт төркемнәрдә эшләү белем нәтиҗәләрен инде 10–12 дәрестән соң ук сиздерә. Барлык параметрлар буенча да. Шулай ук уку тизлекләре дә арта. Гомуми белем бирү мәктәпләрендә эшләүче педагоглар да, балаларның әти-әниләре дә эмоциональ тотрыклылыкны, эш сәләтенең артуын, баланың интеллекты үсүен ассызыклый. Ә сәбәбе гади: тренинг барышында баш мие структурасы активлаша, нейроннар арасындагы бәйләнешләр ныгый.

Тиз уку методикасы түбәндәгеләрнең үсешен тәэмин итә:

- күзләрнең күрү, колакның ишетү сәләте, күреп кабул итү хәтере;
- күрү сәләтенең тизлеге;
- артикуляцион аппарат;
- баш миенең сөйләм өчен җавап бирү үзәге;
- игътибарны күчерә алу, бүлә, туплый алу сәләте;
- арифметик-практик аң, математик мантыйк;
- уйлау-фикерләү тизлеге;
- күз мускуллары ныгый, күрү сәләте тотрыклылана, күзләр алга таба да мәктәп биргән йөкләнешкә күнегә.

Безнең компания белән эшләүнең өстенлекләре:

- Һәр клиентка индивидуаль якын килү. Персональ менеджер беркетеп, без сезнең проектны хезмәттәшлек итүнең бөтен процессы дәвамында үзебез алып барабыз.
- Тулы медиапакет тәкъдим итәбез. Ул үз эченә аудио-, видеорекламаны ала, мәкаләләр, брошюралар, листовкалар, баннерлар, тендерлар һәм компаниянең товар билгеләре дә шуңа керә.
- Уникаль шәхси тәкъдимнәр белән эш итәбез.
- Аз гына чыгымнар белән кертемнең тулаем кайтарылуын тәэмин итәбез. Методикаларның бәясе 50 меңнән башлана.
- Компания менеджерлары һәм тренерлары – үз эшенең профессионаллары. Күрсәтелә торган хезмәтләр пакетына сезнең персоналны укыту да керә.

Реклама 0+

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

facebook.com/protatarstan

twitter.com/protatarstan

instagram.com/protatarstan

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

Реклама 16+

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА
ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Җәлилчеләр турында **НӘРСӘЛӘР** беләбез

Алтын Урда
Үзбәк хан чорында **НИНДИ** булган

Тәтештә чишмәләр **НИЧЕК** барлыкка килгән

«ТУГАН ИЛДӘ БЕЗНЕҢ ЯЗМЫШНЫ БЕЛСЕННӘР ИДЕ...»

Август – җәлилчеләрне искә алу ае. Шул уңайдан, тарихка ретроспектива ясап, искә алырга булдык. Үзләрен генә түгел, ә аларны һәлакәткә китерүче вакыйгалар чылбырын да.

Автор:
Луиза Янсуар

Җәлил һәм җәлилчеләргә карата мөнәсәбәтнең шактый четерекле булуын, аларга кагылышлы бәхәсләрнең хәзерге көнгәчә тынмавын исәпкә алып, фактларга һәм документларга өстенлек бирү дөресрәк булыр. Фактлардан көчлерәк берни юк. Асылда, бу унберәүне кем төркеме дип атау да – бары тик рәсми акт кына. Алар – бер бәйләмдә: кайсыбыз баш та, кем муен, дип тарткалашып ятарга мөмкинлекләре дә, вакытлары да, теләкләре дә булмагандыр. Көн дә үлем тырнагы астында йөргән кешеләрнең шундый ситуациядә оеша, берләшә һәм көчләрен уртак бер максатка юнәлтә алулары – үзе зур батырлык.

Бәлки, шуңа (конспирация йөзеннән) ул «Җәлил» исемен сугышта чакта да, тоткынлыкта вакытта да кулланмый диярлек. Чыганакларда, хәтта төрмә документларында да «Гомәрев» фамилиясе теркәлгән. «Гомәров»ның чынлыкта кем булуын, нигездә, көрәштәш дуслары һәм ышанычлы кешеләр генә белгән.

«ИДЕЛ-УРАЛ ШТАТЫ», ЯКИ ТАТАРЛАРДАН ЛЕГИОН

Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең дошман тылындагы патриотик эшчәнлеге «Идел-Урал» легионы белән бәйле. Нәрсә соң ул «Идел-Урал»?

Татар-башкорт халыклары тарихында XX гасыр башында Россия эчендә Идел-Урал штаты дигән мөстәкыйль дәүләт төзү омтылышы булган. Икенче Бөтендөнья сугышы чорында Идел буе һәм Урал төбәкләре халыкларыннан аерым гаскәри частьлар оештыру башланганда, Идел-Урал штаты төзү проекты яңадан өскә калкып чыга. Теоретиклар мәсьәләне түбәндәгечә аңлата: 1918 елда большевиклар Идел-Урал штаты дигән милли республика төзүгә каршы төштеләр. Хәзер, Германия СССРны җиңү белән, һичшиксез, мондый республика төзеләчәк. Димәк, бу көнне якынайтыр өчен, Идел-Урал буе халыклары үзләре дә большевикларга каршы көрәш юлына басарга тиеш. Шул максаттан легион оешачак.

Әмма бу – теориядә. Асылда Гитлерның СССРны яулап алу һәм анда хакимлек итү планында татар-мөселман дәүләте төзү турында бернинди дә сүз булмый. Киресенчә, «кыргый халык» – азиатларны мөмкин кадәр күбрәк юк итәргә, ә исән калганнарын эш колы, немец ялчысы ролендә файдаланырга ниятлиләр. Шулай да Идел-Урал төбәгендә яшәүче милләтләрнең әсирләреннән торган

79 нчы укчы корпус солдатлары, Рейхстагны штурмлау алдыннан, Моабит төрмәсенә килеп чыга. Анда инде әсирләр дә, сакчылар да булмый. Ихатасында җил йөри, ниндидер папкалар янып бетеп килә. Сугышчыларның берсе таралып яткан төрмә китаплары арасыннан китаптан ертып алынган бер битне тартып чыгара. Анда рус телендә: «Я, известный поэт Муса Джалиль, заключен в Моабитскую тюрьму, как пленный, которому предъявлены политические обвинения и, наверное, буду скоро расстрелян. Если кому-нибудь из русских попадет эта запись, пусть передадут привет от меня товарищам писателям в Москве...»

Язуны кулдан-кулга йөртеп укыйлар. Арада Муса Җәлилне һәм аның шигырьләрен белгән татар солдатлары да була.

Фото: Мартин Мөхәмматҗанов

легионга «Идел-Урал» исеме бирелә. Бу исемне немецларга шушы легионны төзүдә актив катнашучы татар эмигрантлары тәкъдим итә. Әлбәттә, Гитлер Германиясе сугыш башында СССР халыклары вәкиллегенә мохтаҗ булмый. Мондый вәкиллек тоту аларны сәяси партнер дип тану булыр, милли-социалистик стратегия кысаларына сыймас иде. Әмма фронттагы хәлләр тора-бара башкача уйларга мәҗбүр итә. Башта немецлар милли вәкиллекләрне «Милли комитет» дип атарга да рөхсәт итми. Бу оешмалар немецларның көчле контроле астында эшли.

1944 елда Германиядә беренче тапкыр татар вәкиллеге оеша. Гади телдә аны «Идел-Урал комитеты» дип йөртәләр. Җитәкчесе булып Тышкы эшләр министрлыгының радиопропаганда бүлегендә эшләүче Әхмәт Тимер билгеләнә. Әмма ул аны озак җитәкләми, Төркиягә китеп бара. Татар комитеты җитәкчесе итеп Шәфи Алмасны куялар. 1944 елның 3–5 мартында Грейфсвальд шәһәрендә Идел-Урал халыклары вәкилләренең корылтае уза. Шәфи Алмас «Идел-Урал» легионының эшчәнлеге турында сөйли, Идел-Урал штаты төзеп, киләчәктә татар халкын мөстәкыйль дәүләтле итү идеясен күтәрә. Ул съездда катнашырга килгән Унгляубе, фон Менде һәм башка немецлар алдында, куштанланып, «мораль, матди һәм башка күп кенә мәсьәләләрдә «Татар арадашчылыгына» ярдәм иткәннәре өчен» рәхмәт укый. Фюрерга да олы рәхмәтләр белдерә. Корылтайда «Идел-Урал төрки-татар көрәш союзы»ның эш программасы кабул ителә, 11 кешедән гыйбарәт Президиум сайлана. Шәфи Алмас 1945 елның гыйнварына кадәр «Татар комитеты» президенты булып эшли. Гитлер Германиясе тар-мар ителергә берничә ай кала, барлык акчасын Швейцария банкына күчереп куя. Фашизм тар-мар ителгән көннәрдә яки шуннан соң ук Германиядәге күпчелек татар эмигрантлары Америкага китеп котыла.

Легионны төзү буенча практик эш 1942 елның 21 августында Едлино лагеренда башлана. 1942 елның 6 сентябрендә «Идел-Урал» легионына байрак бирелә. Командир итеп 67 яшьлек майор Оскар фон Зекендорф билгеләнә. Легионда дүрт хәрби батальон була. Шуларның 825 нчесе 1943 елның 23 февральгә каршы төнендә Белоруссия партизаннары ягына чыга. Батальоннарның башкалары да немецларга канәгатьсезлектән башка берни китерми. Бер-бер артлы партизаннар ягына чыга торалар. Күпләр совет гаскәрләренә әсир төшүдән курка. Союздаш гаскәрләргә бирелү ягын карый. Әмма андыйларның инде язмышлары күптән хәл итеп куелган була: СССР белән союздаш державалар арасындагы килешү буенча, Англия, Америка гаскәрләре ягына чыккан безнең ил кешеләре кабат СССР га кайтарыла. Ә туган җирендә, «ватанында», аларны Себер көтә.

РЕЙХ ИДЕОЛОГИЯСЕ, ЯКИ ТӨРКИ СС

1944 елның 2 маенда Гиммлер бер ел эчендә Көнчыгыш мөселман СС дивизиясе төзергә дигән боерык чыгара. Аны Һарун әр-Рәшид дигән кеше җитәкли. 1886 елда туган бу кешенең чын исеме – Вильгелм Хинтерзац. Беренче империалистик сугыш вакытында ул төрек генераль штабына җибәрелеп, төрек армиясе полковнигы булып хезмәт итә. Сугыштан соң Әнвәр пашаның киңәшчесе һәм штаб җитәкчесе вазыйфасын башкара. Ислам динен кабул итә, исемен үзгәртә.

Татарча «Көнчыгыш төрки СС хәрби берләшмәсе» бик акрын төзелә. Әсирләрне лагерьлардан берәмтекләп җыялар. Татар командирлары әзерләү максаты куела. 24 кешелек төркемне укытып чыгаралар. Әмма СС частьларындагы әлеге командирлар арасында да, немецлар көткәнчә, тәртип булмый. Мисал өчен,1944 елның 25 декабрендә Төркестан полкы командиры Гулам Алимов үзенә буйсынган 458 СС чыны ияртеп, Словакия партизаннары ягына чыга. Хәрби сводкаларда татарларның качулары турында да даими хәбәрләр чагылып тора.

Фашист Германиясенең җитәкчелек структурасында Гиммлер җитәкләгән СС органнарының роле искиткеч зур булган. ССны еш кына «дәүләт эчендәге дәүләт» дип йөрткәннәр. «Идел-Урал» легионында да яшерен СС агентлары бик күп була. Легион штабындагы, батальоннардагы хәлләрне күзәтеп торалар. Һәрбер батальонда шымчылар челтәре оештырыла. Германия империясенә каршы эш алып баручылар нигездә агентлар тарафыннан фаш ителеп тора. Алар патриотларны җәзалап үтерүдә актив катнаша – күпчелеген Бухенвальд, Освенцим, Майданек һ.б. үлем лагерьларына озаталар.

СС агентларыннан тыш, легионнарда Гитлер армиясенең Абвер контразведка бүлеге дә хәрәкәт итә. «Идел-Урал» легионында булганнарның һәр адымын алар контрольдә тота. Гадәттә җәлилчеләрне саткан кеше буларак Мәхмүт Җамалетдинов фигурасы күрсәтелә. Әмма моны тәгаен дәлилләнгән факт дип әйтеп булмый, чөнки «Эш»тә башка исемнәр дә теркәлгән. Аларга хәтта «очный допрос» та уздыралар. Шуны аңларга кирәк: унберәүнең эшчәнлеге турында материал җыючы һәм рейхка тапшыручылар берәү, икәү генә дә булмаска мөмкин.

Ышанычсыз булган өчен, Идел буе татарларын коралсызландырдык. Алар большевистик ышану белән йөриләр, урысча да сөйләшәләр, дингә дә артык бирелмиләр.

«Көнчыгыш төрки СС хәрби берләшмәсе» (КТХС) командиры Һарун әр-Рәшид, 12 гыйнвар, 1945 ел

Минем тарафтан 187 Идел-Урал татары, коралсызландырылып, хәрби әсирләр лагерена озатылды. Алар арасында политруклар да булган.

16 гыйнвар, 1945 ел

МӘХМҮТ ҖАМАЛЕТДИНОВНЫҢ ТИКШЕРҮ ЭШЕННӘН:

Сорау: Гайнан Кормаш белән ничек таныштыгыз?

Җавап: «1-це» (контрразведка) бүлегендә эшләүче офицер Һелле аның артыннан аеруча игътибарлы күзәтергә боерды.

Сорау: Кормаш белән нәрсә турында сөйләштегез?

Җавап: Ул башта мине читтән шактый озак күзәтеп йөрде. Аннары, комсомол сафларында булуымны белгәч, немецларны тозлап-борычлап сүгүемне ишеткәч (моны мин немецларның үзләренең кушуы буенча эшли идем), иркенрәк, үз итеп сөйләшә башлады... Легионда яшерен оешма барлыгы турында да киная белән генә, әмма аңларлык итеп әйтте.

Сорау: Бу турыда немецларга хәбәр иттегезме?

Җавап: Башка чарам юк иде. Алар һәр көнне миннән отчет алып тордылар.

Сорау: Ни өчен немецлар Кормашны һәм яшерен оешманың башка әгъзаларын шунда ук кулга алмады?

Җавап: Аларга матди дәлил – листовка кирәк иде. Һелле миннән листовка табып бирүне очрашкан саен таләп итте.

Фашизм режимы башында торган җитәкчелек, хәрби һәм сәяси планнарын тормышка ашырыр өчен, ислам факторын да ныклап файдаланырга ният кыла. Икенче Бөтендөнья сугышы башлангач, Палестинаның бөек мөфтие Әмин әл-Хөсәйни белән хезмәттәшлек итәргә керешәләр. 1941 елның 28 ноябрендә мөфтине Риббентроп һәм Гитлер кабул итә. Мөфти чыгышында: «Без Германиянең дуслары, инглизләр, яһүдләр, большевиклар – безнең дошманнар», – дип белдерә. Ул Германиядә кала, сәяси һәм дини тормышта актив катнаша башлый. Берлин мәчетендә, төрле җыеннарда вәгазь сөйли, брошюралар чыгарып тарату белән шөгыльләнә. Чираттагы бер чыгышында: «Германия мөселман илләре белән бер вакытта да сугышмаган, ул 40 миллион мөселманның тираны булган СССРга каршы көрәшә», – дигән сүзләр әйтә.

СССРның әсир төшкән мөселманнарыннан хәрби берләшмәләр төзү эшенә керешкәч, бу эштә ислам факторы мөһим роль уйнаячак, дип исәпли рейхтагылар. 1942 елның 12 декабрендә узган киңәшмәдә Гитлер да: «Мин бары тик мөселманнарны гына ышанычлы дип исәплим, башкаларга ышанмыйм», – дип ычкындырган була. 1944 елның 26 ноябрендә Дрезден шәһәрендә муллалар мәктәбе эшли башлый. Ул, нигездә, СС берләшмәсе өчен дин әһелләре әзерли. Курс һәм мәктәп тәмамлаучыларны мулла яисә обер-мулла чины биреп, төрле хәрби һәм эшче роталарга, батальоннарга, бригадаларга җибәрәләр. 1917 елгы Октябрь революциясеннән соң барлыкккка килгән системада, ягъни СССР да дингә мөнәсәбәтнең ничек булуын яхшылап өйрәнгән һәм белгән рейх башлыклары һәм фашист идеологлары татарларга зур өмет баглый.

«КОРМАШ ҺӘМ ТАГЫН УН КЕШЕ»

(Суд карарының кулдан язылган өземтәсе, Прага)

Фәат Булатов,
инженер,
1913.

12 сәгать 15 минутта

Абдулла Батталов,
легиончы,
1916.

12 сәгать 27 минутта

Гайнан Кормаш,
легиончы,
туган елы 1919.

12 сәгать 06 минутта

Муса Гомәров,
язучы,
1906
(сүз Муса Җәлил турында бара)

12 сәгать 18 минутта

Зиннәт Хәсәнов,
легиончы,
1916.

12 сәгать 30 минутта

Фәат Сәйфелмөлеков,
взвод командиры,
1916.

12 сәгать 09 минутта

Гариф Шабаев,
сәүдә хезмәткәре,
1907.

12 сәгать 21 минутта

Әхәт Атнашев
(һөнәре аңлашылмый),
1918.

12 сәгать 33 минутта

Абдулла Алишев,
легиончы,
1908.

12 сәгать 12 минутта

Әхмәт Симаев,
журналист,
1915.

12 сәгать 24 минутта

Сәлим Бохаров
(һөнәре аңлашылмый),
1918.

12 сәгать 36 минутта үтерелә

Җитәкчеләр буларак, Кормашев белән Сәйфелмөлековка хөкем карары да аерым язылган була: «дошманнарга ярдәм итү», «немец армиясен таркату». Башкаларга хөкем карары бергә язылган: «дошманга ярдәм итү», «Германиянең хәрби көчләрен таркату». Соңгы өч кешегә карар болай теркәлгән: «фетнәчеләр турында хәбәр итмәү» һәм «хәрби хыянәт».

«УЛ КӨННЕ ҺИЧ ОНЫТА АЛМЫЙМ...»

Усман мулла сөйләгәннәрдән: «1944 елның 20 августында Шәфи Алмас, чакырып: «25 августта Мусаларның үлем җәзасы җиренә җиткереләчәк икән, сиңа шунда барырга туры киләчәк, бу хакта Бөек мөфтидән хәбәр килде», – дип белдерде. Мин шул көнне иртән иртүк Плетцензее төрмәсенә барып, иң башта төрмәдәге поп белән күрешеп сөйләштем. Ул минем килүемә бик шатланды һәм татарларның сәгать 12 дә атылачаклары турында сөйләде. Попның сөйләвенә караганда, үлем җәзасына хөкем ителгән татарлар зур гына бер бүлмәдә яшәгәннәр һәм үзләренең атылачакларына һич тә ышанасылары килмәгән. Алар попны һәрвакыт яхшы каршы алганнар һәм шикаятьләрен белдереп торганнар.

Сәгать 11 тирәсендә поп белән бергә атылачак татарлар янына кердем. Үтереләчәк токыннар янына беренче мәртәбә баруым булганлыктан, каушап калдым, нәрсә әйтергә дә белмәдем, нәрсә әйтсәм дә килешмәс, дип уйладым. Ачык күренеп тора: барысының да күңелләре төшкән, барысы да аптыраште, шашып калган. Мин керү белән, башларын күтәреп миңа карадылар... Аларның соңгы минутларын көтеп утырулары чиксез сагышлы бер күренеш иде.

Иң башта Коръәнне Алишка суздым. Ул, акрын гына торып, кулын Коръәнгә салды һәм елап җибәрде. Барысы да җан җәрәхәтеннән михнәт чигәләр иде...

Гариф Шабаев янына барып, Коръәнне суздым һәм, ул кулын кую белән: «Җәберләмәделәрме?» – дип сорадым. «Юк, җәберләү булмады», – дип җавап бирде. Барысының янына барып, Коръәнне суздым, барысы да кулларын салып: «Бәхил, бәхил», – диделәр. Әхмәт Симай, кулын Коръәнгә салганнан соң: «Усман әфәнде, болай ук булыр дип көтмәгән идек, көтмәгән идек», – диде. Иң соңыннан Муса янына барып, Коръәнне суздым. Муса, Коръәнгә кулын салып: «Бәхил булыгыз, язмыш инде, язмыш, безне үтерерләр дип көтмәгән идек», – дип пышылдады».

АҢА КАДӘР – ПЛЕТЦЕНЗЕЕДА...

«Кулларына исемлек тотып, ике төрмә сакчысы килеп керде. Өч татарның исемен атап, аларга тиз генә киенергә куштылар. Тегеләр: «Кая барырга?» – дип сорагач, сакчылар: «Без берни дә белмибез», – дип җавап бирде. Ләкин татарлар үзләренең соңгы сәгате килгәнен шунда ук аңлады. Татарларның берсе үзе белән кечкенә фоторәсем алды. Алар чыгып киткәндә, без, бүтән беркайчан да очрашмаячагыбызны белгән дуслардай, кочаклашып хушлаштык. Татарларның башка камералардагылары инде коридорга чыккан, сөйләшеп торалар иде. Мин ишек төбенә килдем дә, гадәттәгечә: «Сәлам!» – диешеп, без Җәлил белән хушлаштык. Аннары аларны коридордан алып киттеләр. Камерага тагын сакчы кереп, аларның әйберләрен (хат яза торган кәгазь, трубка, юыну кирәк-яраклары) алып чыкты. Берәр сәгатьтән бүтән сакчылар кереп, тәлинкә, кашык, одеял һ.б. шуныңише нәрсәләрнең исемлеген төзеделәр, шул исемлеккә миннән кул куйдырттылар.

Шул ук көнне минем камерага падре Юрытко килде һәм сәгать 10 да татарларның барысын да асып үтерүләрен, аларның елмаеп үлүләрен хәбәр итте. Аларның камерадан ничек итеп үлемгә китүен мин күреп тордым. Алар бик тыныч иделәр...»

Рениеро Ланфрендини хатыннан

АҢА КАДӘР – БЕРЛИНДА...

«Идел-Урал» комитетын төзүдә катнашкан эмигрант Галимҗан Идрисинең улы, белеме буенча медик Илдар Идрисинең Муса Җәлил янына килеп, кием-салым, ризык тапшырганы була. Муса Җәлил аңа төрмә шартларының авырлыгын – ягылмавын, юеш һәм салкын булуын, йөткерү бик интектерүен, сорау алулар вакытында кыйнап бөерләрен эштән чыгаруларын, шуңа бите шешенүен сөйли. Бу очрашу Илдар Идрисигә гаять көчле тәэсир итә, ул шагыйрьгә һәм аның көрәштәшләренә ярдәм итү теләге белән яна. Ләкин ни Шәфи Алмас, ни Германиядәге башка эмигрантлар Җәлил белән аның иптәшләрен баладан йоларга атлыгып тормый. Ә Илдарга нибары 17 яшь. Шулай да Илдар әтисен баш мөфти белән сөйләшергә күндерә. Мөфти янына үзе дә барып, аңа Җәлилнең татар әдәбиятында һәм гомумән бөтен мөселман дөньясында атаклы шагыйрь булуы хакында сөйли. «Мин, – ди ул, – шагыйрьне бөтенләй азат иттерә алырсыз дип ышанмыйм. Шулай да аның җанын саклап калырга көчегез җитәр дип уйлыйм».

Мөфти Илдарны игътибар белән тыңлый, кайбер нәрсәләрне язып та ала. Бу хакта Гиммлерның үзе белән сөйләшеп карарга вәгъдә бирә. Бераздан мөфти белән Илдар Идриси кабат очраша. Мөфти аның үтенечен җиренә җиткергәнен, тиз арада җәлилчеләрнең «Эше» яңадан каралачагын әйтә. *(Бу хакта башка чыганаклардан да мәгълүм.* – **Ред.)** Хәбәрне ишеткәч, егетнең күңелендә өмет уяна. Ләкин берничә көннән Шпандау төрмәсенә баргач, аңа Җәлилнең инде бу төрмәдә булмавын, үлемгә хөкем ителгән тоткыннарны җәзалап үтерә торган Плетцензеега күчерелүен әйтәләр.

Илдар ул төрмә надзирателе белән дә очрашып сөйләшә. Надзиратель аңа татарларның үлеме гаҗәеп дәрәҗәдә тыныч, үзләре сабыр булуы хакында сөйли. Алар үлемне эчке бер ныклык белән каршыладылар, «үлем йортына» *(Плетцензее төрмәсендәге җәзалау бинасы шулай дип атала.* – **Ред.)** барганда үз телләрендә ниндидер җыр җырладылар, ди.

Ул татар-башкорт җыры «Сибелә чәчәк» була.

АҢА КАДӘР – ПЛЕТЦЕНЗЕЕДА

«Шагыйрь белән Булатов үзләренә рәхимлелек булыр дип ышаналар иде. Чөнки хөкем карары чыгарылганга инде күп вакыт үткән... **(***Хөкем карары февральдә чыгарыла, августта тормышка ашырыла.* – **Ред.)** Шагыйрь күп яза иде. Язуын күп язды, ләкин язганнарын, вак кисәкләргә ертып, камерадагы унитаз тишегенә ташлый иде. Атнага өчәр-дүртәр мәртәбә тентиләр бит... *(Муса Җәлил нинди кәгазь кисәге таба, шуларга, падре Юрытко төрмә китапханәсеннән китергән китапларга яза торган була. Кызганыч, ул китаплар сакланмаган.* – **Ред.)** Кайчакта бер ноктага текәлеп, бик озак уйга калып утыра. Ара-тирә: «Йә, Алла!» – дип көрсенеп куя. Кайчак: «Немецларның да хәле мөшкел булачак», – ди.

«Рус хөкүмәте башлыклары безнең хәлдәге кешеләргә карата рәхимлелек күрсәтерләр иде. Гаепле кешеләргә җәзасын бирүен бирерләр (Себергә эшкә җибәрерләр), әмма тормышларын саклап калырлар иде», – дип әйтә. Еш кына үзенең туган иле, гаиләсе, әнисе турында сөйли, үлә калса, аны илендә онытмаслар, дип ышана...

Безгә көн саен җидешәр сигарет бирәләр (аларны тик үлемгә хөкем ителгән тоткыннарга гына бирә торганнар иде). Һәр җомга көн алмашка эчке киемнәр китерәләр. Камерага керәләр, сине анадан тума калдырып чишендерәләр, җентекләп тикшерәләр. Кайчакта тентергә СС солдатлары да килә...

Еш кына без, вакыт үткәрер өчен, үзебезгә кадәр үлемгә хөкем ителгән кешеләрнең стенага язып калдырган исемнәрен, үтерелгән вакытларын укып утыра торган идек... Падре Юрытко шагыйрь белән озаклап гәпләшеп утыра, яңалыклар сөйли. Ул шагыйрьнең запискаларын башка камераларга (татарларга) алып китә, икенче көнне аларга җавап алып килә. Кәгазь, икмәк, теш щеткасы, теш пастасы кебек әйберләрне дә ул алып килә. Бар кешегә карата да ярдәмчел иде...

1944 елның 20 июлендә без төрмә сакчыларыннан Гитлерга һөҗүм булганын ишетеп белдек. Безнең күңелләрдә бик зур ышаныч туды. Әмма ул ышаныч тиз сүнде. Уңышсыз һөҗүмнән соң төрмәләрдә массалап үтерә башладылаар – берьюлы 17 шәр кешене...»

АҢА КАДӘР – ПЛЕТЦЕНЗЕЕДА...

Билгесез әсир авызыннан:

«Хәрбиләрне җәзалау тәртибе буенча, ату ысулы белән дә түгел, гражданнарны җәзалау тәртибе буенча, гильотина ысулы белән дә түгел, ә бөтенләй ерткычларча һәлак итә башладылар. Халык суд палатасы рәисе Роланд Фрейслерга фюрер мондый инструкция биргән: «Гаеплеләрне суйган терлекне элгән кебек итеп элеп чыгыгыз. Башкаларга гыйбрәт булсын».

Аларны Плетцензее төрмәсе түшәменә ит эләр өчен кулланыла торган ыргакларга рояль кыллары тарттырып асып чыгалар. Җәзаланучылар муены тартылудан һәм озакка сузылган буылудан берничә тәүлек газапланып үлде. Моннан тыш, җәзалау актын фотоаппаратка һәм софитлар яктысында кинопленкага төшереп бардылар. Сөйләүләре буенча, Гитлер бу кадрларны солдатларына хәрби рухларын күтәрү һәм ныгыту өчен күрсәтә торган булган...»

АҢА КАДӘР – БЕРЛИНДА...

1944 елның 20 июле.

«Бүген шартлаткыч кулланып, фюрерның гомерен өзмәкче булдылар. Һөҗүм вакытында фюрер җиңелчә җәрәхәтләр алды, әмма исән калды. Ул кичекмәстән үз эшенә кереште...»

1944 елның 21 июле.

«Бүген мин, фюрерыгыз, сезгә үзем мөрәҗәгать итәргә булдым. Сез минем тавышымны ишетергә тиешсез. Миңа һөҗүм иткән акылсыз һәм намуссыз офицерларның хыянәте, һичшиксез, ачылачак. Алар үз җәзасын алачак...»

Берлин радиосы хәбәрләреннән.



АҢА КАДӘР – ДРЕЗДЕНДА...
«Германия һәм немец халкы алдында сез үзегез – җинаятьче»
Февраль, 1944 ел

Суд булыр алдыннан җәлилчеләр утырган камераларга адвокат – бер эмигрант татар кешесе кереп йөри. Симаевның әйтүенә караганда, ул тоткыннарны: «Эшләгән эшләребез өчен үкенәбез, гаебебезне таныйбыз һәм аны эшебез белән юарга әзербез», – дип, судтан миһербанлык кылуны сорарга үгетли. «Шулай иткән тәкъдирдә генә сезнең тормышыгызны саклап калырга мөмкин булачак», – ди. Ләкин җәлилчеләрнең берсе дә моңа риза булмый, «агитатор»ны камераларыннан куып чыгара.

12 февраль, 1944 ел

Гаепләнүчеләр бер-берсен бары тик суд залында гына күрә. Баш кагып исәнләшәләр. Гаепләү нотыгын сөйләгәндә, прокурор көрәштәш дусларны Герман командованиесенең «зур ышанычыннан явызларча файдаланып, рейхка каршы корткычлык алып барган бандит-шпионнар группасы» дип атый, аларга үлем җәзасы бирүне таләп итә. Судьяның: «Гаебегезне танышсызмы?» – дип соравына токыннар: «Безнең бернинди гаебебез дә юк. Без тик Туган ил алдындагы бурычыбызны гына үтәдек», – дип җавап бирәләр.

Хөкем ителгәннәр исеменнән соңгы сүзне Муса Җәлил әйтә. «Германия һәм немец халкы алдында без түгел, бәлки сез үзегез, Гитлер палачлары, җинаять эшләдегез», – ди ул. «Фашизмны җиңү өчен кулыбыздан килгән кадәр эшли алуыбыз өчен без горурланабыз, бары көрәшебезне тагын да дәвам итә алмаганга гына үкенәбез», – дип тә өсти.

Җәлил сөйләгән вакытта аңа кимсетү сүзләре кычкыралар. Сораулар биреп, бүлдерәләр. Аннары, «болар барысы да большевиклар пропагандасы», дип, бөтенләй сөйләвеннән туктаталар. Ләкин аның әйтергә өлгергән сүзләре тоткыннарга рух күтәренкелеге, көч өсти. «Без барыбыз да ил алдындагы бурычыбызны үтәвебез өчен горурлык хисе тойдык», – ди Әхмәт Симаев.

Судья алардан: «Соңгы үтенечегез нинди булыр?» – дип сорый. Җәлилчеләр беравыздан: «Безнең исемнәребезне һәм язмышыбызны Туган илдә белсеннәр иде...» – дигән теләк белдерә. Судья аларның бу үтенечен: «Сезне тик фюрерга хезмәт иткән хыянәтчеләр итеп кенә беләчәкләр», – дип, мыскыллап кире кага.

АҢА КАДӘР – ЕДЛИНОДА...
1942–1943 еллар

«Легионда, әсирләрнең күңелен күтәрү өчен, музыка капелласы оештырылды. Муса Гомәров белән «талантлы кешеләр артыннан» Демблинга килдек. Кормаш белән киңәшеп, Ватанга бирелгән ышанычлы егетләрне капеллага алып китәргә булдык. Барлыгы 13 кеше җыелды. Абдулла Батталны немецларга шагыйрь дип тәкъдим иттек. Ул бик күп шигырьләрне яттан белә иде. Зиннәт Хәсәновны, җырлый белмәсә дә, хор солисты дип атадык. Ул Гайнанның якын дусты, тыйнак, тәвәккәл кеше, фашистларны бөтенләй күралмый иде. Гарәф Фәхретдиновны Казан филармониясе җырчысы дип йөрттек. Аның консерваториядә уку түгел, үз гомерендә Казанны да күргәне булмаган. Дим Алиш дигән псевдоним бирдек. Татар-башкорт әсирләре аның җырлавын аеруча ярата иде. Тора-бара Гарәф җырлый да, бии дә, Муса белән Гайнан язган пьесаларда төп рольләрне дә уйный башлады. Фоат Сәйфелмөлековны, җырлый белмәсә дә, хор артисты дип йөрттек. Ул сәяси яктан нык тәҗрибәле кеше иде. Соңрак, яшерен оешмага пропагандистлар кирәк булгач, аны һәм Гали Корбановны бу эшкә тәгаенләдек. Чыгышлары вакытында алар, немецларга сиздермичә, көлкеле сүзләр аша әсирләргә совет гаскәрләренең якынлашуын, гитлерчыларның һичшиксез җиңеләчәген аңлата иделәр.

Шулай бервакыт музыкаль команда Берлинга экскурсиягә барды. Бу эшне Муса Җәлил оештырды. Берлинның атаклы зоопаркына сәяхәт кылдык. Хайваннарны карап йөргәндә, Муса, минем белән Гайнан янына килеп, фашистларга каршы көрәшне ничек итеп киңрәк җәелдерү буенча үз тәкъдимнәрен әйтте. Ике пачка листовка бирде. Гайнан белән без аларны тиз генә яшердек. Экскурсиядән канатланып кайттык. Капеллада эш тагын да җанланып китте. Концертлар куябыз, кайчагында артистларга Муса да кушылып китә. Шул арада башка яшерен оешмалар белән элемтә урнаштыра, листовкалар тарата...

Эш уңай нәтиҗә бирде – 825 нче батальон, Белоруссия партизаннарына каршы сугышка җибәрелгәч, безнекеләр ягына чыкты. 1943 елның 8 августында яшерен киңәшмә булды. Муса поляк партизаннары белән бәйләнеш булдырылуын әйтте. Легионда баш күтәреп, барлык личный составны кораллары һәм атлы артиллерия белән партизаннар ягына чыгару максаты куелды. Һәркемгә конкрет задание бирелде. 9 августта тагын бер җыелдык. Абдулла Баттал белән Зиннәт Хәсәнов Берлиннан яшерен листовкалар алып кайтып өләште.

10 августта Муса Җәлил кинәт кенә лагерьдан юкка чыкты. 11 августта барлык музыкант һәм артистларны репетициягә дип җыйдылар. Барак һәм ашханәләрне немец офицерлары чолгап алды. Бер бүлмәгә кертеп яптылар да сорау ала башладылар. Баракны тентегәндә, листовкаларга юлыкканнар икән. Барлыгы 40 тан артык кеше кулга алынды.

Безне Варшава төрмәсенә китереп яптылар. Ялгыз камерада утырдык. Күп мәртәбә кыйнадылар, бер-беребезгә яла ягарга тырыштылар. Барлык кыйналу-җәберне сыкранмыйча күтәрдем. Туктаусыз шушы җөмләне кабатладым: «Мин гади солдат, ветеринар, контузия аркасында әсир төштем, бернинди яшерен оешма, листовка турында да белмим... Мин гади солдат, ветеринар...»

Җәлилчеләрне җәзалап үтергән гильотина. Җәза 12 сәгать 00 минутта башланырга тиеш була, әмма, кайбер версияләргә караганда, «үлем машинасын» юарга, чистартырга кирәк булганлыктан, 6 минутка кичегә. Бу машинага кадәр Муса Җәлил белән аның көрәштәш дуслары 114 адым үткән.

Материалны әзерләгәндә Рафаэль Мостафинның «Өзелгән җыр эзеннән...», «Красная ромашка», «По следам поэта-героя», Хәйдәр һәм Айдар Басыйровларның «Ватанга тугры калдылар», «Муса Җәлил. Муса Джалиль» фотоальбомы, архив материаллары, истәлекләр, хатлар кулланылды.



ҮЗБӘК ХАН ҺӘМ АНЫҢ УЛЫ ҖАНИБӘК

Чыңгыз-ханның «атка атланып бихисап илләрне яулап алырга мөмкин, әмма ул илләр белән атка атланып, ягъни көч кулланып кына идарә итеп булмый» дигән алтын сүзләренә таянып, Алтын Урда ханнары Батудан башлап Үзбәк ханга кадәрге җитмеш ел чамасы (1243–1312) яшәү дәверендә төп көчне дәүләтнең идарә итү системасын камилләштерүгә юнәлтәләр.

Автор:
Фаяз Хуҗин

Нәтиҗәдә Алтын Урда дөньяның шул замандагы иң көчле дәүләтләре рәтенә баса. Үзбәк хан белән аның улы Җанибәк идарә иткән ярты гасыр чамасы вакыт эчендә монгол-татар дәүләте дөнья цивилизациясе дәрәҗәсенә күтәрелә. Кызганыч, тотрыклы үсеш озак дәвам итми.

Мәңгү-Тимер вакытында (1266–1282 еллар) Алтын Урда Монгол империясеннән аерылып чыга, тулысынча мөстәкыйль дәүләткә әверелә, дигән идек. Ул үлгәннән соң, Алтын Урда тәхетенә аның энесе Тәдән-Мәнгү (Туда-Менгу) утыртыла. Йомшак табигатьле, олы дәүләт белән идарә итүгә сәләтсез ханны 1287 елда тәхеттән куалар. Хан итеп дәүләтнең эчке сәясәтендә зур роль уйнаган Нугай мирза тарафдарлары Телә Буганы (Тула-Буга) сайлап куялар. Тәхеткә утырганчы, Нугай мирза белән Венгриягә һәм Польшага яу чабарга өлгергән була ул, хан булып алгач, Рязань һәм Муром кенәзлекләрен талап кайта. Әмма аны да хан итеп озак тотмыйлар. 1291 елда Нугай мирза булышлыгы белән тәхетне Мәнгү-Тимернең улы Токта (Тыктай, Туктагу) яулап ала. Хан ролен бик тиз керә ул. Нугайның төрле юллар белән төп идарәче урынына омтылуын да аңлап ала, аңа каршы көрәш башлый һәм үзен тәхеткә утырткан хәйләкәр сәясәтчене көчләп бакыйлыкка озата. Токта хан идарә иткән чорда Алтын Урда тотрыклы үсеш чорына баса.

ҮЗБӘК ХАН ДӘВЕРЕНДӘ – УРДА

1312 елда Алтын Урда тәхете Мәнгү-Тимернең оныгы Үзбәк ханга кала (тәхет варисы Илбасар шаһзадә Токтаның үзеннән алда үлгән була). Ул бик озак – 1342 елга кадәр, ягъни утыз ел дәвамында идарә итә. Үзбәк хан чорында Алтын Урда дөньяның иң зур (билгән җирләре ягыннан караганда) һәм иң куәтле дәүләте буларак таныла. Археологлар исәпләвенчә, илдә йөздән артык эреле-ваклы шәһәрләр була. Аларның шактые, Сарай-Бату (Сарай әл-Мәхрусә, Иске Сарай), Сарай-Бәркә (Сарай әл-Җәдид, Яңа Сарай), Мухшы, Үкәк, Бәлҗәмин, Маҗар ишеләре, – монгол ханнары вакытында калкып чыккан шәһәрләр. Бәркә хан вакытында төзелә башлаган Сарайны Үзбәк хан үзенең яңа башкаласы итә. Шунысы игътибарга лаек – яңа шәһәрләр бернинди ныгытмаларсыз төзеләләр. Сәбәбе бик гади – ул вакытта монгол ханнарына каршы торырлык тышкы дошман булмаган.

Сүз уңаеннан, үзебезнең шәһри Болгарыбызны да искә алып үтик. Белгәнебезчә, монголларга кадәр ул әле кечкенә, әмма эре сәүдә үзәге буларак дөнья базарында танылган бер шәһәр була. Болгарның үсеше Алтын Урда чорында дәвам итә. Монголлар һөҗүме вакытында җимерелгән саклану нығытмаларын яңадан торгызып мәшәкатьләнмиләр, әмма шәһәр территориясе сизелерлек киңәя. XIV гасыр башларына аның мәйданы инде 100 гектардан артып китә. Бүгенгә кадәр сакланган таш-кирпеч архитектура һәйкәлләренең барысы да XIII гасыр ахырына – XIV гасыр урталарына карый. Үзбәк хан чорында Җәмигъ мәчете төзелеп бетә, Хан төрбәләре янында Кече манаралы мәчет, шул тирәдә генә Кара пулат, җәмәгать мунчалары торгызыла.

Алтын Урда шәһәрләрендә һөнәрчелек чәчәк ата. Тимер һәм төсле металлар эшкәртү, алтын-көмештән, кыйммәтле ташлардан бизәнү әйберләре ясау, керамик эшләнмәләр (савыт-саба, балалар уенчыклары, сууткәргеч торбалар, бигрәк тә төзелештә кулланыла торган өсте ялтыравыклы плитәләр) җитештерү тармаклары алга китә, алар эшләп чыгарган югары сыйфатлы продукция дөнья базарында дан тота.

Шәһәрләр тиз арада халыкара сәүдә үзәкләренә дә әвереләләр. Бөек ефәк юлы һәм аның төньяк тармагы – Бөек Идел-Чулман юлы буйлап Шәрык (Кытай, Һиндстан, Иран, Хәрәзем, Византия, Мисыр) һәм Гареб (Италия, Испания, Франция) илләреннән, ерак Скандинавиядән кыйммәтле товарлар төягән кораблар Алтын Урдага агыла. Коры юл буйлап килүче сәүдә кәрваннарына бернинди куркыныч янамаган, аларны хан тарафынннан махсус билгеләнгән хәрбиләр юлбасарлардан саклаган, төн кунарга исә сәүдәгәрләрне уңайлы кәрван-сарайлар көткән. Иң мөһиме – чит илләрдән кертелә торган товарлардан алына торган сәүдә пошлинасы 3–5 проценттан артмаган. Үзбәк хан тарафыннан тудырылган әлеге уңайлы шартлар нәтиҗәсендә халыкара сәүдә дәүләт казнасына иң күп керем бирүче тармакка әверелгән. Дәүләт казнасын баетуга, һичшиксез, Алтын Урдага буйсындырылган халыклар да үз өлешен керткән.

Үзбәк хан үзенә тикле идарә иткән Токта ханның төрле төбәкләрдә сугыла торган акчаларны унификацияләүгә юнәлдерелгән реформасын дәвам иттерә, налоглар җыю системасын камилләштерә, нәтиҗәдә илнең бердәмлеген тотрыклы рәвештә саклау өчен күп көч куя, аны үзәкләштерү сәясәтен үткәрә.

Үзбәк хан тышкы сәясәт өлкәсендә дә уңышлы гына эшләп килгән. Рус кенәзлекләрен һәрдаим күзәтчелек астында тоту өчен зирәк һәм хәйләкәр, кайчакта икейөзле сәясәт алып барган. Мәсәлән, 1317 елда ул Мәскәү кенәзе Юрий Даниловичны рус кенәзлекләре арасында иң көчлеләреннән саналган Владимирның бөек кенәзе итеп раслый һәм аңа үзенең Кончак исемле сеңлесен кияүгә бирә (чукындырылгач, Агафья исемен йөртә). 1327 елда Мәскәү кенәзе Иван Данилович (тарихка Иван I Калита исеме белән кереп калган) ярдәме белән Тверьда Алтын Урдага каршы оештырылган восстаниене бастыра. Тулаем алганда исә, Үзбәк хан вакытында Алтын Урда белән рус кенәзлекләре арасында телгә алып сөйләрлек каршылык булмый. Кенәзләр арасында Үзбәк ханның абруе көннән-көн үсә һәм ул абруй Җучилар дәүләтенең икътисадый куәтенә нигезләнгән була.

Күренекле дин галиме һәм тарихчы Ризаэддин Фәхретдин фикеренчә, «Үзбәк хан алдан күреп эш итүчән, гакыллы, галиҗәнап падишаһ булса да, сәяси җәһәттән зур бер ялгышы инкяр ителмәс. Бу ялгыш Мәскәү кенәзлеген куәтләндереп, Урдага каршы киләчәк дошман хәзерләүдән гыйбәрәт иде. Үзбәк хан гамәлдә үз араларында сугышып, кырылышып торган вак кенәзләрне бетереп, бер ноктага җыйды. Шул сәбәпле урыслар куәт алып киттеләр».

«ОҖМАХ ШАРТЛАРЫ ТУДЫРУЧЫ»

Алтын Урда алып бара торган тышкы сәясәтнең әле Бәркә хан заманыннан ук башланып киткән тагын бер мөһим юнәлеше – Хулагу Иранына каршы көрәш. Хулаху-хан – Чыңгызханның оныгы һәм 1220–1250 елларда яулап алынган дәүләтнең беренче хаки-

ме. Ул дәүләт хәзерге Әфганстан, Иран, Ирак, өлешчә Азәрбайҗан, Грузия һәм Әрмәнстан территориясендә яшәгән күпмилләтле халыкларны берләштергән. Хулагу-хан үзе оештырган дәүләт территориясенә Чыңгызханның улы Җучига вәгъдә итеп калдырган биләмәләрен дә керткән. Ул биләмәләр – Кавказ аръягында урнашкан азәрбайҗан, әрмән һәм грузин җирләре – Хулагулар дәүләте белән Алтын Урда арасында гел бәхәсләр тудырып торган. Үзбәк хан вакытында да, тәгәлрәге, 1319 һәм 1335 елларда, шул җирләргә яу чапканнар. Үтереш-суешлар, җимерүләр-ватулар күп булган, әмма дәүләт чикләрендә үзгәрешләр булмаган диярлек: Кавказ аръягы Хулагулар ягында, Дәрбәнд (Дербент) һәм Төньяк Кавказ Алтын Урда ягында кала биргән.

Үзбәк хан илчеләре Алтын Урда белән Көнбатыш Европа дәүләтләре, Византия, Һиндстан һәм бигрәк тә Мәмлүкләр Мисыры арасында дустанә мөнәсәбәтләр урнаштыруда актив эшләгәннәр. Әлеге дипломатиянең уңай нәтиҗәсе беренче чиратта икътисадның үсешендә һәм халыкара мәдәни багланышларның җанлануында чагылыш тапкан.

Алтын Урда ханнарының иң мәшһүрләре арасында да Үзбәк хан үзенең уңай яклары белән нык аерылып тора. Аны бигрәк тә мөселман илләрендә яратканнар һәм әле хәзер дә хөрмәт итәләр. Бу аңлашыла да, чөнки Үзбәк хан вакытында ислам рәсми рәвештә Алтын Урданың дәүләт дине буларак кабул ителә. Дөрес, мондый омтылыш әле Бәркә ханда да була, ул үзе дә ислам дине тоткан. Әмма Урданың шактый өлеше әле һаман да мәҗүси аллаларга табынганнар. Болгарларда һәм Урта Азия халыкларында гына мөселман диненең берничә йөз еллык тарихы булган. Бер Аллага табыну, әлбәттә инде, халыкларның берләшүенә, илнең тотрыклануына китергән, бердәм татар халкы формалашуына уңай тәэсир ясаган.

Шунысы игътибарга лаек: ислам дине рәсми дәүләт дине саналса да, илдә дини толерантлык, вөҗдан иреге һәи тигезлек хөкем сөргән, ягъни, ислам белән бергә башка диннәргә дә иркенлек бирелгән. Үзбәк ханның 1319 елда рус метрополиты Петрга бирелгән ярлыгын Ризаэддин Фәхретдин «православие өчен чикләнмәгән ирек бирүче, аңа оҗмах шартлары тудыручы» документ дип атады. Бу тарихи ярлыкта, аерым алганда, «кем дә кем христиан динен сүксә, чиркәү, монастырь, часовняларга тел тидерсә, ул адәм үтерелер», дигән сүзләр бар иде.

Ислам дине кабул итү мәдәниятнең үсешенә дә уңай шартлар тудырган. Шул заман тарихчысы Ибн Гарәпшаһ язганча, Сарай шәһәре Үзбәк хан вакытында фән һәм мәдәният үзәге булып торган, биредә күренекле галимнәр, атаклы телчеләр, шагыйрьләр, остазлар-укытучылар һәм башка бик күп хөрмәтле кешеләрдән торган көчле бер зыялы төркем эшләгән. Башкалада һәм илнең башка эреле-ваклы шәһәрләренә төрле уку йортларының киң челтәре формалаша. Биредә, ерак Шәрык илләреннән килгән танылган дин белгечләре, галимнәр укыткан. Күп кенә галимнәр, шагыйрьләр берничә тел белгәннәр, әсәрләрен төрки, гарәп, фарсы телләрендә иҗат иткәннәр. Исегезгә төшереп үтим: Котб исемле шагыйрьнең «Хөсрәү вә Ширин» исемле атаклы әсәре нәкъ менә Үзбәк хан заманында язылган (1342).

УРДА ЧАТНЫЙ БАШЛАГАНДА...

Үзбәк хан 1342 елның мартында вафат була. Тәхет варисы – аның олы улы Тәнибәк – ул вакытта Чыгытайлар олысына яу белән киткән була. Шуннан файдаланып, Үзбәкнең Тайдула исемле хатыны тәхеткә уртанчы улын – Җанибәкне утыртырга ниятли. Һәм теләгенә ирешә дә. Яудан кайткан җиреннән Тәнибәк тә, аның икенче энесе Хызр да юкка чыгалар, үтереләләр.

Җанибәк хан үзенең ундүрт ел буена хакимлек итү дәверендә әтисенең дәүләт белән җитәкчелек итүдәге эчке һәм тышкы сәясәтен дәвам иттерергә омтыла. Ул хакимлек иткән чорда яңа шәһәрләр барлыкка килә, искеләре төзекләндерелә, һөнәрчелек остаханәләрендә эш кайный, мәктәп-мәдрәсәләрдә укулар бара, хан сараенда галимнәр, шагыйрьләр, музыка коралларында уйнаучылар чыгыш ясыйлар.

Алтын Урда белән рус кенәзлекләре арасында элекеге «ярлыклар белән уйнау» сәясәте үзенең тормышчанлыгын раслый, вассал кенәзләрне хан каршында биютеп тору өчен Җанибәк тә көчен кызганмый. Мәмлүкләр Мисыры белән дә Хулагу Иранына каршы юнәлдерелгән дустанә мөнәсәбәтләр дәвам итә.

Әмма уңышларга юлдаш булып Алтын Урда тормышында аның киләчәгенә куркыныч яный торган тискәре күренешләр дә пәйда була. Мәсәлән, күрше Польша короле Казимир элек Алтын Урдага буйсынган Галиция белән Волынь җирләрен үзенә тартып ала, ә Литва кенәзе Ольгерд чик буе шәһәрләреннән берничәсен үзенеке итә. Җанибәк сизеп тора: моңарчы ханга ихластан хезмәт итүче кайбер төбәк бәкләре дә Урдадан аерылып, үзләренә мөстәкыйльлек алып яшәү теләге белән яналар.

Шул хәвефле хәлләргә тагын берсе килеп кушыла: 1346 елда Алтын Урдага чума зәхмәте килеп җитә. Ул бик тиз Каспий, Азов һәм Кара диңгез буендагы төбәкләргә тарала, Көнбатыш Европа илләренә килеп җитә. Чума зәхмәтеннән дистәләрчә, йөзләрчә мең халык кырыла. Алтын Урда өчен дә бу зур фаҗига була.

1357 елда Җанибәк гаскәрләре Төньяк Азәрбайҗан җирләренә басып кереп, Тәбриз шәһәрен кулга төшерәләр. Басып алынган җирләр белән идарә итүне Җанибәк үзенең улы Бәрдебәккә тапшыра.

Сугышчылар олы табыш белән Сарайга юнәләләр. Юлда Җанибәк каты авырый башлый. Сарайга кайтып җитүгә әтисенең авыруы турындагы хәбәрне Бәрдебәккә юллыйлар. Шатлыклы хәбәр иясе Бәрдебәк – тиздән ул хан булачак! – әтисе янына ашыга. Әмма аны Сарайда көтелмәгән яңалык каршы ала – Җанибәк сихәтләнеп килә. Хан киңәшчесе Туглы бәй тәкъдиме белән оештырылган заговор уңышлы булып чыга: Бәрдебәк әтисен бакыйлыкка озата.

«Җанибәк хан һәртөрле халыклар, бигрәк тә урыс һәм христианнар өчен гаять мәрхәмәтле бер падишаһ иде, – дип яза Риза Фәхретдин. – Ифрат динле, гадел, дәрвиш сыйфатлы, хәерле фикер йөртүче, тугры зат булды». Бәлки шулайдыр да. Әмма аның ике энесен үтереп тәхет хуҗасы булганын да онытмыйк. Хуш, үзе дә сөекле улы кулыннан гүр иясе була. Заманасы шулай булгандыр инде..

МАХСУС ПРОЕКТ

— 34нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

ТАТАРСТАНДА СӘНӘГАТЬ ЮЛЫ БЕЛӘН НЕФТЬ ТАБА БАШЛАУНЫҢ 75 ЕЛЛЫГЫНА

СКВАЖИНА №1

Язма чыганакларга караганда, төбәкнең нефтькә бәйле тарихы, Пушкарский приказы материалларында искә алынуга ярашлы рәвештә, үзенең исәбен 1637 елдан бирле алып бара. Зур нефтьне эзләү XX гасырның 30 нчы елларында гына активлашып китә. Аның Идел-Урал төбәгендә барлыгын СССР да нефть сәнәгатен оештыручыларның берсе – И. М. Губкин фаразлый.

СУГЫШ БАРГАН ЧАКТА

1941 елда Германия белән сугыш башлангандагы бик авыр шартларда Шөгер авылы янәшәсендә 1 нче скважинаны разведка өчен бораулау башлана. 1943 елның 25 июлендә көтелгән нәтиҗәгә ирешәләр: Татарстанда беренче тапкыр нефтьнең сәнәгать күләме алына. Шулай итеп, Шөгер чыганагы ачыла: Татарстанның зур нефть тарихы әнә шуннан башланып китә. Әмма ул, халыкара квалификация буенча исәпләсәк, гаҗәеп зур Ромашкино чыганагының нибары бер чите генә булып чыга. Ромашкино чыганагы исә 1948 елның июнендә Тимәш авылы (Ромашкино) янында 3 нче скважина бораулау нәтиҗәсендә ачыла һәм шулай ук тарихига әверелә.

Татарстан илебездә һәм чит илләрдә дә зур нефть төбәге буларак танылa. Республика исә нефть тармагында яңа технологияләр һәм алдынгы техниканы сынау мәйданчыгына әверелә. Биредә беренче тапкыр контур эченә су тутыру ысулы кулланыла, соңрак ул дөнья күләмендә классик ысулга әйләнә.

ҖИМЕРЕКЛЕКЛӘР ФОНЫНДАГЫ ТИЗЛӘНЕШ

1949 елның гыйнварында «Татарнефть» тресты төзелә. СССР Министрлар Советының «Татарстан АССРда нефть табу үсешен тизләтү чаралары турында»гы 1950 елның 28 апрелендәге карары үзе бер этап була. Документ «Татнефть» берләшмәсен булдыруны күздә тота. Берләшмә башлыгы итеп А.Т.Шмарев билгеләнә.

1950 елда республикада 860 мең тонна «кара алтын» табыла. Әмма сугыш җимергән халык хуҗалыгын торгызу һәм ил икътисадын алга таба да үстерү өчен нефть торган саен күбрәк таләп ителә. 1952 елның 24 мартында илебез Хөкүмәтенең тагын бер карары кабул ителә – «Татарстан АССРда һәм Башкортостан АССРда нефть сәнәгатен үстерүне тизләтү турында». Кыска срокларда Татарстанның көньяк-көнчыгышында көчле җитештерү һәм төзелеш көчләре туплана. Төбәктә нефть һәм аңа чиктәш тармакларда, һәм шулай ук социаль һәм коммуналь өлкәләрдә эшләүче 100 меңгә якын кеше җыела. Үз кадрларын әзерләү өчен барлык баскычлардагы уку йортлары ачыла.

Тиз арада көчле инфраструктура булдыру, кешеләргә эшләү һәм яшәү өчен нормаль шартлар тудыру зарурлыгы килеп туа. Төзелеш материалларына кытлык проблеманы тагын да тирәнәйтә. Моннан чыгу юлы 10–15 елга исәпләнгән җыелма-щит йортлар кору ысулы белән хәл ителә. Ахыр чиктә Татарстанның бөтен көньяк-көнчыгышы яңа төс ала. Ямь-яшь шәһәрләр һәм эшче бистәләре барлыкка килә, иске шәһәрләр танымаслык булып үзгәрә.

ИЛДӘ БЕРЕНЧЕЛӘР

1956 елда «Татнефть» нефть табу күләме буенча Советлар Союзында беренче урынга чыга, ә 60 нчы елларда Татарстан илдәге бөтен нефтьнең өчтән бердән артыграк өлешен чыгара. 1968 елда СССР Хөкүмәте бер елга нефть чыгару күләмен 100 миллионга җиткерү күрсәтмәсен бирә. Ул 1970 елда үтәлә.

1971 елда республикада – беренче, ә 1981 елда икенче миллиард тонна нефть табыла. Татарстан нефте бәрабәренә ил искиткеч көчле ресурсларга ия була. Әмма аннан соңгы еллар җир асты байлыкларының төпсез түгеллеген күрсәтә. 1976 елдан башлап, Татарстанда 101,5 миллион тонна нефть күләмендә югары планкага ирешелә, һәм аннан соң күрсәткечләр түбән төшә башлый –

Фото «Татнефть» ГАҖ матбугат хезмәтеннән алынды

1950 нче еллар

1991 елга 32,5 миллион тоннага кадәр. Бик күп көч кую бәрабәренә түбәнгә тәгәрәүне туктатуга һәм нефть табуны тотрыклы итүгә ирешелә. Бу фәнни казанышлар һәм техник камилләштерүләр, инде ярлыланган катламнарны тергезү, авыр чыгарыла торган запасларны үзләштерү нәтиҗәсендә башкарыла. Элек перспективасыз саналган вак чыганакларны да әйләнешкә кертү өчен, кече нефть компанияләре төзелә. Әлеге кыю эксперимент федераль җитәкчелек тарафыннан бөтен тармак өчен лаеклы үрнәк буларак кабул ителә.

ЕСТЬ ДВА МИЛЛИАРДА ТОНН НЕФТИ!

СОВЕТСКАЯ ТАТАРИЯ

Центральному Комитету Коммунистической партии Советского Союза, Генеральному секретарю ЦК КПСС, Председателю Президиума Верховного Совета СССР товарищу Леониду Ильичу БРЕЖНЕВУ

ВЕНЕЦ УДАРНОГО ТРУДА

Заветный рубеж взят!

НЕФТЬ – ТОРМЫШ РӘВЕШЕ

Татарстанда 2007 елда алынган өч миллиард тонна нефтьне, этап күрсәткече дип, түгәрәк саннар магиясе өчен генә атамыйлар – шушы мизгелдән, аз-азлап кына булса да, даими үсеш башланып китә. Әлмәттә өч миллиард тонна нефть алу хөрмәтенә куелган монументны Минтимер Шәймиев берничә буын нефтьчеләрнең тиңдәшсез батырлык символы дип атады.

«Нефть – республиканың 1943 елдан башланган тормыш рәвеше», – диде ул чакта Минтимер Шәймиев. – Бүген инде сүз дүртенче миллиард тоннаны алырга да ерак калмавы турында бара, ә фән бишенче миллиард тоннаны алырга реаль мөмкинлек барлыгын раслый, шул исәптән табигый битумнар хисабына да». «Бу җиңел булмаячак, яңа, югары нәтиҗәле технологик чаралар кирәк булачак, һәм «Татнефть» бу эшкә әзер», – дип җавап бирде компаниянең 1999 елдан 2013 елга кадәрге генераль директоры Шәфәгать Тәхәветдинов.

«Илдә «җиңел нефть» дәвере тәгәлләнде, ә Татарстанда нефть табу тагын да күбрәк фәнни әзерлекне таләп итә торган интеллектуаль процесска әверелә бара», – диде бер чыгышында республика Президенты Рөстәм Миңнеханов.

«Иске» чыганакларны эшкәртүнең катлаулана барган геологик шартлары нефтьчеләрне эчке резервларны активрак эзләргә мәҗбүр итә, – ди «Татнефть»нең генераль директоры Наил Маганов. Бу юлда төп драйверларның берсе дип ул «дүртенче индустриаль революция»нең мөмкинлекләрен атады. Компания барлык җитештерү системасын цифрлы трансформацияләүгә курс алды.

Айдар Метшин,
Түбән Кама шәһәре мэры, ТР Түбән Кама районы башлыгы, августта 55 яшьлеген билгеләп үтә.

Азат Бикмурзин,
«Түбән Кама Нефтехим» ГАЖ генераль директоры

Хөрмәтле Айдар Рәисович!

«Түбән Кама Нефтехим» ГАЖнең меңләгән кешедән торган коллективы исеменнән Сезне юбилеегыз белән котлыйм!

Түбән Кама бүген – матур, уңайлы, төзек шәһәр, ул Татарстан районнарының социаль-икътисадый үсеш рейтингында югары урыннар били һәм ышанычлы рәвештә республиканың әйдәп баручы мәдәни һәм спорт үзәге позицияләрен саклый. Сез җитәкчелек иткән елларда биредә халык өчен максималь уңайлы шартлар булдыруга юнәлтелгән күпсанлы заманча уникаль проектлар тормышка ашырылды.

Сез үзегездә катлаулы мәсьәләләрне хәл итүгә иҗади мөнәсәбәтне, фикер киңлеген һәм җаваплылык хисен берләштерәсез. Амбициоз максатларга ирешүгә омтылышыгыз киләчәктә дә Сезгә Түбән Кама муниципаль районы файдасына яңа проектларны һәм планнарны тормышка ашырырга булышсын!

Сезгә чын күңелдән ныклы сәламәтлек, иминлек, күтәренке кәеф һәм чиксез оптимизм, ирешелгәннәр өчен горурлык һәм барлык башлангычларыгызда уңышлар телим!

Фото «Түбән Кама Нефтехим» ГАЖ матбугат хезмәтеннән алынды.
Реклама

Ринат Шәрапов,
«Өченче Түбән Кама монтаж идарәсе» АҖ генераль директоры

Юбилейга – тормышка ашкан проектлар һәм идеяләр багажы белән

– Хөрмәтле Айдар Рәисович! «Өченче Түбән Кама монтаж идарәсе» коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне 55 яшьлегегез белән котлыйм!

Сезнең тормыш юлыгыз күпсанлы уңышлы эшләрдән, бай идарә итү тәҗрибәсеннән, шәхси казанышларыгыздан һәм даими рәвештә алга бару омтылышыннан гыйбарәт. Бу юбилеегызга тормышка ашкан проектлар һәм идеяләрнең зур багажы белән килдегез. Моны аңлар өчен Сез күп еллар җитәкчелек иткән Түбән Кама шәһәренә һәм Түбән Кама районына күз салу да җитә.

Сезгә көчле ихтыяр, искиткеч оештыру сәләте, зур абруйга һәм инновацион фикерләүгә ия җитәкчелек таланты хас. Шәһәрдә һәм районда биредә яши торган барлык халыклар мәдәнияте һәм традицияләре бер-берсе белән ярашып яши һәм үсә. Шәһәр хакимиятләре алып бара торган күп мәдәниятлелек сәясәте – бүгенге заман өчен бик тә зарури булган чын казаныш.

Хөрмәтле Айдар Рәисович! Шәһәр һәм районнарның җитәкчелегендә Сезнең кебек максатчан, профессионалларның иң яңа һәм кыйммәтле идеяләрен кертергә омтылучы кешеләрнең эшләве республикабыз үсешенә биниһая зур өлеш кертә.

Бу көндә Сезгә ныклы сәламәтлек, гаилә иминлеге, эштәге партнёрларыгызның ышанычлылыгын һәм даимилеген, яңа профессиональ биеклекләргә ирешүегезне теләргә рөхсәт итегез. Сезгә һәрвакыт яхшы кәеф һәм иҗади күтәренкелек юлдаш булсын!

Фото «Өченче Түбән Кама монтаж идарәсе» АҖ матбугат хезмәтеннән алынды.

Түбәнкамалыларның яңа казанышлары хакына

Хөрмәтле Айдар Рәисович, «Татспецнефтехиммонтаж» Идарәче компаниясе» ЖЧЖнең барлык җитәкчеләре һәм структур бүлекчәләре коллективлары исеменнән 55 яшегез белән котлыйбыз. Сезнең бөтен гомерегез һәм карьерагыз диярлек безнең шәһәр белән бәйләнгән. Чын лидер һәм талантлы идарәче буларак, Сез туган шәһәрегез өчен күп эш башкардыгыз. Нефть химиясе предприятиесенең аппаратура җиһазларын ремонтлаучы слесарьдан башлап, Татарстанның иң эре шәһәрләреннән берсенә җитәкчелек итүгә кадәр узган хезмәт юлыгыз зур хөрмәт уята, максатчанлыгыгыз һәм энергиягез турында сөйли.

Өске рәттә, сулдан уңга: «Түбән Кама – Тепломонтаж» ЯАҖ генераль директоры Г. С. Гатиятов, «ТКМИ-2» ҖЧҖ генераль директоры киңәшчесе М. С. Алимбеков, «ТМНХМ» ИК» ҖЧҖ генераль директоры Р. Б. Чигарьков, «ТКМИ-1» АҖ баш инженеры Д. З. Билалов, эретеп ябыштыру-монтажлау колледжы директоры М. Н. Павлов; аскы рәттә, сулдан уңга: «Үзәк монтажавтоматика» ТКП» ҖЧҖ генераль директоры Р. Т. Гайфуллин, «ТКМИ-3» АҖ генераль директоры Р. Т. Шәрәпов, МТМЛ ИК генераль директоры, «ТМНХМ» ИК» ҖЧҖ Гамәлгә куючылар советы рәисе В.И.Носов, «Татэлектромонтаж» АҖнең Түбән Кама идарәсе башлыгы М. М. Гатин, «Термостепс» Түбән Кама махсус идарәсе» АҖ генераль директоры Р. М. Вәлиев, «ТКИ» Коммерциячел булмаган партнерлыгы директоры И. Н. Паньшин.

Фото «Татспецнефтехиммонтаж» ИК» ЖЧЖ матбугат хезмәтеннән алынды

Бүгенге көндә Түбән Кама бөтенләй яңача күренә: заманча индустрия гигантлары, торак микрорайоннар, сәламәтлек саклау объектлары, яр буйлары һәм парклар – барысы да соңгы елларда төзелеп кенә калмады, ә бәлки үсә дә бара. Димәк, Татарстандагы динамик үзгәрешләр дәвам итә, дигән сүз. Сез, даими хәрәкәттәге һәм үсештәге шәхес буларак, түбәнкамалыларның хөрмәтен бик күптәннән яуладыгыз. Шунысы мөһим: шәһәр кешеләренең фикер сөреше дә үзгәрде, алар үз шәһәрләре белән горурлана, аның республиканың башка шәһәрләре арасында нинди урын тота башлавын яхшы аңлый.

Заманча бизнес-җитәкченең күренекле вәкиле буларак, Сез фикердәшләрегез командасына югары эшлеклелек стандартлары куясыз.

Сезнең актив гражданлык позициягез тагын да зуррак хөрмәткә ия: иҗтимагый әһәмияте булган хәйрия, белем бирү проектларында катнашуыгыз, талантлы яшьләргә ихлас күңелдән ярдәм итәргә омтылуыгыз, спортны үстерүегез һәм мәгариф өлкәсендә инновацион технологияләр кертүегез – әнә шулардан. Сезнең өстенлекләрне күрүегез һәм аларны тиешле урынга куя белүегез, катлаулы мәсьәләләрне хәл итү барышында үзара иң дөрес, ышанычлы мөнәсәбәтләр урнаштыруыгыз шәһәрдә һәм районда тормыш сыйфатын яхшыртуга хезмәт итә.

Без ышанабыз, күп еллар дәвамында Сез туплап өлгергән сизелерлек тәҗрибә һәм идарә итү потенциалы түбәнкамалыларны яңа казанышларга китерәчәк!

Хөрмәтле Айдар Рәисович, Сезгә барлык башлангычларыгызда уңышлар насыйп булсын, якыннарыгызның җылысын һәм кайгыртуын, коллегаларыгызның һәм фикердәшләрегезнең ярдәмен тоеп яшәгез, эшләгез. Бетмәс-төкәнмәс энергия һәм перспективалы, кызыклы проектлар туып, тормышка ашып торсын!

Мәхмүт Гатин,
«ТАТЭМ» ААҖ ТКМИ
идарәсе башлыгы

Шәһәрне һәм районны үстерү өчен…

– Хөрмәтле Айдар Рәисович, 55 яшьлек юбилеегыз көнендә Сезне үз исемемнән һәм предприятиебезнең бөтен коллективы исеменнән ихлас котлыйм.

Берьюлы муниципаль район башлыгы һәм республиканың иң эре шәһәрләренең берсендә мэр булу – шактый җаваплы бурыч. Бу бурычны уңышлы башкарырга Сезгә перспективаларны алдан күрә белү, кешеләр белән эшләү тәҗрибәсе, катлаулы мәсьәләләрне хәл иткәндә, аның дөрес чишелешен табу һәм, әлбәттә, үз шәһәреңне тагын да яхшырак һәм матуррак итеп күрергә теләү ярдәм итә. Түбән Кама бүген республиканың эре сәнәгать, мәдәният һәм спорт үзәге һәм ул инде берничә тапкыр республика өчен әһәмиятле булган проектларны тормышка ашыру мәйданына әверелде. Шәһәрдә федераль һәм республика программаларында катнашу буенча шактый мәсьәләләр уңышлы башкарыла.

Түбән Камада медицина хезмәте күрсәтүнең һәм мәгарифнең иң заманча, нәтиҗәле системалары, спорт базасы булдырылган, мәдәният учреждениеләре челтәре үсеш алган, профилактик медицина һәм экологиягә зур игътибар бирелә. Боларның барысына да Сезнең шәхси һәм эшлекле сыйфатларыгыз, куелган мәсьәләләрне оператив хәл итә белүегез, һөнәри тоемыгыз, тәрбиягез һәм җаваплылыгыгыз нәтиҗәсендә ирешелә. Сез шәһәр кешеләре арасында лаеклы рәвештә зур абруйга ия, чөнки чыгышыгыз буенча Түбән Кама кешесе буларак, Сез шәһәрне бик яхшы беләсез һәм яратасыз, анда еллар буе яшәп килгән традицияләр кадерләп саклана һәм яңалары барлыкка килә. Кыенлыклардан курыкмыйча, Сез катлаулы проектларга алынасыз һәм үзегез төзегән команда белән бергә аларны уңышлы итеп тормышка ашырасыз. Без ышанабыз, Сезнең тәҗрибә белән Түбән Камага һәм Түбән Кама муниципаль районына моннан соң да барлык юнәлешләрдә прогрессив үсеш насыйп булыр. Бу үсештә безнең предприятиенең дә шактый өлеше булуы белән чын мәгънәсендә горурланабыз.

Туган шәһәрегезне яшәү өчен тагын да уңайлырак итәргә омтылуыгыз сүрелмәсен һәм монда Түбән Кама кешеләренең Сезгә күрсәткән ярдәме дә һәрчак сизелеп торсын иде! Юбилеегыз алдыннан безнең коллективтан Сезгә һәм якыннарыгызга чын күңелдән бәхет, сәламәтлек һәм иминлек телибез!



Реклама Фото «ТАТЭМ» АҖ ТКМИ матбугат хезмәтеннән алынды

Фәрит Туктаров,
«ТР стандартлаштыру, метрология һәм сынауларның дәүләт төбәк үзәге» ФБУ директоры, сентябрь аенда үзенең 60 яшьлеген билгеләп үтә.



Ринат Ханбиков,
«Газпром межрегионгаз Казан» АҖ генераль директоры

Икътисадның нәтиҗәлелеген күтәрү ачкычы

Хөрмәтле Фәрит Хәйдәрович! «Газпром межрегионгаз Казан» АҖ коллективы һәм үз исемемнән юбилеегыз белән котлыйм. Иң җылы һәм ихлас теләкләребезне кабул итегез!

Республикада Сезне барысы да бик яхшы кеше һәм профессионал буларак белә һәм бәяли. Хезмәт сөючәнлек, зур кызыксынучанлык кыры, максатчанлык Сезгә тотынган һәр эшегездә югары нәтиҗәләргә ирешергә булыша.

Сезнең, Директорлар советы әгъзасы буларак, безнең предприятие эшчәнлегендә катнашуыгызны аерым билгеләп үтәсем килә. Икътисад һәм сәнәгать министры урынбасары буларак, Татарстан мәнфәгатьләрен кайгыртып, Сез һәрвакыт безгә төбәктәге кулланучыларны, аерым алганда, социаль әһәмиятле предприятиеләрне һәм халыкны табигый газ белән тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итүдә ярдәм иттегез.

Менә инде биш ел дәвамында Сез техник көйләү һәм метрология буенча Федераль агентлык системасында иң эреләрдән булган – «ТР стандартлаштыру, метрология һәм сынауларның дәүләт төбәк үзәге» ФБУ белән уңышлы җитәкчелек итәсез.

«ТР стандартлаштыру, метрология һәм сынауларның дәүләт төбәк үзәге» ФБУның тәэмин ителеш дәрәҗәсе бүгенге көндә безнең республикада һәм РФ төбәкләренең кайберләрендә кулланыла торган барлык үлчәү чараларын диярлек тиешле контроль белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирә. Сез җитәкчелек иткән предприятиенең төгәл эшләве икътисад нәтиҗәлеген күтәрү һәм татарстанлыларның тормыш сыйфатын яхшырту өчен ачкыч булып тора.

Сез – иң катлаулы мәсьәләләрне дә җиңел итеп чишәргә сәләтле югары нәтиҗәле һәм уңышлы җитәкче. Шул исәптән без бергә күп еллар буе уңышлы хезмәттәшлек иткән газ тармагында да

«Газпром межрегионгаз Казан» АҖнең барлык хезмәткәрләре исеменнән Сезгә уңышлар, оптимизм, көч һәм энергия, тотрыклылык һәм җитеш тормыш телибез! Шулай ук ныклы сәламәтлек, бәхет, туганнарыгыз һәм якын кешеләрегезнең мәхәббәтен! Оештыру талантыгыз, тәҗрибәгез һәм максатчанлыгыгыз киләчәктә дә уңышларыгызның гаранты булсын.

Фото «Газпром межрегионгаз Казан» АҖ матбугат хезмәтеннән алынды
Реклама

Рәфкать Кантюков, «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ генераль директоры, август аенда үзенең 65 яшьлеген билгеләп үтә.

Ягулык-энергетика комплексының мактаулы хезмәткәре, нефть һәм газ сәнәгатенең атказанган хезмәткәре, газ сәнәгатенең мактаулы хезмәткәре, Казан шәһәренең мактаулы гражданины, Татарстан Дәүләт Советы депутаты, күп еллар дәвамында республика икътисадына көчле импульс бирүче газ тармагының җаваплы участокларында эшли. Аның турыдан-туры җитәкчелегендә республика газчылары Татарстанны газлаштыру буенча Президент программасын тормышка ашырдылар.

Ныклы сәламәтлек һәм бетмәс-төкәнмәс энергия!

Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго» АҖ генераль директоры

– Хөрмәтле Рәфкать Габделхәевич! «Татэнерго» АҖ коллективы Сезне 65 яшьлек юбилеегыз белән котлый һәм бу елның яңа уңышлар һәм колачлы планнар елы булуын тели!

Сезнең дәрәҗәдәге җитәкченең җаваплылыгы икеләтә югары. Ул вазыйфаи бурычлар белән генә түгел, ә бәлки компаниянең республикабыз социаль-икътисадый хәлен һәм анда яшәүчеләрнең иминлеген ныгытудагы стратегик роле белән дә билгеләнә. «Газпром трансгаз Казан», социаль юнәлешле компания буларак, һәрвакыт республиканың мәдәни һәм спорт проектларына, фәнгә, яшь талантларга, шулай ук ветераннарга ярдәм итә. Сезнең көн саен туып торган катлаулы мәсьәләләр спектрын уңышлы хәл итә белүегезне бәяләгәндә, без Сезнең актив эшчәнлегегезнең Татарстан халкының уңайлы һәм рәхәт яшәвенә юнәлтелгәнен күрәбез.

«Татэнерго»-«Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖнең төп заказчыларыннан берсе булып тора. Без компанияләребез арасында урнашкан эшлекле партнёрлык мөнәсәбәтләрен югары бәялибез һәм уртак эшебез киләчәктә дә нәтиҗәле дәвам итәр, дип өметләнәбез.

Ихлас күңелдән юбилеегыз белән котлыйбыз һәм Сезгә, Рәфкать Габделхәевич, барлык башлангычларда уңышлар, сәламәтлек, бетмәс-төкәнмәс энергия телибез!

Фото «Татэнерго» АҖ матбугат хезмәтеннән алынды

Реклама

Фото «Газпром газ-мотор ягулыгы»ЖЧЖ матбугат хезмәтеннән алынды

Михаил Лихачёв,
Идарә рәисе – «Газпром газ-мотор ягулыгы» ҖЧҖ генераль директоры

Хөрмәтле Рәфкать Габделхәевич!

– «Газпром газ-мотор ягулыгы» ҖЧҖ коллективы һәм үз исемемнән Сезне чын күңелдән 65 яшьлек юбилеегыз белән котлыйм!

Сезнең белән кулга-кул тотынып эшләүче һәркем Сезгә хас булган көчле эшлеклелек сыйфатларын, максатчанлыкны, оптимизмны һәм тормыш энергиясен югары бәяли.

Сез – Татарстан Республикасында танылган җитәкчеләрнең берсе: күп еллар дәвамында «Газпром» ГАҖнең төбәктәге баш предприятиесенә җитәкчелек итүне уңышлы рәвештә республика Дәүләт Советы депутатының иҗтимагый эшчәнлеге белән бәйләп алып барасыз. Сез искиткеч белгеч, талантлы идарә итүче, чын профессионал, новаторларча лаеклы зур хезмәт юлы үткән шәхес. Сезнең җитәкчелектә Татарстан Республикасын газлаштыру программасы тулысынча тормышка ашырылган, төбәктә газ-мотор тармагын үстерүгә нигез салынган, һәм ул бүген Россия Федерациясендә газ-мотор ягулыгы базарында әйдәп баручылар сафына басты.

Коллегаларыгыз, партнёрларыгыз, ватандашларыгыз белән аралашкандагы киң күңеллелек, югары эчке культура, әдәплелек сыйфатлары – болары да Сезгә карата тирән ихтирам һәм ышаныч уята.

Хөрмәтле Рәфкать Габелхәевич! Сезгә һәм якыннарыгызга сәламәтлек телим. Барлык хыялларыгыз чынга ашсын һәм лаеклы нәтиҗәләр китерсен!

Фото «Газпром межрегионгаз Казан» АҖ матбугат хезмәтеннән алынды

Ринат Ханбиков,
«Газпром межрегионгаз Казан» АҖ генераль директоры

Ихтирамга лаеклы җитәкче

– Хөрмәтле Рәфкать Габделхәевич! Бу искиткеч көндә, ягъни юбилеегыз көнендә, Сезне «Газпром межрегионгаз Казан» АҖ коллективы һәм үз исемемнән котларга телим! Бүген Сез биләгән вазыйфаны һәм шулай ук Сез алып барган зур җәмәгать эшләрен үз-үзеңне шуңа тулысынча багышлаудан, югары профессиональлек һәм җаваплылыктан башка күзаллау мөмкин түгел. Сездәге эшлеклелек сыйфатына, һәрвакыт оптимистлар рухын саклавыгызга һәм коллегаларыгыз белән нәтиҗәле эшлекле мөнәсәбәтләр кора белүегезгә сокланырга гына кала. Сезгә бирелгән бүләкләр һәм мактаулы исемнәр коллегаларыгыз һәм Сезне белүче барлык кешеләр арасында зур ихтирамга ия булуыгыз турында сөйли. Сез кадрларга һәм компаниядә яшәп килгән хезмәт традицияләренә сак карыйсыз һәм бу, һичшиксез, үзенең уңай нәтиҗәләрен бирә. Сез бүгенге көн офыкларын һәм, иң мөһиме, предприятиенең перспективаларын күрә белүче ихтирамга лаеклы җитәкче. Илнең газ тармагында шундый талантлы һәм ышанычлы җитәкчеләрнең булуы олы бәхет ул. Сезнең кебек белгечкә һәм җитәкчегә теләсә кайчан таянырга мөмкин.

Шикләнмим, Сезнең профессиональлегегезгә һәм биниһая зур тәҗрибәгезгә республикада әле күп еллар буена ихтыяҗ булачак. Яңа казанышлар телибез Сезгә! Бәхет һәм сәламәтлек үзегезгә дә, якыннарыгызга да һәрвакыт юлдаш булсын, тормыш уңай эмоцияләр белән куандырып торсын! Юбилеегыз белән, Рәфкать Габделхәевич!

Автор:
Руфия Фазылова

КӘҖӘ БИСТӘСЕ: СОҢГЫ УТЛАР

Без утырган нәшрият бинасы Кәҗә бистәсендә урнашкан. Тәрәзәдән көн дә гаҗәеп манзараны күзәтәбез: Казансу елгасы, Кремль... Ә сулгарак күз салсаң, карашың белән ярымишелгән йортларга төртеләсең. Буялмаган, җиргә үк батып беткән агач өйләр ул. Бу – Казанның кайчандыр атаклы Кәҗә бистәсенең соңгы хәрабәләре. Әле яз көне генә алар дистәләп иде. Футбол буенча дөнья чемпионаты алдыннан берничә өйне сүттеләр. Безнең күзне «иркәләргә» бишесе генә утырып калды. Аларын да сүтеп атканчы, борынгы Кәҗә бистәсе тарихка кереп калсын, дип, аның соңгы могиканнары белән күрешергә булдык.



«Озакламый сүтәчәкләр, фатир бирәчәкләр», – дип яши-яши шушы нигездә картайдык, – ди Венера апа Хәкимҗанова.

«ВАКЫТЛЫЧА» ДИП АЛГАН ЙОРТТА КАРТАЙДЫК....

Бактың исә, Кәҗә бистәсендә иске агач өйләр бишәү генә дә түгел икән. Аның әлегә ике урамы – Кемерово һәм Түбән Торфяная калган. Безнең нәшриятка карап торганы Кемерово урамы. Аларның ни капкалары, ни коймалары, дигәндәй, кыскасы, ярым ишелгән хәлдә тора алар. Чемпионат башланыр алдыннан йортларны ике метрлы яшел калай белән уратып алдылар. Бер белмәгән кеше урамнан узып барганда, монда шундый хәрәбәләр бар, дип уйлап та карамый, әлбәттә.

Кемерово урамындагы иң сөйкемле йортның капкасын шакырга булдык. Башкалар янәшәсендә ул зуррак, төзегрәк тоелды. Май чүлмәге тышыннан билгеле шул, ишектән бик сөйкемле апа күренде. Һәм күптән күргән кешеләр кебек аралаша да башладык.

– И, җаныем, без монда 35 ел яшибез инде, – диде Кемерово урамындагы 8 нче йортта гомер итүче Венера апа Хәкимҗанова. – Ике улыбыз да шушында үсте. 1984 елда бу йортны бер әбидән 3 меңгә сатып алган идек. «Озакламый сүтәчәкләр, фатир бирәчәкләр», – дип яши-яши картайдык. Балалар өйләнеп гаилә корды, фатирда яшиләр. Ә без мөнә көтәбез.

– Сезнең йортларны кайчан сүтәчәкләр соң? – дим Венера апага.

– Берәү дә белми. Шәһәр администрациясеннән вәкилләр

Фото: Лилиана Валитова

дә килде. Төгәл җавап бирмәделәр. «Бу урында мәктәп, балалар бакчасы төзеләчәк, тик әлегә шәһәрнең андый акчалары юк», – дип аңлаттылар.

Акча дигәннән, яз көне Кемерово урамында биш йортны сүткәннәр. Бер сутый җиргә 950 мең сум акча биргәннәр. Биредә һәр өйнең кимендә 7-8 сутый җире бар икәнен исәпкә алсак, хуҗалар ярыйсы гына акча алган. Һәрхәлдә, бу ишелеп беткән йортта яшәгәнче, ул акчага яңа өч бүлмәле фатир алып була.

Бүлгәч зур акчалар түгел ул, – диде Венера апа. – Мисал өчен каршыда Зәкия апа яши иде. Фатир биргәннәрен көтеп тәки үлеп китте. Йорты белән җиде сутый җире өч баласына калды. Алар бүлешә инде. Безнең дә өйдә ун кеше теркәлгән. Ирем белән мин, хатыннары белән ике улыбыз, аларның икешәр балалары. Безнең җир тугыз сутый. Тизрәк алсыннар иде, дибез, картайган көндә кайнар су белән юынасы килә, бәдрәф тә урамда бит.

Хуҗабикә безгә бакчасын күрсәтеп йөрде: монда бөтен нәрсә дә үсә. Нәкъ авыл йорты, аерма шунда гына – шәһәр ыгы-зыгысы нык ишетелә. Җитмәсә, күршедә зур йорт салалар. Дөп-дөп иткән тавыш колакны яра.

– Егерме елдан бирле төзелеш бара монда, – ди Венера апа. – Әле бер йорт салалар, әле икенчесен. Өйдә хәтта тәлинкәләр селкенеп тора...

Венера апа өенә дә чакырды. Мичтән чыккан, яңа пешкән алма бәлешен турап куйды.

– Мактап йөрисез, – дип, кыстый-кыстый чәй эчерде. Тиз генә әни янына кайтып килгән кебек булдык...

– Менә дигән бакчагыз бар, чагыштырмача өегез дә әйбәт. Барыбер күпкатлы йортка күчәсегез киләме? – дим хуҗабикәгә.

– Җәен бик рәхәт, әмма кышлар бар бит. Суны урамдагы колонкадан ташыйбыз, кышын юл юк, кар күмеп китә. Бу йорт 1936 елда салынган, нигезләре начар, суык керә. Карап торганга гына шундый хәлдә ул. Берничә ел элек иске агачлардан улыбыз янкорма эшләп куйды. Елларда мунчага килгәч, алар шул якта йоклый. Ә болай урын барыбызга да җитә, күңел иркен безнең. Әле кышын Әтнәдән 82 яшьлек әнине дә алып киләбез.

Кемерово урамындагы биш йортның берсендә Ольга Осипова егерме яшьлек улы белән яши икән.

«УТ-КҮЗДӘН КУРКЫП ЯШИБЕЗ»

Кемерово урамындагы биш йортның тагын берсенә сугылдык. Ольга Осипова егерме яшьлек улы белән яши икән. Хәкимҗановлар өеннән соң Осиповларныкы, йомшак кына әйткәндә, күпкә кайтышрак ул. Бу ихата ниндидер чүплек өемен хәтерләтте. Ике корылманың кайсысы сарай, кайсысы йорт икәнен аңламассың. Икесендә дә тәрәзәләргә такта кадакланган, ишекләр салынып төшкән. Буш савытлар, әллә нинди тартмалар, иске кием-салым, барысы да аяк астында аунап ята. Ана белән ул каян, ничек йөри торгандыр, хәтта аптырадым да.

– Бу йорт безгә әти-әнидән калды, – дип сөйләде Ольга Осипова. – Миңа ун яшь булганда бирегә күчендек. Минем тагын сеңлем, абыем бар. Алар да монда теркәлгән, яшәмиләр генә.

Ике ел элек Осиповларның уң як күршеләре ихатасында янгын чыккан. Санаулы минутлар эчендә ялкын йортны юк иткән. Шулвакыт Осиповларның иске өе аздан гына янмый калган.

кыныч. (Кичен ут та юк икән.) Бата-чума дигәндәй, йортларга кадәр килеп җиттек. Каршыга шактый таушалган йөзле, салмыш бер ир килеп чыкты.

– Сез кем? Нишләп йөрисез? – диде дорфа гына.

Шактый җайлап сөйләшә торгач, кемнәр икәнебезне аңлаткач, ир ачылып китте. Алексей исемле икән, бередә әти-әнисе белән яши.

– Әйдә, минем белән. Монда ишәк, кечкенә атлар асраучылар яши. Шулар йортына алып барам, – диде Алексей.

Фотограф кыз Лилиана исә салмыш ир артыннан барудан баш тартты. Куркам, дип кире йөгерде.

– Ә сез курыкмыйсызмы? – ди Алексей.

– Кемнән? – дим.

– Миннән...

– Ә куркырга кирәкме? – дим.

Алексей бик канәгать кыяфәт белән көлеп җибәрде.

– Курыкма. Мин яхшы егет. Мондагы бөтен кешене кулда тотам.

Кыскасы, Кәҗә бистәсенең «смотрящий» егете, әллә нинди кечкенә басмалар аша бер ишелгән йортка алып килде. Кычкыра-кычкыра ишек шакырга керешге. Ул да түгел капка астыннан усал итеп өреп эт килеп чыкты. Менә кайда ул экстрим! Атлар асраучы кешеләр өйдә булып чыкмады.

– Бу кешеләр атлар белән акча эшли, – диде Алексей. – Паркларда балаларны йөртәләр. Монда яз көне килеп урнаштылар. Ә аңа кадәр Кемерово урамында иске бер өйне «снимать» итеп яшәделәр. Йортларны сүткәч, монда күченделәр. Хәзер безнең үзебезнең зоопарк.

Алексей рольгә шулкадәрле керде ки, чын хуҗаларча, бистәдә элек булган хәлләрне дә сөйләде. Булдыра ала торганнар, майтарып карадылар эшләрне, диде. Хәзер эш майтарырлык кешеләр генә калмаган... дигән фикер белән кайттык.

– Өйнең бер як диварлары кара көйде, – ди Ольга. – Әле ярый янгын сүндерүчеләр вакытында килеп җитте. Ә узган җәй күршеләрнең бакча янәшәсендәге иске өйләре янды. Анда кеше яшәми иде инде. Тагын Алла саклады, ялкын безгә күчмәде.

– Монда шулай янгыннар еш буламы? – дим.

– Була. Язын сүтелгән йортлар арасында да янып, көлгә әйләнгән нигезләр бар иде. Ут-күздән гел куркып яшибез.

– Ут төртәләрме, янгыннар ник чыга?

– Махсус төрткән очраклар да бар. Кайбер ташландык йортларда сукбайлар да яшәде, тәмәке төпчеге төшереп калдырганнар. Аннан, йортлар иске, ут чыбыкларына да йөзәр ел бит. Кыска ялганыш очраклары да булды.

Бистәдә яшәүче башка кешеләрдән аермалы буларак, Ольга Осипованың Кәҗә бистәсеннән китәсе килми. Югыйсә, иң начар ихата аларныкы кебек тоелды, шулай да...

– Ә без урамга бәдрәфкә йөрергә, колонкадан су ташырга өйрәнгән инде, – диде ул. – Үз дигәнчә яшибез. Берәү белән дә ишегалдын бүлешәсе юк. Шәһәр үзәгендә рәхәтләнеп торып ятабыз.

Хуҗабикә, бик кадерле әйбере белән бүлешкәндәй, иске корылмаларның берсе янына алып килде.

– Әти-әни йортны сатып алганчы, бу бинада ветеринар клиника булган. Әлбәттә, ул чорда алай аталмаган инде ул. Песи, этләрне генә түгел, башка йорт хайваннарын да бередә дәвалаганнар. Әти-әни шулай сөйли иде. Шәһәр зурайгач, хайваннар өчен яңа дәвалау үзәкләре барлыкка килгән. Бинаны исә сатуга куйганнар. Без шунда яшәдек. Менә әле шәһәр администрациясенә хат язасым килә: сүтмәсеннәр иде бу корылманы. Кәҗә бистәсенең истәлеге булып калсын. Әнә бит Иске Татар бистәсендә никадәр йортны яңартып куйдылар. Реставрация ясасалар, бер дигән әле ул, тагын йөз ел тора ала!

Ольганы сәер дип әйтсәм, ялгыш булмастыр. Чүп-чар оясында үзенең фәлсәфәсе белән яшәп ята. Ихатасындагы һәр чүпрәкнең үз тарихы бар, тәфсилләп сөйли дә сөйли. Безнең заманның Плюшкины шундыйрак булырга тиештер кебек тоелды.

– Тавыклар да асрыйсыз икән, – дип Ольганы бүгенге көнгә кайтарырга телләп.

– Әйе, дүртәү генә калды инде. Боларын да бетерермен дим, артык эш кенә. Элек кәҗәләр дә асрый идек, хәзер бетердек. Сөтен яратмыйбыз, ашатырга азыгы да кирәк...

«СМОТРЯЩИЙ»

Осиповлардан чыккач күрше Түбән Торфяная урамына юнәлдек. Баксаң, Кемерово урамы аның белән чагыштырганда чыпчын цивилизация булган икән. Монда бөтенләй юл юк. Өстәвенә, алдагы көнне яңгыр явып узган иде, йөри торган түгел. Ә юлдагы чүп-чарны күрсәң! Шәһәр уртасында мондый күренешка тап булырбыз дип һич көтмәгән идек. Бер сүз белән әйткәндә, гаҗәп! Төнлә түгел, көндез йөрергә кур-

«МОНДА ТУДЫМ, МОНДА ГОМЕР ИТТЕМ»

Түбән Торфяная урамында җиде йорт бар. Алексей кебек әллә барысы да «текә»ме дигән идем, юк икән, төрле кеше бар. Гаять бер зыялы ханым – Надежда Викторовна Эсселевич белән таныштык. Заманында Казан дәүләт

университетын тәмамлаган. Җитмеш ике яшьне тутырган. Дөрес, аңа ул яшьне биреп булмый.

– Мин бирёдә туганмын, – диде Надежда ханым. – Без үскәндә Кәҗә бистәсе гөрләп торды. Биредә «Красный огородник» дигән совхоз бар иде. Анда ни генә үстермәделәр: иртә яздан кәбестә, помидор үсентеләре, соңрак суган, башка яшелчәләр сату дисеңме. Сатып алучылар Казаннан гына түгел, якын районнардан да килде. Совхозның кәҗәләре дә бар иде. Аннан сыр ясадылар. Минем әти дә «Красный огородник»та эшләде. Эшкә шәһәрнең төрле почмакларыннан йөзләп кеше йөрде.

Надежда Викторовна өенә чакырды. Йортлары төзек, җиргә дә батмаган.

– Бу йортны әти 1957 салды, – диде. – Мин ул вакытны яхшы хәтерлим. Аңа кадәр бик кечкенә, салам түбәле өйдә яшәдек. Замарында бу йорт бик затлы саналды, калай түбәле, ике яклы. Әти-әни үлгәннән соң, ирем белән без монда яши башладык. 12 сутый җиребез бар. Ел буе ашарлык бәрәңге, кишерен үстердек. Балалар да бакчада эшләп үсте.

Эсселевичларның бүген дә бакчалары бар. Анда кыяр, помидор, кишер, суган – барысы да үсә. Дөрес, унике сутыйның бөтен җиренә дә яшелчә утыртмаганнар.

– Безнең бакча артында зур күл бар иде, – диде Надежда ханым. – Анда су коена, балык тота идек. 1990 нчы елларда, зур төзелешләр башлангач, ул күлне балчык белән тигезләделәр. Анда агачлар утырттылар. Тик елга барыбер кибеп үк бетмәде, күрәсең, чыганагы калган. Язын шул урынга су җыела, безнең бакчаларга кадәр керә. Һәм җир июль айларында гына кибә. Шулай булгач, монда әйбер утыртырга җай юк.

Надежда Викторовнадан Кәҗә бистәсенең үткәне турында сорашам. Мәктәп, балалар бакчасы бар идеме? Юллар ничек?

– Мәктәп сез утырган нәшрият бинасы тирәсендә урнашкан иде, 66 нчы номерны йөртте. Мин шунда белем алдым. Ә каршысында балалар бакчасы эшләде. Ул вакытта Декабристлар урамы бүгенге кебек киң түгел иде. Ә Чистай урамында зур юл бөтенләй юк, аннан җәяүлеләр, атлар гына йөрде. Нәкъ авылдагы кебек өйләр төзелеп киткән. Һәр хуҗалык хайван, кош-корт асрады. Кара, сөйли торгач сагынып җибәрдем. Бар иде бит рәхәт, тыныч чаклар. Әтәчләр кычкыра, кошлар сайрый... Югыйсә әллә ни күп вакыт та үтмәгән, илле ел тирәсе. Ә шуның кадәрле үзгәрешләр. Хәтерлим, башта Чистай урамындагы өйләрне сүтеп, күпкатлы йортлар салдылар. Безне дә сүтәбез дигәннәр иде, насыйп булмады. Инде туган нигездә картайдым.

Эсселевичлар кышка әзерләнгәннәр инде. Ике машина утын алып кайтып, ярып, өеп куйганнар. Кыш чыгар өчен тагын ике машина күмер кирәк икән.

– Ел буена 15 меңлек утын, 15 меңлек күмер алабыз, – диде хуҗабикә. – Атна саен мунча да ягабыз бит. Ай саен 350 сумга газ баллоны сатып алабыз, ризыкны газда пешерәбез. Утка 100 сум тирәсе түлибез. Санап карасаң, коммуналь хезмәтләр шәһәр фатирыннан арзанграк чыга кебек. Шул мәшәкате бар, утынны ярырга, мичне ягарга кирәк. Әйтмәгәнем булсын, сәламәтлек зарланырлык түгел әле. Бабай белән икәүләп эшлибез.

«1990 нчы елларда, зур төзелешләр башлангач, күлне балчык белән тигезләделәр».



«Бу коедан әле дә су алабыз», – ди Надежда Викторовна Эсселевич (фотода – уңда, сулда – хуҗабикәнең якын дусты Тамара Козлова).

...Менә шундый ул бүгенге Кәҗә бистәсе. Сәер, серле, шул ук вакытта ямьле. (Аерым кешеләрнең бакчалары турында әйтәм.) Әлбәттә, башкалада мондый бистәләрнең бетеп баруы кызганыч. Казаныбыз таш калага әйләнеп бетеп бара. Җирдән аерылабыз...

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

Җиләкле бистәсе тирәсендә кешеләр Идел буе Болгар дәүләте вакытыннан бирле яшәгәнлеге билгеле. Аерым чыганаклар, Кәҗә бистәсен XVII гасырда оешкан дип күрсәтә. 1654 елда Казанда чума авыруы башлана. Бер төркем халык, коточкыч чирдән качып, Кәҗә бистәсенә күчеп утыра. Рәсми рәвештә Кәҗә бистәсе Казан эченә 1825 елда кертелә.

Риваятьләр буенча, чума авыруы вакытында, бистәгә күченеп килгән кешеләргә, җирле халык кәҗәне корбан иткән. Аның ите авыру һәм фәкыйрь кешеләргә бирелгән. Кәҗә итен ашаучылар сәламәтләнгәннәр. Сакаллы хайван халыкны коткарды дип исәпләп, бу урынга Кәҗә бистәсе дип исем биргәннәр.

1889 елда, Казан шәһәре думасы, сазлыкны киптерү карарын раслый. Җиләкле һәм Кәҗә бистәләре арасында дамбалы юллар ясала.

Кәҗә бистәсе шифалы үләннәр белән данлыклы саналган. Биредә халык гомергә күпләп кәҗәләр асраган. (Чыганак: Википедия.)

Без Татарстандагы төрле риваять-хикәятләрне җыю эшен дәвам итәбез. Ә андыйлар безнең төбәктә шулкадәр күп. Бүгенгесе исә Идел елгасының ике як ярыннан бер-берсенә карап торган шәһәрләрдә туган. Болгар белән Тәтешне әнә шулай бер риваять берләштергән.

ТАТАРСТАН РИВАЯТЬЛӘРЕ: ӨЧ БЕРТУГАН КЫЗНЫҢ КҮЗ ЯШЕ

Борын-борын заманнарда Идел яры буенда, хәзерге Кошки-Новотимбаево авылыннан егерме чакрым читтәрәк, Бөек Болгарның каравыл кальгасы булган, имеш. Ул бик биек, мәһабәт итеп ясалган – агач манара күкләрне терәп торган. Ә анда, иң өстә, болытлар янындамы, йолдызлар астындамы, сакчылар утырган. Алар көн-төн тирә-юньне күзәткән, ә инде офыкта бер-бер дошман күренсә, шундук Иделнең каршы ярына хәбәр салган. Шуңа күрә болгарларны берәү дә җиңә алмаган. Монголлар килгәнче…

Урда болгарларга шундый көчле һөҗүм итә ки, бөтен тирә-якны саранча кебек сырып алган исәпсез-хисапсыз сугышчыларга бу төбәкнең курку белмәс хуҗалары да каршы тора алмый. Монголлар бөтен гаскәрне кырып бетерә, шәһәрне талый, һәм менә алар Болгар иле хакименең сараена якынлаша… Аның исә, нәкъ әкияттәгечә, өч чибәр кызы була. Аларның матурлыгы турында илбасарлар да күптән ишеткән һәм шундый шәп җиңүләре өчен ошбу кызларны бүләк итеп алу турында хыялланган.

Тик кызлар чибәр генә түгел, акыллы да булып чыга. Өстәвенә, бу якларда яшәгән башка бик күпләр кебек, бераз тылсым-сихер дә кыла беләләр. Дошман кулына төшмәс өчен, алар аккошларга әверелә дә, канат җилпеп, җиңел генә Иделнең каршы ягына очып китәләр. Илбасарлар буе җитмәслек урынга – каравыл манарасының иң очына куналар. Тегеләр исә һични кыла алмый.

Туган калаларының янганын, көл өеменә әйләнгәнен күреп, кызлар бик озын-озак елый. Шул күз яшьләреннән чишмәләр хасил була, алар бүген дә Тәтеш тирәсендәге чокырлардан агып ята икән… Ул чишмәләрдә су бераз тозлырак, дип сөйли халык.

Редакция туган якларыгыз, туган авылларыгызның риваять-легендаларын бик теләп «бүләк итеп ала». Аларны безгә язып җибәрегез – һәм тиздән сезнең туган төбәк серләрен бөтен илебез белер.

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ

Бүгенге көндә бик күптөрле самолетларның конструкторлары үзләренең очкычларын Казанда ел саен уза торган «Я выбираю небо!» бәйрәмендә сынап карарга атлыгып тора. 2018 ел.

Фото: Александр Ефремов

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ



Дөнья авиациясе легендаларын – У-2 самолетларын – Бөек Ватан сугышы елларында Казанда җыйганнар. У-2 дошман позициясен штурмлау һәм бомбага тоту максатында кулланылган. 1943 ел.